А.И. Кравченко, Е.А. Певцова

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

9

СЫЙНЫФ

9
ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ
А.И. Кравченко, Е.А. Певцова

А.И. Кравченко, Е.А. Певцова

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

9 нчы сыйныф өчен дәреслек

II кисәк

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 сыйныфы өчен җәмгыять белеме буенча дәреслек буларак рөхсәт ителгән

Тәрҗемә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган

Москва
«Русское слово»
2004

Казан
Хәтер
2005

ББК 60я72
К78

Авторлары:
Кравченко А.И., *социология фәннәре докторы, профессор* — 1,3 бүл.
Певцова Е.А., *хокук фәннәре һәм педагогика фәннәре кандидаты* — 2 бүл.

Кравченко А.И., Певцова Е.А.
Обществознание: Учебник для 9 класса. Ч. II — 4-е изд.
М.: ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2004.— 224 с.

© ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2001, 2004
Все права защищены
© Хәтер, 2005

ISBN 5-94113-205-0

ЭЧТӘЛЕК

1 нче (4) бүлек. Сәяси сфера 4

§ 1 (§ 25). Хакимият 5
§ 2 (§ 26). Дәүләт 12
§ 3 (§ 27). Милли дәүләт төзелеше 20
§ 4 (§ 28). Идарә формалары 29
§ 5 (§ 29). Сәяси режимнар 39
§ 6 (§ 30). Гражданлык җәмгыяте һәм хокукый дәүләт .. 46
§ 7 (§ 31). Тавыш бирү, сайлаулар, референдум 55
§ 8 (§ 32). Сәяси партияләр 61

2 нче (5) бүлек. Кеше һәм аның хокуклары 70

§ 9 (§ 33). Хокук 70
§ 10 (§ 34). Закон һәм хакимият 82
§ 11 (§ 35). Конституция 90
§ 12 (§ 36). Хокук һәм милек мөнәсәбәтләре 97
§ 13 (§ 37). Кулланучы һәм аның хокуклары 102
§ 14 (§ 38). Хезмәт һәм хокук 106
§ 15 (§ 39). Хокук, гаилә, бала 110
§ 16 (§ 40). Җинаять 117

3 нче (6) бүлек. Рухи сфера 127

§ 17 (§41). Нәрсә ул мәдәният 127
§ 18 (§42). Мәдәни нормалар 136
§ 19 (§ 43). Мәдәният формалары 144
§ 20 (§ 44). Дин 153
§ 21 (§ 45). Сәнгать 163
§ 22 (§ 46). Мәгариф 173
§ 23 (§ 47) Фән 180

Йомгаклау сораулары 188
Йомгак 190
Сүзлек 194
Әдәбият 219



1 (4) нче бүлек. СӘЯСИ СФЕРА

Җәмгыятьнең сәяси сферасы — җәмгыятьне яулау, дәүләт хакимиятен кулда тоту һәм аннан файдалану белән бәйле эшчәнлек өлкәсе ул. Нәкъ менә шул өлкәдә хакимият өчен көрәш колач җәя һәм җәмгыять белән идарә итү алымнары һәм принциплары мәсьәләсенә кагылышлы җитди бәхәсләр кабына. Хакимият өчен көрәштә җәмгыятьнең *сәяси элитасы* актив роль уйный.

Илнең гади гражданнары референдумнарда һәм сайлау кампанияләрендә даими катнашып торсалар да, сәясәт өлкәсе аларга бик аз күләмдә генә кагыла. Без телевизор аша игътибар белән сәяси партия лидерлары чыгышларын, хөкүмәт алышынуын, закон чыгаручы һәм башкарма хакимият арасындагы көрәшне күзәтәбез, дәүләтнең икътисади, социаль һәм юридик мәсьәләләрне никадәр нәтиҗәле хәл итүен бәялибез.

Җәмгыятьнең сәяси сферасын өйрәнгәндә түбәндәге сорауларга җавап бирү зарур:

1. **Нәрсә** алар — дәүләт, сәяси партияләр, хакимият һәм закон?

2. Хакимиятне үз кулларына алу өчен кешеләр төркемнәре **ничек** көрәшәләр, көндәшләрен үз юлларыннан ничек алып ташлыйлар, ничек итеп халык яклавына ирешәләр, хокук тәртибен ничек саклыйлар?

3. Партиянең төп сайлаучылары нигезен яки революциянең хәрәкәтләндерүче көчләрен **кемнәр** тәшкил итә, кемнәр — каршы як, ә кемнәр көрәштәшләр сафында торалар, кемнәр җинаять кылалар һәм кемнәр алар белән көрәшәләр?

§1 (§ 25). Хакимият

Хакимият турында сөйләгәндә, без күбесенчә сәясәт хакында уйлыйбыз. Ничек кенә булмасын, һәрберебезнең көндәлек тормышына сәясәтнең кагылышы бар. Безгә кемгәдер буйсынырга туры килә, чөнки ул безнең өстән хакимияткә ия. Әти-әниләр, мәктәп укытучылары, милиционер, тренер кайвакытларда, телибезме, юкмы, безне үзләре уйлаганча эшләргә мәҗбүр итәләр. Һәм без буйсынабыз, чөнки аларның һәрберсе хакимияткә ия.

— Караңгы кичтә өч таза егет, каршыгызга чыгып, акчагызны бирергә мәҗбүр иткәндә, алар ***көч*** кулланалар.

— Бүлек җыелышында җитәкче, рәсми вәкаләтләренә таянып, сезгә шелтә белдергәндә, ***хакимияткә*** ия булуын күрсәтә.

— Алдагы көндә генә патша гаиләсе җәсәдләрен күмүдә катнашудан баш тарткан Россия президентын академик Д.С. Лихачев әлеге вакыйгада катнашырга күндерә икән, ул үз ***абруеннан*** файдалана.

Көч, хакимият һәм ***абруй — йогынты ясауның өч формасы***. Йогынты ясый алу бер кешенең яки кешеләр төркеменең башкалардан нәрсәдәдер *өстен торуын* күрсәтә. Физик сыйфатлар яки кораллар өстенлеге булган очракта *йогынты көч аша ясала*. Шулай ук дәрәҗәле эш урыны һәм социаль хәл буенча да өстенлек булырга мөмкин. Мондый өстенлек конституциядә, уставта, законда һәм традицияләр белән яклана. Бу очракта йогынты ясау *хакимиятле булудан файдаланып* тормышка ашырыла. Компетентлылык, белемлелек, әхлакый сыйфатлар, мәшһүрлек өстенлеге булуы да ихтимал. Биредә без *абруй, ягъни авторитет аша йогынты ясау* турында әйтә алабыз.

Йогынты ясауның өч ысулы арасында катлаулы мөнәсәбәтләр һәм бәйләнешләр яши. Алар кайвакытларда, инде югарыда әйтеп үтелгәнчә, гадәти рәвештә чагылыш табарга мөмкин, әмма мондый хәлләр бик сирәк була. Күбесенчә аларның үзара үрелеп гамәлгә ашырылуы күзәтелә. Әйдәгез, йогынты ясауның өч ысулы арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга тырышып карыйк.

> **КӨЧ** — башка кешеләрнең теләгенә каршы килеп, аларга үз ихтыярыңны тагу максатында физик тәэсир итү.

Бу очракта көч *мәҗбүри* йогынты буларак аңлашыла. Яшүсмерләрнең ишегалды компаниясендә һәрвакыт бер лидер була,

ул еш кына үз хакимлеген акылы һәм белеме белән түгел, ә көче белән урнаштыра. Мафия корал көчен файдалана. Монда куркыту, янау, шантаж, үтерүләр бергә үрелә.

> **ХАКИМИЯТ** — закон яки традицияләргә нигезләнеп йогынты ясау, икенче төрле әйткәндә, башка кешеләргә физик түгел, ә закон һәм гореф-гадәтләр кысаларында тәэсир итү.

Законнарга таянган тәртипләр күпчелек халык тарафыннан яклау табу сәбәпле, хакимияттәгеләрнең теләсә кайсы эш-гамәле закон һәм гореф-гадәтләргә каршы булмаса, халык өчен файдалы дип исәпләнергә тиеш. Хөкүмәтнең салымнар җыюы кемгәдер ошап бетмәскә мөмкин һәм ул алардан качу җаен эзли. Әмма халыкның күпчелеге үзенең әлеге йөкләмәсен төгәл үтәп килә, чөнки җыелган акчаларның җәмгыятьтәге социаль өлкәгә җибәрелүен аңлый.

Тарихи яктан хакимият көчкә караганда күпкә соңрак оеша. Ул аучылык һәм азык җыючылык белән шөгыльләнүче беренче кешеләр барлыкка килгәч, ягъни моннан 40–30 мең еллар элек формалаша. Антропологлар фикеренчә, нәкъ менә шул дәвердә чын мәгънәсендә кешелек җәмгыяте яралу турында сөйләргә мөмкин.

Тагын да соңрак, 6–5 мең еллар элек, беренче дәүләтләр барлыкка килгәч, *хакимият үсешендә яңа — дәүләти этап* башлана. Махсус кодексларда, хартияләрдә, конституцияләрдә беркетелгән законлы хакимият йөзләрчә мең һәм миллионнарча кешеләрне колачлый. Дәүләт барлыкка килү белән, хакимиятнең башкарма, закон чыгаручы һәм суд хакимиятләренә бүленүе күзәтелә, бу хәл җәмгыятьнең сәяси үсешендә гаять зур роль уйный.

Хакимият җәмгыятьнең сәяси институтына әверелә. Ул үз йогынтысын закон карарларында — король указларында, парламент законнарында, суд чыгарган карарларда, директор яки генерал боерыкларында һәм башкаларда чагылдыра. Дәү-

ләт җитәкчесе генә түгел, хәтта кечкенә генә оешма җитәкчесе дә, әгәр ул оешма законлы юл белән төзелгән икән, законлы хакимияткә ия була. Иң югары җитәкчеләр үз хакимиятләренең бер өлешеннән читләшәләр, ягъни үзләренә буйсынучыларга бүлеп бирәләр, соңгылары исә аны тагын да түбәнрәк баскычта торучыларга тапшыра алалар.

Менә шул рәвештә күп тармаклы *хакимият пирамидасы* барлыкка килә. Ул бары тик *башлыклардан* гына тора һәм бирегә *буйсынучылар* керми. Башлык — идарә итүгә кагылышлы карарлар чыгарырга һәм аларның үтәлешен таләп итәргә хокуклы вазифалы зат. Президент, министр, директор, бригадир — болар барысы да башлыклар, ягъни «башта, алда торучы» кешеләр.

Кешеләр башлыкларның боерыкларына аларны бик ошатканга яки физик мәҗбүр итү аркасында түгел, ә үзләренә билгеләнгән урыннан чыгып буйсыналар. Армиядә боерыклар хәрби устав белән законлаштырылган, һәм бу устав командирга башкаларның үз-үзләрен тотышын контрольдә тоту хокукын бирә. Боерыклар шәхси үтенеч буларак түгел, ә оешма структурасы белән каралган законлы таләп рәвешендә бирелә. Мәктәптә, оешмада, министрлыкта һ.б. мөнәсәбәтләр әнә шул рәвештә җайга салына.

Хакимият — көчкә караганда киңрәк төшенчә, чөнки ул көч кулланмыйча да тормышка ашырылырга мөмкин. Гәрчә аларның үзара үрелеп баруы ешрак күзәтелә.

Фән хакимиятне икътисади, социаль һәм сәяси проблемаларны хәл итү чарасы дип карый. Хакимияткә килгән демократик партия гомумхалык сайлаулары үткәрә, гражданнарның сәяси ирекләрен һәм хокукларын киңәйтә, матди хәлен яхшырта, җәмгыятьнең хокук тәртибен ныгыта. Әмма еш кына хакимият максатка әверелә, аны халык тормышын җиңеләйтү яки мөһим проблемаларны хәл итү өчен түгел, ә үз хәлләрен яхшырту һәм баю өчен кулга төшерергә омтылалар.

Чара буларак каралган хакимият һәм максат итеп куелган хакимият — төрле генә түгел, ә капма-каршы күренешләр.

Мөһим проблемаларны хәл итү чарасы булган хакимият, төрле сәбәпләр аркасында, үзмаксатка әверелә. Бу сәбәпләргә җитәкченең шәхси сыйфатларын кертергә мөмкин. Күпчелек тираннар балачактан ук бөтен дөнья өстеннән хакимлек итәргә хыялланганнар. Цезарь, Александр Македонский, Наполеон,

Гитлер кебек тарих агышын үзгәрткән күренекле эшлеклеләр — барысы да хакимлек итү ихтыяҗы зур булган көчле шәхесләр алар. Моннан тыш әле социаль шартлар да сәбәп булырга мөмкин. Сәяси партия үзе өчен тавыш җыйганда, аның күпсанлы вәгъдәләр бирүен, халыкның барлык проблемаларын хәл итәргә өметләндереп, аны үз ягына авыштыруын без бик яхшы беләбез.

Ә менә хакимиятне үз кулына алганнан соң, партия сайлау алды вәгъдәләрен шул мизгелдә үк оныта һәм, сәяси олимпта тору өчен, халыкны газапларга дучар итүче чаралардан да чирканмый: башка дәүләтләр алдында бурычка бата, меңнәрчә кешеләрне һәлак итүче сугышларга керә, җинаятьчелек белән көрәшми һ.б.

> **АБРУЙ**, ягъни **авторитет** (латинчадан auctoritas — хакимият, йогынты) киң мәгънәдә — җәмгыятьнең төрле сфераларында шәхеснең яки оешманың белемнәргә, әхлакый сыйфатларга, тәҗрибәгә нигезләнгән гомумтанылган йогынтысы; тар мәгънәдә — хакимиятне тормышка ашыруның бер формасы.

Әгәр дә сез дусларыгыз алдында акыллы, намуслы, принципиаль кеше буларак яки мәктәп администрациясе каршында алар мәнфәгатьләрен яклаучы буларак абруй казангансыз икән, сез хөрмәткә лаек бу сыйфатларыгызны югалтмаган очракта гына үз өстенлегегезне саклап кала аласыз. *Хөрмәт* — абруйның нигезе.

Йогынты ясауның өч формасын чагыштырып карасак, менә нәрсә аңлашылыр. Көч һәм абруй, ут һәм су кебек, бер-берсенә капма-каршы торалар. Гадәти тормышта алар үзара бәйләнми, аның каравы, криминаль тирәлектә бик яхшы ярашалар, чөнки, «законлы карак» башка кешеләргә тупас физик көче, аларның тормышына янавы белән йогынты ясаучы абруйлы затка әверелә. Әмма җитештерү өлкәсендәге, мәдәният һәм сәясәттәге абруйлы кеше бервакытта да физик көч кулланмый.

Урталыкта торган хакимият бу ике чиктәге күренешкә дә түземле мөнәсәбәт саклый. Ул физик көч белән дә, абруй белән дә яраклаша. Милицияне һәм армияне куллану дәүләтнең законлы рәвештә физик көчтән файдалануын күрсәтә. Әмма дәүләт җитәкчесе үзенең белемнәре һәм эшлекле сыйфатлары абруена таяна.

Шулай итеп, *көч* һәм *абруйны хакимиятнең ике чыганагы* дип исәпләргә мөмкин.

Кешеләр арасында мөнәсәбәтләр билгеле бер системага салынган, җитәкче һәм буйсынучылардан торган теге яки бу

дәрәҗәдәге (йогынтылы, өстенлекле, хакимияткә ия) хезмәт вазифаларына бүленеп яшәгән урында хакимият тә була. Хакимияткә ия затлар — иҗтимагый пирамиданың югары өлешендә, ә башкалар, хакимияттән мәхрүм булганнар, түбәндә урнашалар. Мондый тәртип *иерархик* тәртип дип атала.

> **ИЕРАРХИЯ** (грекчадан hieros — изге һәм arche — хакимият) — бербөтен берәмлек элементларының яки өлешләренең югарыдан түбәнгә таба урнашуы. Бу термин христиан чиркәве төзелешен сыйфатлау өчен файдаланыла; социологиядә исә — җәмгыятьнең, бюрократиянең социаль структурасын билгеләү өчен, оешма теориясендә идарә итү принцибын күрсәтү өчен кулланыла.

Теләсә кайсы иерархия *пирамида* рәвешендә күрсәтелә ала, анда өч төп баскыч — югары, урта, түбән баскычлар аерылып тора. Идарә итүче иерархиядә алар идарә баскычлары булсалар, социаль иерархиядә сыйныфлар булалар.

Җәмгыять шулай корылган — хакимият һәрвакыт *актив азчылык* кулында туплана. Әгәр ул пассив күпчелекнең үз режимын яклавы белән кызыксынмаса, аннан башка да яши алса, халык идарә итүгә кертелми. Ә инде хакимияттә торучылар демократия режимындагыча бары тик халык яклавы белән генә көчле булсалар, алар халыкны да идарә эшләренә җәлеп итәчәкләр. Әгәр дә алар моны эшләмәсәләр, демократларны бик тиз арада *олигархлар*, ягъни тар бер төркем мәнфәгатьләрен генә яклап хакимияттән файдаланучы бик бай һәм йогынтылы кешеләр кысрыклап чыгарачак. Олигархлар — демократларның куркыныч дошманнары. Менә шуңа күрә дә демократлар халык яклавына таянырга тиеш.

Кешенең табигате шулай корылган: пирамиданың югары очына менеп җиткәннәр башкалар белән өстенлекләрен бүлешергә теләмиләр. Абсолют монархия һәм диктатура әнә шуңа нигезләнә. Өлешсез калып та, хакимияткә ия булу теләген югалтмаган кешеләр, беренче мөмкинлек чыгу белән, переворот ясарга әзер торалар. Еш кына алар корольнең иң якын яраннары арасында була. Бөтендөнья тарихы раслаганча, хакимнең яраннары оештырган *сарай переворотлары* түбән массалар башлаган фетнәләргә һәм революцияләргә караганда ешрак кабатланалар.

Хакимият өчен көрәш, вакытлыча, дошманнарны берләш-

терә. Әмма гади халык яки фетнәчеләр төркеме үз максатларына ирешкәннән соң, эчке бәхәсләр һәм мөнәсәбәтләрне ачыклау башлана. Хакимият тирәсенә *оппозиция* чыга, ул хөкүмәтне яки президентны (корольне, патшаны, солтанны һ.б.) ничек булса да бәреп төшерергә хыяллана. Шулай итеп, хакимият өчен барган көрәштә дуслар тупланса да, аны бүлгәләгәндә, алар дошманнарга әвереләләр.

Хаким, ягъни идарәче, хакимиятне үзенең иң якын дусларыннан һәм көндәшләреннән күптөрле ысуллар белән сакларга тырыша. Ул хакимлеккә омтылучы көндәшләренең мәкерле эш-гамәлләре турында хәбәр итеп торучы әләкчеләрне, шпионнарны алар арасына җибәрә. Әледән-әле оппозиция рәтләрендә чистарту үткәрә. Мәсәлән, Иван Грозный боярларга карата шундый чаралар күрә. Ниһаять, үз хакимлеген ныгыту өчен, идарәче хакимияткә килүне чикләүче күп санлы законнар уйлап таба. Тәхет варислыгы турындагы закон иң ышанычлысы була, аның буенча тәхет бары тик король гаиләсе әгъзаларына гына тапшырыла ала.

Әмма ул хакимне революцион өернең корольләрне бәреп төшерерлек ярсуыннан һәм үзе генә идарә итәргә теләүче хакимнең амбицияләрен чикләүче парламентның закон чыгару адымнарыннан саклап кала алмый. Яңа заман тарихы парламент һәм король арасында барган бихисап көрәшләрне, ә кайвакытларда канкойгыч бәрелешләрне бик яхшы хәтерли. Тәхеткә көч кулланып үрелүләрдән саклау өчен көчле армия,

полиция һәм суд, ягъни физик көч куллануның законлаштырылган ысуллары хакимгә ярдәмгә киләләр.

Шулай итеп, без йогынты ясауның өч ысулын аерып алдык — *көч, хакимият, абруй*. Алар арасында хакимият кешеләргә йогынты ясауның иң куәтле һәм иң катлаулы ысулы булып тора.

---

[1] **Төшенчәләр:** *көч, абруй, хакимият, хакимият иерархиясе.*

---

[2] **Сораулар һәм биремнәр**

1. Кешелек үсешенең кайсы стадиясендә хакимиятләр бүленеше турында сөйләргә мөмкин һәм ни өчен?

2. Хакимият пирамидасы һәм иерархиясе нәрсә ул? Хакимиятле булу ихтыяҗы анда нинди роль уйный?

3. Актив азчылык һәм пассив күпчелек нәрсә ул? Алар арасындагы мөнәсәбәтләрне мәгълүм мисаллар өстендә анализлагыз.

***4**. Йогынты ясауның өч формасы — хакимият, көч һәм абруй арасындагы аермаларга анализ ясагыз.

***5**. Мәктәптә еш кына лидерлык һәм хакимият өчен барган яшерен яки ачыктан-ачык көрәшне күзәтергә мөмкин. Аның нинди максатларда алып барылуын аңлатыгыз. Бу көрәштә уңышка ирешү нәрсәгә бәйле?

***6**. Хакимият йогынты ясауның иң катлаулы һәм иң куәтле чарасы булып тора. Бу тезисны расларга яки кире кагарга тырышыгыз. Үз фикерегезне раслаучы мисаллар китерегез.

? Проблема. Хакимиятнең кайсы көчлерәк: көчкә таянганымы, әллә абруйга нигезләнгәнеме? Бәлки, мондый сорау кую дөрес түгелдер һәм ни өчен?

Практикум. Түбәндәге фикерләрдә нәрсәдер буталган:

1. Конституциядә, уставта, законда беркетелгән һәм традицияләр белән якланган дәрәҗәле эш урыны һәм социаль хәл өстенлеге — көч аша йогынты ясауның үрнәге ул.

2. Физик сыйфатлар һәм кораллар өстенлеге — абруй аша йогынты ясауның үрнәге.

3. Сөйкемлелек, компетентлылык, белемлелек, әхлакый сыйфатлар, мәшһүрлек өстенлеге — хакимият ярдәмендә йогынты ясауның үрнәге.

§ 1 (§ 25) текстын белсәгез, бу каршылыклар йомгагын тиз сүтә алырсыз.

---

[1] Параграф ахырындагы төшенчәләр укытучы алар белән эш оештыра алсын өчен аерып бирелде.

[2] * белән күрсәтелгән сораулар аеруча катлаулы дип исәпләнелә.

§ 2 (§ 26). Дәүләт

Алдагы параграфта карап үтелгән хакимият тулысынча дәүләттә гәүдәләнеш таба. Ул сәяси хакимиятне яулауның һәм кулда саклап калуның гаять зур, күп тармаклы, катлаулы төзелешле механизмыннан гыйбарәт.

Дәүләт җәмгыятьнең сәяси системасының мөһим состав өлешен тәшкил итә. **Җәмгыятьнең сәяси системасы** *билгеле бер сәяси максатларны күз алдында тотучы дәүләтне, партияләрне, профсоюзларны, оешмаларны, хәрәкәтләрне колачлый.* Җәмгыятьнең сәяси үсешендә чиркәү дә билгеле бер урын алып тора.

Көндәлек тормышта без дәүләт белән минут саен очрашып торабыз. Ул законнар чыгара, массакүләм мәгълүмат чараларын, армияне, судны һәм полицияне тәэмин итә, паспорт һәм визалар бирә, укытучыларга яки врачларга хезмәт хакы түли, туган илебез чикләрен саклый, контрабанда белән көрәшә, пенсия һәм социаль ярдәм бүлеп бирә, мәдәният өлкәсенә булышлык күрсәтә һәм башка күпсанлы вазифалар башкара.

«Дәүләт» термины гадәттә ике төрле мәгънәдә кулланыла.

Киң мәгънәдә алганда, дәүләт ил һәм шул территориядә сәяси яктан тупланып яшәгән халык мәгънәсенә тәңгәл килә. Бу мәгънәдә әйткәндә, мәсәлән, Россия, Америка, Германия дәүләте һәм алар гәүдәләндергән бөтен бер җәмгыятьне күз алдында тоталар. Чама белән XVII гасырга кадәр дәүләт киң мәгънәдә генә аңлатыла һәм җәмгыятьтән аерып күрсәтелми.

Тар мәгънәдә исә дәүләт җәмгыять өстендә торучы югары хакимият оешмасын гына белдерә. Бу очракта дәүләт һәм җәмгыятьне төгәл аерып кую кирәк. Дәүләтнең шартнамәле теориясен тудырган XVIII гасыр француз мәгърифәтчеләре тарих таңында кешеләр берничек тә оешмага берләшеп яшәмәгәннәр дип исәплиләр. Әмма тормыш аларны башта җәмгыятькә оешырга, ә аннары, үзләрен тышкы дошманнардан һәм эчке җинаятьчеләрдән саклау өчен, дәүләт төзергә мәҗбүр иткән.

Борынгы дәүләтләр: фактлар мозаикасы

1. Хеттлар — һинд-европа чыгышлы иң борынгы халыклар. Б.э.к. якынча 1450 елда хеттлар Яңа патшалык төзиләр. Дәүләт башлыгы булып монарх тора. Ул иң югары хәрби, гражданлык һәм

суд хакимиятен гәүдәләндерә һәм баш дини авторитет та була. Ирекле гаскәриләр үзенә күрә аристократияне тәшкил итәләр. Алар махсус җыелышка — панкуска берләшәләр, хәтта яңа монархны сайлау да әлеге панкуска бәйле була.

2. Б.э.к. 730 елда Европада төзелгән Фракия кабиләләр союзы белән югары юлбашчы җитәкчелек итә, ыруг-кабилә аксөякләре аның тирәсендә берләшәләр. Ул югары сәяси һәм дини хакимияткә ия була, сугышлар вакытында югары гаскәр башлыгы да булып тора. Аксөякләр өстенлекләрдән файдаланганнар: аларның үз яшәү кагыйдәләре, киемнәре, бизәнү әйберләре, ризыклары, башкалардан үзгә тормыш рәвеше булган. Гади терлекчеләр һәм игенчеләр — күпсанлы авылларда, юлбашчылар һәм аларның яраннары ныгытылган шәһәрлекләрдә (фракиялеләр шәһәрләр төземәгәннәр) яшәгәннәр.

3. Патша Ашшурбанипал (б.э.к. 680–627 елларда идарә иткән) Ассирия башкаласы Ниневиядә искиткеч матур рельефлар белән бизәлгән гаҗәеп гүзәл Төньяк сараен төзеткән һәм анда шумерлар, аккадлар, вавилонлылар, ассирияләләр текстларының нөсхәләре төшерелгән 30000 чөй язулы балчык таблицалардан торган бик зур китапханәсен урнаштырган. Алар арасында археологлар патша указлары һәм хроникалар, медицинага һәм математикага кагылышлы текстлар, география һәм ботаника белешмәләре, халыкара шартнамәләр, күрәзәлек язмалары һәм риваятьләр, дипломатия хатлары һәм хуҗалык эшләренә кагылышлы язмалар таптылар.

4. Ассирия патшасы Саргон II (б.э.к. 722–705 елларда идарә иткән) үзеннән алда хакимияттә булган патшаларның басып алу сәясәтен дәвам иткән. Ул Израиль патшалыгын җимергән (б.э.к. 722 ел), Мисырны җиңүгә ирешкән (б.э.к. 720 ел), ә Фригия, Кипр һәм Урарту дәүләтенең бер өлешен үзенә салым түләргә мәҗбүр иткән. Аның улы Синахериб (б.э.к. 705–681 елларда идарә иткән) Финикиянең порт шәһәрләре Сидон һәм Яффаны яулап алган, Иудеяне буйсындырган (б.э.к. 701 ел), штурм белән Вавилонны алган һәм җимергән (б.э.к. 689 ел). Ассирияләләр, басып алынган территорияләрдә үзәкләштерелгән катгый идарә системасын саклау өчен, массакүләм террор системасы үткәргәннәр.

5. Асархаддон заманында (б.э.к. 681–667 елларда идарә иткән) Ассирия иң зур куәткә ирешкән. Б.э.к. 671–664 елларда ул Нил дельтасын басып алган һәм Мисыр хакимиятенә үз кешесен

куйган. Нәтиҗәдә империя Нилдан Каспийга һәм Клиниядән Фарсы култыгына кадәр җәелгән. Ассирия крестьяннары һәм буйсындырылган илләрнең халыклары гаять зур армияне һәм империянең идарә аппаратын тәэмин итеп торганнар. Чыгымнарны, мәсәлән, сарай төзелеше өчен тотылган акчаны каплау өчен, яулап алу сугышлары алып барылган. Хәрби чыгымнар торабара империяне какшаткан.

Чыганак: «Кешелек хроникасы» («Хроника человечества») энциклопедиясе.

Хәзерге заман фәнендә ***дәүләт*** тар мәгънәдә ***билгеле бер территориядә югары хакимияткә ия оешма, оешмалар системасы*** буларак аңлашыла. Ул башка сәяси оешмалар — партияләр, профсоюзлар һ.б. белән янәшә яши. Башкача әйткәндә, дәүләт — җәмгыятьнең сәяси системасындагы үзәкләштерелгән институт ул, әмма ул бердәнбер булмыйча, аның белән янәшә башка институтлар да бар. Үткәндәге һәм хәзерге дәүләтләргә түбәндәге ***гомуми (төп) сыйфатлар*** хас:

1. *Бердәм территория.* Ул башка илләр тарафыннан танылган дәүләт чикләре белән күрсәтелә.

2. *Территория белән идарә итүче бердәм система.* Ул хакимиятләр бүленеше принцибына нигезләнә һәм аның составына тармакланган дәүләт чиновниклары аппараты керә.

3. *Бердәм законнар системасы.* Ул барлык гражданнар тарафыннан илнең бөтен территориясендә дә үтәлүче Конституциядә теркәлгән.

4. *Легаль көч куллануга* яки физик мәҗбүр итүгә *монополия.* Ул армиягә, милициягә (полициягә), куркынычсызлык хезмәтенә, суд һәм прокуратурага таяна.

5. *Салымнар җыю хокукы.* Бу салымнар күпсанлы хезмәткәрләрне тәэмин итүгә һәм дәүләтнең оборона, икътисади һәм социаль сәясәтен финанслауга җибәрелә.

6. *Дәүләт әгъзасы булу мәҗбүрияте*, ягъни *гражданлык.* Партия һәм профсоюздан аермалы буларак (аларда әгъза булып тору ирекле), кешегә гражданлык хокукы тугач ук бирелә.

7. *Халыкара оешмаларда, сөйләшүләрдә һ.б. җәмгыять исеменнән вәкаләтле булу.*

8. *Суверенитет*, ягъни билгеле бер территориядә югары хакимияткә ия булу. Җәмгыятьтә хакимиятнең күп төрләре яши, әмма дәүләт иң югары хакимияткә ия булырга тиеш,

аның карарлары бөтен гражданнар өчен дә мәҗбүри. Бары тик ул гына законнар чыгару хокукына ия.

Илнең барлык яки бер өлеш территориясенә таралган суверен хакимият дәүләтнең иң мөһим сыйфатларыннан берсе.

СУВЕРЕНИТЕТ (немецча Souveranitat, французчадан souverainete — югары хакимият) — дәүләтнең тышкы эшләрдәге бәйсезлеккә һәм эчке эшләрдә югары хакимияткә ия булуы.

Суверенитетны хөрмәт итү — хәзерге халыкара хокукның һәм халыкара мөнәсәбәтләрнең төп принцибы. Ул БМО Уставында һәм башка халыкара актларда теркәлгән. Суверенитет — мөстәкыйль дәүләт төзергә теләгән һәр халык омтылган төп кыйммәт ул. СССР таркалганнан соң 90 нчы еллар башында «суверенитетлар парады» дип аталган процесс булды. Элекке союздаш республикалар бер-бер артлы дәүләт бәйсезлеген игълан иттеләр. Дөньяның сәяси картасында тиз арада 10 нан артык яңа дәүләт барлыкка килде.

Дәүләтнең **суверенлыгы** (югары хакимият плюс бәйсезлек) аның бөтен җәмгыятьне тулаем гәүдәләндерү хокукына ия булуында, дәүләт тарафыннан норматив актлар, шул исәптән җәмгыятьнең барлык әгъзалары тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган законнар чыгаруда, суд эшчәнлеге алып баруда чагылыш таба. Дәүләт — җәмгыятьнең һәр әгъзасын мәҗбүр итүгә сәләтле көч буларак өйрәнелә.

Әлеге сыйфатлар дәүләтнең башка оешмалардан, мәсәлән, шәһәр мэриясеннән, сәяси партиядән, профсоюзлардан үзгә булуны күрсәтә. Бу оешмалар дәүләтнекенә охшаш сыйфатларга ия булсалар да, аның башка сыйфатлары алар өчен хас түгел.

Дәүләт эшчәнлегенең эчтәлеге һәм характеры турында аның *функцияләре* сөйли. Алар эчке һәм тышкы функцияләргә бүленәләр.

Дәүләтнең эчке функцияләре: җитештерүнең гамәлдәге ысулын, икътисади һәм социаль системаны яклау; сыйнфый дошманнарны буйсындырып тоту (капма-каршы мәнфәгатьле сыйныфлар булган җәмгыятьләрдә); икътисад белән идарә итүдә катнашу; иҗтимагый тәртип һәм дисциплина саклау; социаль мөнәсәбәтләрне җайга салу; мәдәни-тәрбияви, идеологик эшчәнлек һ.б.

Дәүләтнең тышкы функцияләре: халыкара аренада башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрдә үз (әлеге дәүләт) мәнфәгать-

ләрен яклау, ил оборонасын тәэмин итү, башка дәүләтләр белән уңай мөнәсәбәтләр үстерү, ике як өчен дә янәшә тыныч яшәүгә нигезләнгән файдалы хезмәттәшлек урнаштыру.

Дәүләт тарихи аренада моннан 5–6 мең ел элек барлыкка килгән һәм шуннан бирле җәмгыятьнең мөстәкыйль институты буларак яши. Дәүләт объектив булган түбәндәге сәбәпләр аркасында барлыкка килгән.

Халык урнашуының тыгызлыгы — дәүләт барлыкка килүнең *беренче сәбәбе*. Ыруглык җәмгыятендә 40–60 кешелек төркемнәр, азык эзләп, зур территорияләрдә таралганнар. Алар товар алмашу, берәрсен башка төркем кешесенә өйләндерү, үз территорияләреннән чит-ятларны кысрыклап чыгару ихтыяҗы туганда гына очрашканнар. Галимнәр ул заманнарда Җирдә 5–6 миллионлап кеше яшәгән дип исәплиләр, ә бүген исә – 6 млрд чамасы кеше яши. Ике санны чагыштырып карыйк. Тулы булмаган 10–15 мең ел эчендә кеше саны мең тапкыр арткан. Әгәр дә беренче кешенең 2–3 млн ел элек барлыкка килүен искә төшерсәк, бу бик аз вакыт.

Кешедә иң гади хезмәт кораллары булганда, аңа үзен туендыру өчен бик зур территория кирәк. Мәсәлән, 40–60 кешедән торган аучылар һәм азык җыючылар төркеме өчен берничә йөз квадрат километр җир таләп ителә. Даими бәрелешләр, еш кабатланган ачлык һәм үз территорияләрен саклау өчен бер төркемнәрнең икенчеләре белән берләшүе котылгысыз хәлгә әверелә. Бер халыкларның икенчеләре тарафыннан яулап алынуы Җир шарының әле бер, әле икенче төбәгендә тиз арада кабиләләрнең хәрби союзлары төзелүгә китерә.

Икенче сәбәп — тышкы агрессиядән һәм эчке ызгыш-талашлардан курку. Кайбер галимнәр исәпләвенчә, кешеләрне дәүләт төзүгә дошман агрессиясеннән курку, тормыш һәм милек өчен борчылу этәрә. Әмма илнең үз эчендәге юлбасарлар һәм җинаятьчеләрдән янаган куркыныч та көч куллануга һәм тәртип урнаштыруга сәләтле дәүләткә берләшү өчен җитди сәбәп булган. Дәүләт, орбитр буларак, бөтен бәхәсләрне объектив хәл итә һәм барлык кешеләр өчен дә гомуми законнар чыгара ала. Инде антик заманнарда ук дәүләт дигәндә җәмгыять өстендә торучы, әмма аның күзәтүе астында булып, аңа хезмәт итүче хакимият төзелешен аңлыйлар. Дәүләт чиновниклары кешеләрнең хезмәтчеләре буларак каралган. Латин телендә министр сүзе дә җитәкче түгел, ә хезмәтче мәгънәсен аңлата.

Көч факторы дәүләт барлыкка килүнең *өченче* сәбәбе булып тора. Хәзерге базар җәмгыятенә күз салыгыз. Һәр фирма, ә аларның саны миллионнарча, сакчылар, күзәтүче һәм тыңлаучы аппаратура, сигналлы һәм компьютер системалары белән чолгап алынган. Бу фирмаларны тирән чокырлар белән дә әйләндереп алсалар, тулысынча феодаль җәмгыятькә тәңгәллек күзәтелер иде. Мондый тәңгәллек күп нәрсәләргә аңлатма кертә. Урта гасырлар Европасы күпсанлы феодаль кенәзлекләрдән тора. Аларның һәрберсендә хосусый сак армиясе, үз флагы, гербы, хөкүмәте, теле, мәдәнияте була. Шәһәрләр һәм замоклар, авыллар һәм тирә-як — сак астында. Сәүдәгәрләр дә юлга сак астында чыгалар, һәм еш кына үзләре үк профессиональ сугышчылар булалар. Халыктан салымны коралланып җыялар, бәхәсләр кылычлар ярдәмендә хәл ителә, кылыч белән йоклыйлар да, ашыйлар да, хәтта җирне дә корал аскан килеш сөрәләр.

Европаның барлык корольләре бер-берсенең профессиональ солдатларын яллыйлар яки үз якларына авыштыралар. Дөньяда бар нәрсәгә дә корал ярдәмендә ирешәләр: гүзәл ханымнар күңелен яулыйлар, үз территорияләреннән мул салым җыялар, чит территорияләрдән зур контрибуция алалар. Хәрби отряд-



лар өзлексез сәүдә барышын һәм салымнарның даими төстә түләнүен тәэмин итеп торалар.

Икътисади законнар сәяси проблемаларны хәл итүнең рациональ формаларын уйлап табуга этәрә. *Хәрби кампания* дә эшлекле чараның бер төре булып тора. Чиста табыш гади халыктан җыеп алынган ясакның армияне тоту өчен тотылган чыгымнардан соң калган өлешеннән гыйбарәт була. Армия — төп эш көче. Үзен тәэмин итеп торуны аклау һәм табыш китерү өчен, ул даими төстә хезмәт итеп торырга тиеш. Әгәр аның халыкка йөрүләре даими булмаса, табыш та даими рәвештә керми. Әгәр дә югары хакимият билгеле бер территория өстеннән тулысынча монополия урнаштыра һәм даими төстә ясак җыя икән, армия тотуга чыгымнар кими. Бер үк вакытта гади халыкның хәле дә яхшыра. Эш шунда ки, даими төстә җыйган очракта һәр хуҗалыктан салымны азрак алалар, аның үсеше өчен мөмкинлек калдыралар, әлеге хуҗалыкларның хәлен кайгырталар, чөнки киләчәктә дә алардан салым җыярга кирәк була. Бу турыда хәтта Россия рэкетирлары да бик яхшы беләләр. Даими рәвештә алынган салымнарның күләме төрле сеньорлар тарафыннан җыелган һәм халык тарафыннан начар кабул ителгән салымнарга караганда, гадәттә, кимрәк була. Менә шуңа күрә дә ил халкы үз хакимиятен зур территорияләргә җәелдерүче көчле дәүләт булуы белән кызыксына.

Шулай итеп, дәүләт формалашу икътисади ниятләргә барып тоташа. Көчле армиясе булган хаким үзенә буйсынган территориядән салымнарны бик тиз һәм җиңел җыя алган, әлеге салым чыганакларына дәгъва итүче удел кенәзләрен, юлбасарларны, чит дәүләтләрне, ягъни теләсә кайсы конкурентларын үз юлыннан алып ташларга сәләтле булган. Олы юлда талаучы юлбасарлар, хәзерге рэкетирлар, салымнардан качучы эшмәкәрләр — болар барысы да салым җыюда дәүләтнең конкурентлары, димәк, аның дошманнары. Аларның кайберләре физик көч белән, ә кайберләре юридик законнар ярдәмендә юк ителә.

Чынлыкта дәүләт — законлы көч куллануга монополия ул. Көч куллану дәүләт Конституциясендә беркетелгән булса, ул законлы дип исәпләнә; Конституциядә түбәндәгеләр теркәлгән: бу территориядә дәүләт тарафыннан вәкаләтләр бирелгән махсус органнар, аерым алганда, милиция (полиция) һәм армия генә физик көч куллану хокукына ия. Көчле дәүләт үз монополиясен саклый, моннан исә гади халык җәфа чигә.

Дәүләт монополиясенең югарыда әйтеп үтелгән ике төреннән тыш тагын бик күп төрләре бар. Мәсәлән, сүз ирегенә монополия. Бу очракта дәүләт җәмгыятьтәге әхлак кагыйдәләрен бозучы порнографик әдәбиятны, милләтара каршылыкка китерүче әдәбиятны (мәсәлән, фашизмны яклаучы әдәбиятны) тыю хокукына ия. Шулай ук таможня пошлиналарына, алкогольгә һәм тәмәкегә, тозга һәм башкаларга монополияләр хөкем сөрә. Россия хөкүмәте алкоголь җитештерүне һәм сатуны күләгәдәге эшкуарларга тапшырганнан соң, казна дистәләрчә млрд доллардан колак какты. Чөнки бу өлкәдәге чиста табыш 2000 % тәшкил итә. Революциягә кадәр һәм совет заманында «сәрхуш акчалар» дәүләт табышының өчтән бер өлешен тәшкил итә иде.

Гомуми монополияләргә дәүләтнең шәхси өлкәгә караган монополияләре дә өстәлә. Алар дәүләт хезмәтләренә тарала һәм дәүләтне генә түгел, чиновникларны да баета. Дәүләт өйләнешү һәм бала туу турындагы таныклыкларны теркәү, аерылышу барышын оештыру, варислык милеген алу хокукын раслау, судка тапшырган шикаятьне кабул итү һ.б. өчен пошлина ала. Бар җирдә дә өлгер чиновниклар шәхси характердагы монополияләрне генә түгел, гомумдәүләт монополияләрен (мәсәлән, таможня җыемын) дә үзләре өчен җим чыганагына әверелдерәләр. Хокук саклау органнары таможня хезмәте өстеннән контрольне киметсәләр, чиновникларга биргән ришвәт хисабына чик аша наркотиклар, корал, алкоголь һәм башка товарлар үтеп керә, ә алар дәүләт бюджетын тулыландыруда катнашмыйлар һәм илгә зур зыян китерәләр.

Төшенчәләр: *дәүләт, суверенитет, суверенлык, дәүләт функцияләре, дәүләт монополиясе.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Җәмгыятьнең сәяси системасы нәрсә ул? Дәүләтне җәмгыятьнең сәяси системасының состав өлеше буларак характерлагыз.

*2. Ни өчен дәүләт җәмгыятьнең социаль яки икътисади өлкәсенең состав өлеше булып тормый?

3. Нинди сәбәпләр дәүләт барлыкка килүгә һәм ныгуга китергән?

4. Дәүләтнең гомуми сыйфатларын тасвирлагыз.

*5. Дәүләт сыйфатларын беренче кисәктә тасвирланган җәмгыять сыйфатлары белән чагыштырыгыз. Алар арасында нинди уртаклык бар? Ә нәрсә белән аерылалар?

6. Дәүләт функцияләре нәрсәдән гыйбарәт? Ни өчен алар эчке һәм тышкы функцияләргә бүлеп карала? Сез аларның ике төренә дә мисаллар китерә аласызмы?
7. Дәүләт барлыкка килүдә көч куллануның роле нинди?
***8.** Ни өчен дәүләтнең көч куллануы законлы дип карала?
9. Дәүләт монополиясе нәрсәдә чагылыш таба? Дәүләт монополиясенең барлык төрләрен санап чыгыгыз.
***10.** Уйлагыз, дәүләт кайсы монополияләрдән тыш яши алмас иде? Үз фикерегезне дәлилләгез.

? Проблема. Кешелек киләчәктә дәүләттән башка яши алырмы һәм ничек итеп?
«Идеаль дәүләт» бармы һәм ул нинди?

Практикум. Түбәндә санап үтелгән монополияләрнең кайсылары дәүләткә карамый?
1. Законлы көч куллануга монополия.
2. Сәяси оешмалар төзүгә монополия.
3. Сүз ирегенә монополия.
4. Җитештерү эшчәнлегенә монополия.
5. Кыйммәтле кәгазьләргә монополия.
6. Таможня пошлиналарына монополия.

Җавабыгызны нигезләгез.

§ 3 (§ 27). Милли дәүләт төзелеше

Дөньяда 200 гә якын дәүләт һәм 5 меңгә якын этнос бар, шуларның берничә йөзе милләт булып санала. Хәзерге Россия составында 100 дән артык этнос, шул исәптән 30 милләт яши. Бу саннарны чагыштырып карасак, барлык милләтләрнең дә дәүләте булмавы аңлашыла, гәрчә аларның күпчелеге дәүләтле булырга омтылсалар да.

Дөнья бергәлегендә ике капма-каршы тенденция күзәтелә:
милләтләрнең берләшүе,
милләтләрнең аерымлануы.

Беренче тенденция Европаның яңа тип конфедерация — *Европа Союзы (ЕС)* кысаларында берләшүендә ачык чагылыш таба. Ул 1993 елда Маастрихт шартнамәсе буенча Европа бергәлекләренә берләшкән 12 ил базасында төзелә — аңа Бельгия, Бөекбритания, Германия, Греция, Дания, Ирландия, Испания, Италия, Люксембург, Нидерланд, Португалия, Франция

керәләр. 1994 елда ЕСка Австрия, Норвегия, Финляндия һәм Швециянең керүе турындагы килешүгә кул куела. Бүгенге көндә Европа Союзы 16 дәүләтне берләштерә[1]. ЕСның үз парламенты һәм Министрлар советы бар. Бердәм Европа үсешенә юнәлдерелгән шартнамә сәяси, икътисади һәм валюта союзы төзүне дә, ягъни «чикләрсез Европа» төзүне дә, бердәм эчке базар формалашуның тәгәлләнүен — товарлар, хезмәт күрсәтүләр, капитал һәм кешеләрнең ирекле күчеп йөрүләренә киртәләрне бетерүне дә күз алдында тота. ЕС илләре тышкы сәясәт һәм куркынычсызлык өлкәсендә, эчке икътисади сәясәтнең төп юнәлешләрендә уртак курс үткәрергә, әйләнә-тирә мохитне саклау, җинаятьчелеккә каршы көрәш мәсьәләләрендә, юстиция өлкәсендә сәясәтне үзара яраклаштырырга йөкләмә алдылар. Бердәм Европа гражданлыгы формалашып килә. Европа валюта институты һәм Европа үзәк банкы төзелә, 1999 елда бердәм валюта — евро кертелде һәм бердәм акча-кредит сәясәте үткәрелә башлады. Евро банк исәп-хисапларында һәм акча күчерүләрендә кулланыла, ә 2004 елдан ул милли валюталарны алыштырды.

2000 елның декабрь башында Ниццада (Франция) ЕС илләре башлыкларының очрашуы булып узды. Җитәкчеләр ЕСның яңа меңьеллыктагы эшчәнлеге турында, аерым алганда, бергәлек илләрен көньякка һәм көнчыгышка киңәйтү һәм тиз арада җавап кайтарырлык хәрби көчләр булдыру һ.б. (барлыгы 54 пункт) турындагы Хартиягә кул куйдылар. Киңәшмәдә ЕСка керүне дәгъва итүче 13 ил вәкилләре дә катнашты, алар арасында Балтия илләреннән килүчеләр дә бар иде.

Икенче тенденция СССР, Югославия һәм кайбер башка илләрнең таркалуына китерде. Моны *сепаратизм* дип тә атыйлар.

СЕПАРАТИЗМ (латинчадан separatus — аерылган) — бүленүгә, аерымлануга омтылу.

Милләтләрнең аерымлануы тыныч һәм хәрби юл белән барырга мөмкин. Ешрак икенче юлны сайлыйлар. Милли азатлык сугышлары һәм милләтара конфликтлар тыныч булмаган аерымлану формасы булып торалар. Әлеге юллар арасында сый-

[1] Мәгълүмат 2004 ел башына карый. Соңгы вакытта Европа Союзына яңа әгъзалар (илләр) өстәлә. — *Ред.*

фат чикләрен билгеләү җиңел түгел. Әмма шуны әйтергә мөмкин: сугышлар бер милләт икенчесен буйсындырган очракта, ә конфликтлар кайчандыр тыныч кына берләшкән, ә хәзер берсе аерымланырга теләгән халыклар арасында килеп чыга.

Беренче тенденция — милләтләрнең берләшүгә омтылуы — үзәкләшкән дәүләтләр төзүгә, ә икенче тенденция аларның таркалуына китерә.

Үзәкләшкән дәүләтләр — хәзерге заманда дәүләтчелекнең төп формасы. Алар еш кына *җирләрне туплау* аша төзелә. Ике процесс та — үзәкләштерү һәм туплау — бербөтеннең ике өлешен тәшкил итәләр.

X гасырда *Германия* короле һәм Изге Рим империясе императоры Бөек Оттон I этник һәм сәяси яктан таркау дәүләтне берләштерү белән шөгыльләнә. Ул ярты Европаны диярлек басып ала һәм Эльба белән Одер елгалары арасында яшәүче халыкларга ясак сала. Шул ук X гасырда *Дания* идарәчеләре дә җирләр туплау белән шөгыльләнәләр. Беренче тапкыр илне конунг Карт (Старый) Горм (920–940) берләштерә, ул, викинглар авылы Хедебюны үзенә буйсындырып, Дания дәүләте территориясен Эйдерга кадәр киңәйтә. Скандинавиянең башка илләрендә дә вак корольлекләр көчле идарәчеләр хакимияте астында берләшәләр, ләкин аларның үлеменнән соң яңадан таркалалар. *Норвегиянең* шактый өлешен үзенә буйсындырган беренче конунг Харальд Гүзәлчәч (Прекрасноволосый) була. *Швециядә* бердәм дәүләт X–XI гасырлар чигендә Вестфольддагы Инглинглар нәселеннән чыккан Олаф Шетконунг заманында барлыкка килә. Король титулын алган Кыю Болеслав I нең (992–1025) *Польша* җирләрен туплау буенча күп елларга сузылган тырышлыгы да уңышлы тәгалләнә. Болеслав 33 ел идарә итү дәверендә Польша җирләрен берләштереп бетерә. *Италия* белән *Германия* дә, Руська караганда соңрак булса да, җирләрен туплап бетерәләр. Алар XIX гасырның соңгы чирегендә генә үзәкләшкән дәүләтләргә әвереләләр.

Русьта җирләрне туплау җиңел генә бармый. Монда *ике этапны* аерып күрсәтергә мөмкин: 1) Борынгы рус дәүләте периоды, 2) Мәскәү патшалыгы периоды. *Беренче этап* 882 елда Киевта хакимияткә Рюриковичларның варяглар династиясе урнашып, борынгы рус җирләре бердәм дәүләткә берләшкәч башлана. Скандинавиядән варяглар (викинглар) килер

алдыннан Борынгы Русь җирләрендә берничә вак кенәзлек була.

Бераз соңрак, феодаль таркаулык чорында, идарәче кенәзләрнең туганнары арасында каршылыклар башлана, дәүләт таркала һәм монгол-татар гаскәрләре өчен ул җиңел табышка әверелә. Җирләрен эзлекле рәвештә бердәм куәтле йодрыкка туплый барып, Русь 300 ел буе читләр изүе астында яши. Монда да, Европадагы кебек үк, үзәкләшкән дәүләт туплауның хәрби һәм тыныч юллары эшкә җигелә.

Җирләр туплауның *икенче этабы* 1328 елда башлана. Бу елда Мәскәү кенәзе Иван Калита Тверьдә ясак җыючы баскакларга каршы халык күтәрелешен бастыра һәм шуның өчен Алтын Урда ханы аңа Владимир җирендә бөек кенәзлек итү һәм рус җирләреннән ясак җыю хокукын биргән ярлык тапшыра. Шуның белән Русьның Алтын Урдага бәйлелеге кимүе һәм Мәскәүнең күтәрелүе башлана. Иван Калита заманнарында нәкъ менә Мәскәү кенәзләре җирләрне Мәскәү тирәсендә туплый башлыйлар. Бераз соңрак бөек Мәскәү кенәзе Иван III удел кенәзлекләрен бетерә һәм Төньяк-Көнчыгыш Русьның күпчелек өлешен Мәскәү хакимияте астында берләштерә. Торабара Ярославль, Ростов, Рязань, Тверь һәм Новгород шәһәрләре дә Мәскәүгә буйсыналар. Иван III Урдага ясак түләүдән баш тарта һәм Русьта монгол-татар изүенә чик куя. Шулай итеп, рус дәүләтен үзәкләштерү аның сәяси бәйсезлек алуы белән бер үк вакытта бара.

Үзәкләшкән дәүләтләр — *тарихи яктан дәвамлы процессның соңгы этабы ул. Алар гаять зур киңлекләрне билиләр, әлеге дәүләтләрдә күпсанлы халык яши, коралләну югары дәрәҗәгә күтәрелә, төгәл оештырылган һәм күп тармаклы дәүләт идарәсе аппараты эшли.* Мондый дәүләтләрне ***державалар*** һәм ***империяләр*** дип атыйлар. Үзәкләшкән дәүләтнең уңай да, тискәре дә яклары була. Ул илне көчле дошманнар һөҗүменнән саклый һәм халыкны коллыктан, юк ителүдән коткара. Бары тик шундый идарә формасында гына ил халкы үзен бербөтен итеп тоя башлый һәм дөньякүләм танылуга ирешә. Әмма бу бөеклек ил халкы җилкәсенә салым йөге булып өелә һәм хәерчелек, сүз ирекен чикләү яки бетерү белән яный. Бер үк вакытта бөек тә, бай да булуга халыклар бик сирәк ирешәләр.

Үзәкләшкән дәүләтне кайвакыт ***милли*** дәүләт дип атыйлар. Алар арасында охшаш һәм аермалы яклар бар. Борынгы Мисыр һәм Вавилон дәүләтләре, һичшиксез, үзәкләшкән эре дәүләтләр булалар. Әмма ул вакытларда милләтләр әле формалашып җитмәү сәбәпле, аларны милли дәүләтләр дип исәпләп буламы соң?

Гомуммилли, яки ***милли дәүләт*** — *үзәкләшкән дәүләтнең тарихи яктан иң соңгы формасы ул*. Аның соңгы форма булуына милләтләрнең бары тик капитализм чорында гына формалашып җитүе йогынты ясый, ә капитализмның беренче яралгылары Европада якынча XV гасырда күренә башлый, ә иң өлгергән формасына ул XIX гасырда гына ирешә. Нәкъ шул вакытта Италиядә һәм Германиядә җирләрне туплау тәгәлләнә һәм шуның нигезендә милли дәүләтләр формалаша.

Милли дәүләт бер милләт яшәгән җирләрне үзәкләштерү хисабына төзелә. Сүзнең тәгәл мәгънәсендә әйтсәк, милли дип бары тик бер милләтле дәүләтне генә аңларга кирәк. Анда башка милләтләр һәм халыклар да яшәргә мөмкин, әмма алар икенче урынны гына алып торырга тиеш. Хәзерге Германиядә күп милләтләрнең вәкилләре яши, әмма алар җәмгыятьтә төп урынны алып торган немец этносы тирәсендә яшәүчеләр буларак кына каралалар. СССР бер вакытта да бер милләтле дәүләт булмады, чөнки аның территориясендә 100 дән артык милләт яшәде. Ул күп милләтле дәүләт иде. *«Милли дәүләт»* һәм *«күпмилләтле дәүләт»* төшенчәләрен аера белү зарур.

Үзәкләшү күпсанлы территорияләрнең уртак үзәк тирәсендә туплануын гына белдерә. Бу — дәүләтнең территориаль-административ һәм өлешчә сәяси билгесе. Әмма берничек тә этник билгесе түгел. Әгәр дә аның барлык территориясендә бер генә милләт яки бик якын этнослар яшәсә, без үзәкләшкән дәүләтне шулай ук милли дәүләт дип тә атый алыр идек.

Милли дәүләт булып яшәү мәсьәләсе беренче карашка бик гади генә күренсә дә, бу алай түгел. Мисал өчен составында бер генә этнос — славяннар яшәгән Югославияне китерик. Формаль сыйфатлар буенча ул — милли дәүләт. Әмма славян серблар — православие динен, ә славян хорватлар католицизмны тоталар. Һәм узган гасырның 90 нчы елларында алар арасында сугыш учагы кабына. Ул нинди сугыш була соң:

гражданнар сугышымы, әллә милли сугышмы? Төгәл атама бирү бик кыен. Әмма нәтиҗәдә ике төрле дәүләт барлыкка килә, хәзер алар бер милләтле генә була. Аларны элек бергә нәрсә тотып торган соң? Коммунистик идеология. Аның җимерелүе белән дини тамырлар баш калкыта. Алар идеологик якынлыктан көчлерәк булып чыгалар.

СССР таркалгач та шундый ук хәл күзәтелә. Католик Балтыйк буе халкын, католик көнбатыш украиналыларны, мөселман азәрбайҗаннарны яки мөселман үзбәкләрне нәрсә бергә тотып торган соң? Тармаклы партия аппараты тарафыннан төрле төбәкләрдә тормышка ашырылып килгән идеологик бердәмлек. Идеология бер үк, әмма халыклар күптөрле иде. Идеологик бердәмлеккә таянып, совет хакимияте тора-бара яңа милли бергәлек булдырырга ниятли. Аны совет халкы дип атыйлар. Ясалма рәвештә оештырылган бу гомумилекне милләтнең яңа тибы дип аңлыйлар. Әмма берни дә килеп чыкмый. 1991 ел ахырында барысы да җимерелә. Союздаш республикаларның сакланып калган милли һәм дини аермалары аларның уртак идеологик ватанны тиз арада ташлап чыгуларына китерә.

Ә менә ике сәяси дәүләткә — ГФРга һәм ГДРга таркатылган немец милләте шул ук 90 нчы елларда бердәм милли дәүләткә берләшә. Сәяси киртәләр белән бүленгән Төньяк һәм Көньяк Вьетнамда да шундый ук хәл күзәтелә. Төньяк һәм Көньяк Корея да бүген шул ук юлда торалар, тик алар арасындагы сәяси аермалар әлегә көчлерәк. Киләчәктә әлеге аермаларның икенче планга калуы, аларның үзәкләшүгә омтылучы милли тенденцияләргә урын бирүе дә бик ихтимал.

Икенче меңьеллык ахырында һәм өченче меңьеллык башында бөтендөнья тарихы артка чигенгән кебек тоела. Җирләрне туплау процессы аларның таркалуына әверелә. Йөзләрчә еллар дәвамында барлыкка килгән куәтле үзәкләшкән дәүләтләр XX гасырның икенче яртысында бик тиз таркала башлыйлар. Үзәкләшкән дәүләттә, кагыйдә буларак, күпсанлы этнослар кушыла, менә ни өчен аларны полиэтник дип атыйлар. Әмма бер түбә астында төрле халыклар күбрәк җыелган саен, аларның мәнфәгатьләре дә күптөрле була һәм конфликтлар өчен сәбәпләр дә арта. Димәк, сепаратизм (үзәкләшкән дәүләттән аерымлану) өчен сәбәпләр дә күбәя.

Милли дәүләт төзелешенең төп формалары	Аларның үзенчәлекләре
1) Унитар форма	— Дәүләт аппаратының бердәм структурасы. Дәүләт башлыгы үз хакимиятен илнең барлык территориясенә җәелдерә; — Барлык территориаль берәмлекләр дә үзәк органнарга карата тигез статуста торалар. Административ-территориаль берәмлекләр сәяси мөстәкыйльлеккә ия түгелләр; — Бердәм гражданлык; — Бердәм хокук системасы; — Бердәм суд системасы; — Бер юнәлешле салымнар системасы: алар үзәккә җибәреләләр, ә аннан соң төрле регионнарга билгеләнәләр.
2) Федератив форма	— Һәр федерация уникаль үзенчәлекләргә ия — дәүләт аппаратының ике баскычы бар: федераль (союзныкы) һәм республиканыкы;
3) Конфедератив форма	— Дәүләтләрнең шартнамә нигезендә берләшүе. Билгеле бер максатларга ирешү өчен. — Конфедерация субъектлары тулысынча мөстәкыйль дәүләтләр булалар.
4) Бергәлек	— Дәүләтләр берләшмәсе, ул уртак телгә, хокукка һ.б. нигезләнә.

Америка географы С.Коэн фаразлары буенча, 30 елдан соң дөньяда дәүләтләр саны 50% ка артачак. Глобуста 300 дән артык бәйсез дәүләт барлыкка киләчәк. Галимнәр Австралиянең дүрт дәүләткә таркалачагын, Европада берничә яңа бәйсез дәүләт барлыкка киләчәген, Россиянең таркалачагын, Азия сәяси картасының тулысынча үзгәрәчәген, Канаданың дәүләт буларак юкка чыгачагын, АКШ чикләренең үзгәрәчәген фаразлыйлар (Социс.— 1996.— №12). Дәүләт таркалу — һәрвакытта да геосәяси катастрофа ул, чөнки тыныч юл белән бүлену очраклары бик сирәк була.

Ю.Калинина. Бөтендөнья аерылулар тарихы

Хәзерге сугышларның яртысы диярлек сепаратизм аркасында башланып китә. Әлеге күренешкә каршы тора алучы ышанычлы чара әлегә табылмаган. Статистика күрсәткәнчә, милли-азатлык җирлегендә туган конфликтлар бик сирәк тыныч тәгалләнә. Еш кына алар бөтенләй тәгалләнмиләр, ә киеренке фазадан «салмак агучы» халәткә генә күчәләр.

Бер өлеш территориянең үз дәүләтеннән тату рәвештә, сугышсыз, ике илдә дә яшәүче халык фикерен искә алып, ике якның да килешүе буенча бәйсезлек алган очраклар да булган. Гасыр башында Норвегия әнә шулай итеп Швециядән аерылып чыккан, ә күптән түгел генә Словакия Чехиядән, Россия элекке республикалардан, ә республикалар бер-берсеннән аерылдылар. Ингушетия дә Чечнядан нәкъ шундый «нәзакәтле» юл белән бүленеп чыкты.

1914–1918 елларда булып узган Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Бөекбритания Ирландияне Төньякка (протестантларга) һәм Көньякка (католикларга) бүлеп куйды. Көньяк Ирландиягә бәйсез дәүләт статусы бирелде, һәм Төньяк Ирландия Британиядән аерылу өчен көрәшә башлады. Башта көрәш салмак кына барды. 1969 елда Англия Ольстерга үз гаскәрләрен керткәч, хәл кинәт киеренкеләнеп китте. Конфликт әле дә дәвам итә.

1939–1945 еллардагы Икенче бөтендөнья сугышыннан соң бөек державалар җитди рәвештә дәүләтләр санын артыру белән шөгыльләнә башладылар. Германияне «капиталистик» һәм «социалистик» илләргә бүлделәр. Бердәм Корея һәм Вьетнам «коммунистик» һәм «антикоммунистик» кисәкләргә аерып куелдылар. Бөек державалар Кытайдан милли фикерле Тайваньны тартып алдылар. Инглизләр Һиндстаннан мөселманнар Па-

кистанын бүлеп чыгардылар, Палестинаның бер кисәген яңа дәүләт Израиль өчен бүлеп бирделәр. Дөнья державалары тарафыннан өлешләргә бүлгәләнгән, кискәләнгән илләр арасына хәзер, мөгаен, Югославияне дә кертеп буладыр.

Бәйсез дәүләтләрне «арттыру» әлеге илләрнең җитди рәвештә бер-берсе белән сугыша башлавына китерде. Кореялар арасында бер сугыш, Вьетнамнар арасында да бер сугыш булды, Тайвань һәм Кытай күпсанлы конфликт сынаулары уздылар, Һиндстан һәм Пакистан арасында өч сугыш һәм Палестина (гарәпләр) белән Израиль (яһүдләр) арасында биш сугыш булды.

Әгәр дә хакимиятләр нинди дә булса бер регионның үз карамакларындагы дәүләт «йогынты зонасы»нда торуын теләсәләр, алар, иң беренче чиратта, бу регионда үз хәрби көчләрен саклап калырга тырышалар. Бу эчке генә түгел, ә халыкара, геосәяси конфликтларда да эшләүче гомуми закон.

Гаскәрләрне калдыру мөмкинлеге бөтенләй беткән очракта гына ул территориядән чыгалар. Мәсәлән, дөнья бергәлегенең күп тапкыр кисәтүләреннән соң гына без Көнбатыш Европа һәм Балтыйк буеннан үз гаскәрләребезне чыгардык. Азәрбайҗанны да бик теләмичә генә калдырдык. Грузия белән дә аннан гаскәрләрне эзлекле рәвештә чыгару турында план эшләнде.

Грузия сепаратизм белән көрәштә уңышсызлыкка очрады. Ул гаскәрләрен Абхазиядә калдыра алмады. 1992 елда абхазлар җиренә сугыш белән кергән грузин армиясе бер елдан соң Сухумидан бер дә үз теләге белән китмәде. Россия артиллеристлары, десантчылары һәм очучылары белән ныгытылган абхазлар хәлиткеч һөҗүмгә күчтеләр һәм грузин гаскәрен Абхазия чикләреннән куып чыгардылар. Абхазия үзен берьяклы тәртиптә бәйсез республика дип игълан итте. Әмма танылуга ирешә алмады (*Ред. искәр.*).

Карабахта да шул ук хәл күзәтелде. Әрмән армиясе һәм Россиянең хәрби ярдәме белән, карабахлылар республикаларын Әрмәнстан белән бәйләп торучы Лачин коридорын өстәмә рәвештә үзләренә яулап алдылар.

Чыганак: МК.— 1996 — 7 июнь.

Төшенчәләр: милли дәүләт төзелеше, сепаратизм, үзәкләшкән дәүләт, империя.

Сораулар һәм биремнәр

1. Үзәкләшкән һәм милли дәүләтләр арасында нинди аерма бар?

*2. Хәзерге Россия аларның кайсы тибына карый?

3. Җирләрне туплау процессы нәрсә ул һәм безнең ил территориясендә ул ничек барган?

*4. Көнбатыш Европа илләрендә һәм Россиядә булып узган җирләрне туплау процессын чагыштырып карагыз. Сез нинди нәтиҗәләр ясарсыз?

5. Хәзерге заман дөнья бергәлегендә милләтләрнең берләшү һәм аерымлану тенденциясе ничек чагыла? Бу тенденцияләрнең охшаш һәм аермалы яклары нәрсәдә?

6. Милли дәүләтләр ни өчен һәм ничек таркалалар?

7. Иң яңа тарихта сепаратизм нинди роль уйнаган? Сезнең «суверенитетлар парады» дигән гыйбарәне ишеткәнегез бармы? Бу күренеш сепаратизм белән ничек бәйләнгән?

*8. Күпмилләтле дәүләтнең милли дәүләтләргә таркалуы барышында халык һәм хакимиятләрнең нинди проблемалары юкка чыга, ә нинделәре өстәлә? Шул турыда үз фикерегезне әйтегез.

? Проблема. Сез ничек уйлыйсыз, Россия Федерациясенә күпсанлы милли дәүләтләргә таркалу яныймы? Шул турыда өлкәннәр белән сөйләшегез.

Практикум. Дөньяда 200 чамасы дәүләт һәм 5 меңләп этнос яши, аларның берничә йөзе генә милләтләр. Хәзерге Россия составында 100 дән артык этнос, шул исәптән 30 милләт бар. Күпчелек милләтләр, хәтта барысы дисәк тә ярый, дәүләтле булырга омтылсалар да, бу максатка ирешә алганнар дип нәтиҗә ясап буламы?

§ 4 (§ 28). Идарә формалары

Идарә формалары — хакимиятне оештыру төрләре, алар хакимиятнең рәсми чыганагы белән характерлана. Монархиядә хакимиятнең рәсми чыганагы булып бер зат тора, ул да булса — король, патша, фиргавен һ.б. Республикада исә, закон буенча, хакимият чыганагы булып күпчелек халык исәпләнә.

Идарә формаларын ничек итеп классификацияләү турында бәхәсләр әлегә кадәр дәвам итә. Бик күп төрле вариантлар тәкъдим итсәләр дә, барысы да Аристотель типологиясе иң яхшысы дигән фикердә торалар. Ул *төп өч төрне* аерып



күрсәтә: монархия, аристократия, демократия. Аристотель шулай ук *өч төрле бозык форма* булуын да әйтә: тирания, олигархия һәм охлократия.

Шул заманнардан бирле фәнни фикер бернинди дә яңа нәрсә уйлап тапмады, ул бары тик моңарчы булган нәрсәләр белән генә эш итте. Фән прогрессы ни өчен шулай кинәт туктап калды соң? Мөгаен, моңа тарих закончалыгы сәбәп булгандыр: аның төп билгеләре һәр яңа әйләнештә яңа шартларга яраклашкан формада искеләрен кабатлый. Кешелек идарәнең теге яки бу формасын үз өстендә бик озак сыный, аның нәрсәләрендер үзгәртә, камилләштерә, уңышсыз үрнәкләреннән баш тарта.

Соңгы 5000 ел эчендә кешелек дәүләт иҗат итү эшен өзлексез рәвештә камилләштереп килде, аның төрле вариантларын сынап карады һәм бөртекләп иң яхшыларын гына сайлап алды. Инде күптән онытылган вариант еш кына иң яхшы үрнәк булып чыкты. Уйланырлык та, б.э.к. V гасырда уйлап табылган антик демократияне кешелек 2500 елга оныта. Һәм бары тик XX гасырда гына АКШ аның төп нигезләренә кире кайтты, төп принципларын торгызды һәм иске модель уңышлы төстә эшләп китте. Әмма бу инде хәзер яңа кешеләр, яңа халык, яңа хөкүмәттән һәм парламенттан торган, хакимиятнең яңа атрибутикасыннан гыйбарәт булган бөтенләй үзгә модель иде. Һичшиксез мәгърифәтле халык ихтыярына таянырга тиешле демократия рухы һәм принциплары гына элеккечә калды.

Сәяси идарә формалары

Борынгы акыл ияләре Геродот, Платон һәм Аристотель, идарәнең төрле функцияләре һәм табигате турында фикер йөртеп, аның өч типта булуы хакында нәтиҗә ясадылар:

— **бер кеше идарәсе,**

— **азчылык идарәсе,**

— **күпләр яки күпчелек идарәсе.**

Бу идарә типларының һәрберсе бозык форма алырга мөмкин. Яхшы патша идарәсе *монархия* дип атала, ә явыз патша идарәсен *тирания* диләр (хәзер аны диктатура дип атыйлар). Затлы нәсел аксөякләре идарәсе *аристократия* (иң яхшылар хакимияте) дип атала, ә гадел булмаган гражданнар төркеме идарәсен *олигархия* диләр. Әгәр дә хакимияттә күпчелек торып, алар гадел, мәрхәмәтле булсалар, хакимият *демократия* дип атала. Әгәр дә инде бу күпчелекне намуссыз, пычрак кешеләр алып торса, алар идарәсе *охлократия* (өер хакимияте) була. Греклар демократия турында югары фикердә тормаганнар, аны өер хакимияте дип атаганнар.

МОНАРХИЯ

абсолют монархия	чикләнгән монархия
— монарх дәүләтне гәүдәләндерә, ул — дәүләт башлыгы — берүзе идарә итә. Тулы хакимияткә ия. Аның хакимияте иң югары һәм бәйсез — аның хакимияте изге дип игълан ителә һәм дини хөрмәт белән әйләндереп алына — кагыйдә буларак, хакимият нәсел буенча тапшырыла	— законнар чыгару, башкарма хакимият өлкәсендә монарх хакимиятенең юридик яктан чикләнүе — ул парламентка бәйле түгел, әмма аның эшчәнлеге белән исәпләшергә тиеш

Антик философлар дәүләтнең *өч төрес* формасын (монархия, аристократия һәм демократия) аерып күрсәткәннәр. Алар шулай ук әлеге өч форманың бозылган формалары булуын да искәрткәннәр: чикләнмәгән монархия — автократиягә (тиранияга), чикләнмәгән аристократия — олигархиягә, чикләнмәгән демократия охлократиягә яки анархиягә әверелә.

Демократия ике грек сүзеннән килеп чыккан: «демос» — «халык» һәм «кратос» — «көч», «идарә». Демократия тәртибе булганда, гражданнар үзләренең тормышлары белән үзләре идарә итәләр, җәмәгать тормышына йогынты ясыйлар. Демократиядә халык суверен була, ягъни үз яшәү рәвешен сайлаганда, хакимиятләрдән бәйсез кала дип тә әйтәләр. Суверенлык нәкъ менә халыкның законлы хакимият чыганагы булуын белдерә.

Демократия халыкның хакимият чыганагы буларак танылуына нигезләнә. Демократиянең төп принциплары: күпчелек хакимияте, гражданнарның тигез хокуклылыгы, аларның хокук һәм ирекләренең саклануы, закон өстенлеге, хакимиятләр бүленеше, хакимият башлыгының, вәкиллекле органнарның сайланып куелуы.

Демократия вакытында кешеләр, үзләре өчен нәрсәнең начар, ә нәрсәнең яхшы булуын билгеләгәндә, чып-чынлап

ирекле саналалар. Әгәр дә әлеге хокукны сәяси партия яки хөкүмәт законсыз рәвештә үз кулына тартып алса, ягъни узурпацияләсә һәм халык өчен кайсы сәяси тәртип, кайсы икътисади уклад һәм нинди тормыш рәвеше яхшырак икәнен билгеләсә, мондый җәмгыятьне демократик дип исәпләп булмый. Кызганычка каршы, патша режимы, совет хакимияте һәм 90 нчы еллардагы яңа демократик идарә вакытында халык билгеле бер дәрәҗәдә үз язмышына үзе хуҗа түгел иде. Шулай булгач, безнең җәмгыятьнең демократик тәртиптә булуы турында сөйләргә әле иртәрәк.

Өч төрле дөрес идарә формасын — монархия, аристократия һәм демократияне берләштереп, *республика* дип атарга мөмкин.

Республика (лат. respublika, сүзгә-сүз мәгънәсе — иҗтимагый эш) төшенчәсе астында дәүләт башлыгын (мәсәлән, президентны) ил халкы яки махсус сайлау коллегиясе сайлап куюга нигезләнгән идарә формасы күздә тотыла. Закон чыгару хакимияте сайлап куелган вәкиллекле орган (парламент) кулында туплана. Республикада демократия, аристократия һәм монархия элементлары бергә үрелеп яши. Чынлыкта ил белән бер кеше (монархиячел башлангыч) идарә итә, әмма аның хакимияте закон чыгару органы булган парламент тарафыннан чикләнә, ә парламентны барлык яки күпчелек халык (демократия) сайлап куя. Республикаларда хакимият чыганагы булып күпчелек халык тора, ә дәүләтнең югары органнары ил гражданнары тарафыннан сайлап куела.

Дәүләтнең республика тәртибенә классик мисал итеп Борынгы Римны китерергә мөмкин. Европада киләчәктәге шундый типтагы идарә формалары өчен ул үрнәк итеп алына. Нәкъ менә римлылар хокук тәртибе системасын (Рим хокук тәртибе) бүгенге көндә дә эталон булып торырлык һәм хәзерге заман юристларын рухландырырлык итеп камилләштерүгә ирешәләр. Рим республикасы башында югары магистратлар — бер елга сайланып куелган тигез хокуклы ике консул һәм 300, соңрак 600 кешедән — аксөяк нәселләр вәкилләреннән (патрицийлардан) гыйбарәт булган сенат (латинчадан senex — карт, аксакаллар советы) тора. Сенат закон проектлары әзерли, законнарны һәм сайлау нәтиҗәләрен раслый, магистратлар эшчәнлеген контрольдә тота, сугыш һәм гадәттән тыш хәл игълан итә, солых төзи. Гадәттән тыш очракларда сенат диктаторны билгеләп куя.



Хәзерге вакытта дөньяда республиканың өч төп төре яши:

— **парламент республикасы**

— **президент республикасы**

— **катнаш (ярымпрезидент) республика**

Парламент республикасының үзенчәлекле сыйфаты — хөкүмәтнең парламент нигезендә (гадәттә, парламент әгъзаларының күпчелеге тарафыннан) корылуы һәм аның парламент алдында рәсми рәвештә җавап тотуы.

Безнең илдә президент премьер-министр кандидатурасын раслауны парламентка чыгара. Әгәр дә Дума аны өч тапкыр кире какса, президент Думаны таратырга һәм вакытыннан алда сайлаулар билгеләргә хокуклы. Көч куллану өлкәсе белән бәйле министрларны (мәсәлән, оборона министрын) билгеләү дә президент компетенциясендә. Дума раслаган башка министрларны президентка премьер-министр тәкъдим итә.

Парламент хөкүмәткә мөнәсәбәтле түбәндәге функцияләрне башкара:

— парламентны формалаштыра һәм аны яклый;

— хөкүмәт башкарырга тиешле законнарны чыгара;

— дәүләт бюджетын раслый һәм шул рәвешле хөкүмәт эшчәнлегенең финанс кысаларын билгели;

— хөкүмәтне контрольдә тота һәм кирәк булганда аңа ышанычсызлык белдерә, бу исә хөкүмәт отставкасына яки парламентны таратуга һәм вакытыннан элек сайлаулар үткәрүгә китерә;

— хөкүмәт сәясәтен тәнкыйтьли, хөкүмәт карарларына һәм бөтен сәяси курска альтернатив вариантлар тәкъдим итә.

Шулай итеп, парламент республикасында төп роль хөкүмәткә дә, президентка түгел, ә нәкъ менә парламентка бирелә. Бүгенге Россия әнә шуңа омтыла да, монда Дәүләт думасы президентның мөһим вазифаларын, аерым алганда, премьер-министрны билгеләү функциясен үзләштерергә тырыша. Әгәр Дәүләт думасы үз дигәненә ирешсә, безнең ил президент республикасыннан парламент республикасына күчәчәк. Бу очракта рәсми рәвештә дәүләт башлыгы булмаган премьер-министр чынлыкта дәүләтнең беренче затына әвереләчәк. Бүгенге Англиядә нәкъ шундый хәл күзәтелә. Монарх — бары тик хакимиятнең символы гына. Реаль хакимият парламент һәм хөкүмәт кулында. Парламент законнар һәм Конституция сагында тора, ә хөкүмәт аларны тормышка ашыруга һәм сәясәткә (эчке һәм тышкы сәясәткә) күзәтчелек итә.

Безнең илдә президент барлык халыкның турыдан-туры тавыш бирүе белән сайлана, парламент республикасында исә аны парламент сайлый; бу очракта соңгы сүз күпчелекне тәшкил иткән партия ягында кала.

Бөтен халык сайлавы һәм парламент сайлавы — икесе ике нәрсә. Халык сайлап куюы өстенрәк санала. Республикада аның абруеннан да югары дәрәҗә юк. Парламент белән конфликт килеп чыкканда, президент үзенә яклау эзләп турыдан-туры халыкка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Президент парламент карарларына вето (тыю) салу хокукына ия. Ул Конституция һәм гражданнар хокукы гаранты булып тора һәм халыкның икътисади хәле өчен җавап бирә.

Рәсми документларда теркәлгәнчә, бүгенге Россия — идарә итүнең республика формасы булган демократик федератив дәүләт (президент республикасы). Дәүләт башлыгы — президент, ул гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлауларда яшерен тавыш бирү юлы белән 4 елга сайлап куела. Ул шулай ук Кораллы Көчләрнең Югары Башкомандующие һәм Куркынычсызлык советы Рәисе булып та тора.

Россия Федерациясенең закон чыгаручы органы (парламенты) — Федераль җыелыш. Ул ике палатадан — Дәүләт думасыннан һәм Федерация Советыннан тора. Башкарма хакимиятне хөкүмәт рәисе (премьер-министр) җитәкчелегендәге

хөкүмәт тормышка ашыра. Хөкүмәт рәисен Дәүләт думасы ризалыгы белән президент билгели.

Хәзерге заман төрендәге республика идарә формасы беренче тапкыр (Новгород республикасын исәпкә алмасак) безнең илдә 1918 елның гыйнварында урнашты, ул вакытта Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы (РСФСР) төзелгән иде. 1922 елның 30 декабрендә РСФСР, Украина (УССР), Белоруссия (БССР), Закавказье республикалары (ЗСФСР) Совет Социалистик Республикалар Союзын (СССР) оештырдылар. Республиканың киләчәк үсеше турыдан-туры СССР белән бәйләнде. 1990 елның 12 июнендә РСФСР халык депутатлары съезды Россия Федерациясенең Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул итте. 1991 елның 17 мартында Россиядә узган референдумда Россия Федерациясе президенты посты кертелде (шул ук елда Б.Н. Ельцин Россиянең беренче президенты итеп сайланды). 1993 елның декабрендә Россия Федерациясе Конституциясе кабул ителде; Федераль җыелышка сайлаулар үткәрелде.

2000 ел уртасында президент В.В. Путин хакимият вертикален ныгытуга юнәлдерелгән указга кул куйды. Аның буенча югары палата — Федерация Советы реформалаштырылды. Моннан соң ул губернаторлардан түгел, ә аларның вәкилләреннән оеша. Президент каршында Дәүләт советы һәм аның президиумы булдырылды, президиум, Дәүләт Советы кебек үк, президент җитәкчелегендәге 7 кешедән тора.

Совет — консультатив орган, аның тәкъдимнәре закон көченә ия түгел. Аның беренче утырышы 2000 елның ноябрендә үткәрелде (ул айга бер тапкыр җыела), анда Россиянең якындагы 10 елга стратегик үсеш мәсьәләсе тикшерелде. Өстәвенә, үзәк хакимиятне ныгыту өчен, РФ территориясе җиде федераль округка бүленде: Үзәк, Төньяк-Көнбатыш, Идел буе, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш, Төньяк Кавказ округлары. Алар белән президент билгеләп куйган тулы вәкаләтле вәкилләр җитәкчелек итә.

Хәзерге Россиянең идарә формасы АКШның идарә формасы белән охшаш. Аларның икесе дә президент республикасы. Әмма АКШта президент дәүләт башлыгы да, хөкүмәт башлыгы да, ә безнең илдә дәүләт башлыгы гына. Ләкин барлык көнүзәк карарларны хөкүмәт башлыгы президент белән килешеп эшли. Ул мөстәкыйль түгел.

Күрсәтелгән ике илдә дә закон чыгару органы ике палатадан тора: АКШта — Конгресс (вәкилләр палатасы һәм сенат). АКШ Конгрессы президентка импичмент игълан итеп, аны отставкага җибәрә ала.

Импичмент (ингл. impeachment) *югары вазифалы затларны* җаваплылыкка тартуның һәм аларның җинаятьләрен судта карауның үзенчәлекле тәртибе булып тора, ул кайбер илләрдә, аерым алганда, АКШта һәм Россиядә гамәлгә кертелгән. Импичмент вакытында җаваплылыкка тартуны һәм судка бирүне, кагыйдә буларак, парламентның түбән палатасы башкара, ә эшне тикшерүне югары палата алып бара.

Безнең илдә импичментка китерүче төп сәбәп — Конституциягә каршы килүче гамәлләр. 1999 елда АКШта һәм Россиядә президент импичменты булды. Аларның икесендә дә Б.Клинтонны һәм Б.Ельцинны хакимияттән читләштерү өчен зарур булган өчтән ике өлеш депутатлар тавышы җитми калды. 1999 елның 15 маенда Россия Дәүләт думасында тавыш бирү узды. Ельцинны гаепләү буенча биш пункт чыгарылды: 1) СССРны таркату (Белая Вежа килешүе); 2) 1993 елның октябрендәге вакыйгалар; 3) Чечнядагы сугыш; 4) армияне таркату; 5) рус халкына каршы геноцид. Биш пункт буенча зарур 300 (бер генә пунктка булса да) тавыштан уртача 240–250 тавыш җыелды. АКШта да импичмент барып чыкмады.

Катнаш республика тибы икенче төрле ***ярымпрезидент республикасы*** дип йөртелә. Аның өчен көчле президент хакимиятенең һәм хөкүмәтне нәтиҗәле контрольдә тотучы парламентның бергә үрелеп эшләве хас. Хөкүмәт президент алдында да, парламент алдында да бер үк дәрәҗәдә җаваплы.

Франция ярымпрезидент республикасының классик үрнәге булып тора. Монда президент һәм парламент бер-берсеннән бәйсез рәвештә сайлана. Парламент президентны урыныннан ала алмый, ә президент парламентны таркатырга мөмкин, әмма ул чираттан тыш парламент сайлауларының датасын игълан итәргә тиеш (бу шарт инде бездә дә кертелде). Ел саен бюджет раслау һәм шулай ук хөкүмәткә ышанычсызлык игълан итү юлы белән, парламент хөкүмәтне контрольдә тоту мөмкинлеге ала.

Төшенчәләр: *монархия, аристократия, демократия, тирания, олигархия, республика, импичмент.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Өч дөрес һәм өч дөрес булмаган идарә формаларын сыйфатлап чыгыгыз.

2. Дәүләт төзелешенең республика тибына җентекле сыйфатлама бирегез. Парламент анда нинди функция башкара?

3. Импичмент нинди шартларда үткәрелә?

4. Демократияне сыйфатлап чыгыгыз, аның антик һәм заманча формаларын чагыштырыгыз, уртак һәм үзенчәлекле билгеләрен аерып күрсәтегез.

***5.** Ни өчен демократия охлократиягә әверелә, ә тираниягә түгел? Шундый әверелешнең тарихи мисалларын табып күрсәтә аласызмы?

***6.** Сезнеңчә, республика тибына хас дәүләт төзелешенең уңай һәм җитешсез яклары нәрсәдә?

***7.** Хәзерге дөньяда республиканың өч тибына (парламент, президент, катнаш) чагыштырма анализ ясагыз. Нәтиҗәләрегезне дәфтәрегезгә кыскача теркәп куегыз.

? Проблема. Сез рус тарихчысы Н.М.Карамзинның: «Демократик идарә — кече дәүләтләр өчен, аристократик идарә — урталар, монархия зур дәүләтләр өчен кулайрак»,— дигән фикере белән килешәсезме?

	Монархия	Аристократия	Демократия	Тирания	Олигархия	Охлократия
Иң яхшылар хакимияте						
Көч һәм башбаштаклык хакимияте						
Азчылык хакимияте						
Бер кеше хакимияте						
Өер хакимияте						
Халык хакимияте						

Практикум. 38 нче биттәге таблицаны карагыз. Анда идарә формалары аталган һәм кыскача сыйфатлама бирелгән. Идарә формасының нәкъ шул тибына туры килгән сыйфатламаны тамгалап куегыз.

§ 5 (§ 29). Сәяси режимнар

Сәяси режим — *дәүләт хакимиятен тормышка ашыру алымнары системасы, рәсми конституцион һәм хокук формаларының чынбарлыктагы сәяси тормыш белән туры килүе.*

Сәяси режимның *демократик* һәм *демократик булмаган* төп ике тибы яшәп килә; аларның һәрберсе берничә төргә бүленә.

Коллектив закон чыгару органы — парламент төп рольне уйнаган идарә формалары ***демократик режимга*** карый. Бу парламентлы режим була. Республика — шуның ачык мисалы.

Чикләнмәгән хакимиятле идарәче төп рольне уйнаган идарә формалары ***демократик булмаган режимга*** карый. Алар — идарә итүнең *авторитар* (бер кешеле) формалары.

АВТОРИТАРИЗМ (латинчадан auctoritas — хакимият) — антидемократик сәяси режимнарга хас хакимият системасы. Гадәттә, шәхси (бер кешеле) диктатура белән туры килә.

Авторитаризмның тарихи формаларына Азия деспотияләре, борынгы чорның, урта гасырларның һәм Яңа заманның тираниягә һәм абсолютизм идарә формалары, хәрби-полицияле һәм фашистик режимнар, тоталитаризмның төрле вариант-





лары керә. Монархия шәхси идарә формасы булса да, урталыктагы хәлдә тора, чөнки король хакимияте күп очракта парламент белән чикләнә.

Авторитар режимда хакимият чыганагы булып халык ихтыяры түгел, ә хакимиятне кулга төшергән һәм аны көч белән тотып торган бер кеше ихтыяры алга чыга. Көч авторитар режимнарның — диктатураның һәм тираниянең төп чыганагы булып тора.

Барлык *авторитар режимнарга да кайбер уртак сыйфатлар хас*. Иң элек болар *сәяси оппозициянең һәм ирекләрнең булмавы, эчке дәүләт проблемаларын хәл итү өчен куптармаклы полиция аппараты һәм куәтле армия файдаланылу.* Конституция, парламент һәм хөкүмәт дәүләттәге беренче затка буйсына һәм аның ихтыярын чагылдыра. Нәкъ менә шул ихтыяр җәмгыятьтә кабул ителгән законнар чыганагына әверелә. Галимгә, сәясәтчегә яки артистка карьера ясау өчен идарәче партиядә тору зарур. Газеталар, радио һәм телевидение бу партия идеяләрен пропагандалаучыларга, ә мәктәпләр һәм университетлар идарәче идеология рухында сәяси социальләштерү чарасына әверелә. Сәнгать әсәрләре һәм фәнни хезмәтләр кырыс сәяси цензура аша уздырыла, дин идарәче партия диктаты астында кала, бу партия шулай ук сәясәтне дә үз контролендә тота.

Бу сыйфатламалар *диктатурага* (латинчадан dictatura — чикләнмәгән хакимият) да туры килә. Ул авторитар сәяси режимның иң кырыс формасы. Әгәр дә демократия шартларында законнар халык ихтыяры буенча һәм аның мәнфәгатьләрен яклап кабул ителсә, диктатурада барысы да киресенчә була, халыктан бернәрсә дә сорап тормыйлар. Массакүләм репрессияләр хакимиятнең нәкъ менә халык мәнфәгатьләренә каршы юнәлдерелгән булуын раслый.

А.Гитлер идарәсе, гәрчә ул Конституция белән законлаштырылган, ягъни легаль хакимият төренә караса да, тарихчылар тарафыннан диктаторлык режимы (икенче төрле аны көч режимы дип тә атыйлар) дип бәяләнә. Гитлер режимы киң халык массаларына таянса да, аны демократик хакимият дип атап булмый. Ул икътисадны җайга салырга, җинаятьчелекне һәм эшсезлекне бетерергә, куәтле кораллы көчләр булдырырга мөмкинлек бирә. Әмма бу режим гражданнарның табигый һәм сәяси хокуклары белән хисаплашмый. Кешеләрнең азыкка һәм түбә астына сыенуга булган беренчел ихтыяҗлары гына канәгатьләндерелә, аларның социаль, сәяси, рухи өлкәдәге югары ихтыяҗлары исәпкә дә алынмый. Диктатура белән риза булмаган меңнәрчә кешеләр концентрацион лагерьларда газап чигә. Гитлер хакимияте режимы сәяси прогрессны, кеше хокуклары һәм ирекләре, хакимиятнең демократик институтлары үсешен дистәләрчә елларга тоткарлый. Кешеләр хакимияткә үз теләкләре белән түгел, ә куркудан буйсыналар.

Демократик режимнарга караган *парламентлы режим иң борынгы сәяси институтларның берсенә — парламентка нигезләнә.* Мондый режим шартларында җәмгыятьнең барлык сәяси, социаль һәм икътисади тормышы парламент белән бәйләнә, парламент аша законлы көч ала һәм парламент тарафыннан контрольдә тотыла. Кагыйдә буларак, парламент халык тарафыннан Конституция билгеләгән система буенча сайлана һәм закон чыгару функцияләрен башкара.

ПАРЛАМЕНТ (инглизчә parliament, французчадан parler — сөйләү) — хакимиятнең закон чыгаручы югары органы, ул тулысынча яки өлешчә сайлап куюга корыла.

Англиядә аны парламент дип, АКШта — конгресс, Швециядә — риксдаг, Норвегиядә — стортинг, Россиядә бүген — Федераль Җыелыш (элек — Дәүләт думасы) дип атыйлар. Бе-



ренче тапкыр ул XIII гасырда Англиядә сословиеләр вәкилләге органы буларак барлыкка килә.

Парламентарийларның төп бурычы — законнар чыгару. Закон проектларын тикшерү кайвакытларда бик шау-шулы, кызу бәхәсләрдә уза. Нотыклар белән күбесенчә партияләр һәм фракцияләр лидерлары, шулай ук депутатлар чыгыш ясыйлар. Алар Думаның даими комиссияләре утырышларында, мәсәлән, Кеше хокуклары комиссиясендә яки Икътисади мәсьәләләр комитетында катнашалар һәм тавыш бирәләр. Иң мөһиме — тәгаен бер сорау буенча күпчелек тавыш җыю.

Әгәр дә закон проекты күпчелек тавыш җыюга ирешә икән, ул законга әверелә. Һәр партия үзе өчен кулай һәм, аның фикеренчә, җәмгыять өчен кирәкле законнар кабул итәргә тырыша.

Парламентта күпчелек урынга ия булу — һәр сәяси хәрәкәтнең хыялы. Моның өчен сәяси хәрәкәт сайлау алды көрәше вакытында бихисап акча түгә, газеталар, радио, телевидение, өндәмәләр һ.б. аша үз кандидатлары өчен тавыш бирергә чакыра.

Парламентлы хакимият тарихы үз тамырлары белән ыругкабилә строенда кертелгән халык ассамблеяларына барып тоташа. Соңрак ассамблеялар юлбашчылар каршындагы кон-

сультатив советка әвереләләр. Юлбашчы каршындагы акыл ияләре советы гап-гади аксакаллар советы була, анда иң затлы нәсел кешеләре керә. Урта гасырларда парламент корольнең үз киңәшчеләре белән очрашуыннан гыйбарәт була, анда шулай ук халыктан килгән шикаятьләрне һәм петицияләрне тикшерү өчен судьялар да чакырыла. Мондый җыелыш үзендә хакимиятнең өч тармагын — закон чыгаручы, башкарма һәм суд хакимиятләрен берләштерә.

Латин сүзе «parliamentum»нан килеп чыккан «парламент» төшенчәсе башта лордлар (дворяннар һәм руханилар) җыелышына һәм өченче сословие вәкилләренә (рыцарьлар һәм шәһәр башлыклары) карата гына кулланылган, бу җыелышны король коллоквиум (латинчадан coologuim — сөйләшү, әңгәмә) өчен чакыра торган була. Анда башка илгә бәреп керү өчен армия җыю яки һөҗүмнән саклану мәсьәләләре тикшерелә. Әмма мондый әңгәмәләр еш кына король казнасын тулыландыруның законлы чарасы гына булып калалар.

Англия короле Эдуард I идарә иткән XIII гасырда шундый даими парламент төзелә. 1278 елда парламент даими составлы була һәм даими статуска ирешә. XIV гасыр башында функцияләр бүленә: закон чыгару — парламентка, башкарма функцияләр король киңәшчеләренә күчә. Король киңәшчеләре хөкүмәт ролен башкаралар һәм бары тик монархка тугрылык анты биргәннән соң гына законлы көчкә ия булалар. 1422 елда Англиядә хакимиятнең ике тармагы һәм аларның чикләре — совет һәм парламент, башкаручылар һәм закон чыгаручылар — инде аермачык тәгаенләнә.

Парламент демократик ирекләрне яклауның куәтле коралына әверелә. Юкка гына аның тирәсендә аяусыз көрәш бармый. Корольләр һәм диктаторлар аны ябалар, тараталар, ә халык аны торгызуны таләп итә. Парламент хокукларын кысу еш кына сарай переворотларына, фетнәләргә һәм хәтта гражданнар сугышына китерә. 1629 елда Англиядә король Карл I һәм парламент арасында каршылык көчәя. Нәтиҗәдә король түбән палатаны (общиналар палатасын) тарата һәм 1640 елга кадәр берүзе идарә итә. Әмма бераз элегрәк, 1628 елда, салымнар җыю хокукы булган парламент бу хокукны монарх хакимиятен чикләү өчен файдалана һәм шулай итеп конфликт тудыра, корольне җавап гамәлләре кылуга этәрә. Инглизләрнең Франциягә каршы гугенотлар ягында торып сугышуы, һәм иң элек, Ла-Рошель

крепостен камап тору дәүләт казнасын нык кына саектыра. 1629 елның гыйнварында король сәясәте белән риза булмаган парламент аңа яңадан һөҗүм башлый. Җавап итеп Карл I түбән палатаны тарата. Әмма парламент белән көрәш корольнең җиңелүе белән тәгәлләнә. 1649 елда корольне җәзалап үтерәләр.

Парламент төзелеше буенча *ике* һәм *бер палаталы* булырга мөмкин. Беренче вариант киңрәк таралган. Иң озын гомерле Англия парламенты *лордлар* һәм *общиналар палаталарын* берләштерә; Австралиядә ул сенаттан һәм вәкилләр палатасыннан тора; Канадада парламент сенаттан һәм общиналар палатасыннан гыйбарәт. Әмма бер генә палаталы парламентлы илләр дә бар (алар аз). Швеция (аның парламенты риксдаг дип атала) һәм Финляндия — шундый илләр.

Кайбер илләрдә, мәсәлән, АКШта һәм Россиядә, бер үк кеше ике яки өч хакимият тармагында (закон чыгаручы, башкарма, суд хакимиятләре) вәкил булып тора алмый; башка илләрдә министрлык һәм депутатлык постларын берьюлы биләп тору рөхсәт ителә. Англиядә премьер-министр һичшиксез парламент әгъзасы булырга тиеш. Ул парламенттагы күпчелекне җитәкләгәнгә күрә генә премьер-министр була. Әгәр аның партиясе парламентка сайлауларда җиңелсә, җиңгән партия лидеры премьер-министр урынын ала. АКШта президентның хакимияттә тору дәвамлылыгы Конгресска сайлаулар нәтиҗәсенә бәйле түгел, һәм президент Конгресс әгъзасы булып тормый.

Бер палаталы парламент халык ихтыярын чагылдырмый, чөнки ул король ихтыярын башкаручы һәм, гадәттә, король белән килешүче аксөяк нәсел дворяннарыннан гыйбарәт. Икенче, ягъни түбән палата төзелү һәрвакыт түбәннән килгән басым белән бәйле. Сайлау хокукларыннан мәхрүм калган сословиеләр революцияләр, фетнәләр оештыралар, күпсанлы корбаннар исәбенә булса да үз максатларына ирешәләр.

Барлык илләрдә дә парламентның түбән палатасы — һәрвакытта да югарыларның мәҗбүри төстә түбәндәгеләргә ташламасы ул. Югарылар үзләренә баерга һәм хакимияткә ирешергә мөмкинлек биргән режимнан канәгать булалар. Әмма мондый баюга алар башкалар хисабына ирешәләр дип исәпләүчеләр әлеге режимнан ризасызлык белдерәләр. Алар байлыкның гадел бүленүе өчен көрәшәләр. Моңа революцион һәм конституцион ике юл илтә. Беренчесе — законсыз һәм канлы юл, икенчесе — тыныч һәм законлы юл.

Беренче вариантны булдырмау өчен, монархка һәм аның тарафдарларына түбән катлауларны сайлауларга үткәрү, аларның мәнфәгатьләрен һәм ихтыярларын парламентта, законлы юл белән чагылдыру кулайрак. Әмма тарих законнары шуны күрсәтә: түбәндәгеләр хакимияткә тырнаклары беләнябышкач, анда бөтен куллары белән керергә тырышалар. Иң тотрыксыз һәм консерватив монархияләрнең берсе саналган Англия монархиясе беренчеләрдән булып хакимияткә түбән социаль катлауларны үткәрергә мәҗбүр була. Башка илләрдә — Нидерландта, Италиядә, Франциядә, Бельгиядә — халыкка хакимият бирергә теләмәгән югары палата тора-бара актив роль уйнаудан туктый.

Әгәр парламентның ике палатасын чагыштырып карасак, илләрнең барысында булмаса да, күбесендә гаҗәеп үзенчәлек күзәтелә. Югары палата һәрвакыт хакимиятләр белән килешә, ә түбән палата ризасызлык чыгышлары, бунтлар күтәрә. Беренчесе конституцион тәртипләрне яклый, ә икенчесе, әгәр дә җитди сәбәпләр бар икән, аны үзгәртергә тырыша. Мондый хәл конституцион монархия илләрендә генә түгел, совет системасыннан арынган Россиядә дә күзәтелә.

Төшенчәләр: *авторитаризм, тоталитаризм, парламент.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сәяси режим нәрсә ул? Идарә формасыннан ул нәрсә белән аерыла?
2. Сәяси режимнар ничек классификацияләнә?
3. Авторитар режим барлыкка килү өчен нинди шартлар кирәк? Авторитар режимга мисаллар китерегез.
4. Диктатурага мисаллар китерегез һәм аңа сыйфатлама бирегез.
*5. Антик дөнья тарихында иң элекке грек тираниясе турында укыгыз. Аның үзенчәлеге нәрсәдә?
6. Парламентлы режим нәрсә ул? Ул кайчан барлыкка килгән һәм нинди үзгәрешләр кичергән?
*7. Хәзерге Россиядә парламентлы режим мисалларын беләсезме? Аларны тасвирлагыз.

? Проблема. Җәмгыять үсешендә авторитар режимнар нинди роль уйнаганнар, бу режимнарның кешелек тарихына уңай йогынты ясаулары турында әйтеп буламы?

Практикум. Түбәндәге ике билгеләмәнең кайсы белән сез килешәсез?

1. Сәяси режим — иң элек сәяси практика ул, бу режим төрле дәүләти һәм хокукый формалар кысаларында тормышка ашырыла.
2. Сәяси режим — дәүләт хакимиятен тормышка ашыру алымнары системасы. Ул демократик хокукларны һәм ирекләрне, дәүләт хакимиятенең аларның хокукый нигезләренә мөнәсәбәтен чагылдыра.
Үз фикерегезне нигезләгез.

§ 6 (§ 30). Гражданлык җәмгыяте һәм хокукый дәүләт

«Гражданлык җәмгыяте» — күп мәгънәле төшенчә. Фәндә ***төп ике мәгънәне*** аерып күрсәтәләр: безнең акылыбыздан бәйсез яшәүче ***чынбарлык чагылышы*** булган гражданлык җәмгыяте һәм җирдә алдынгы карашлы кешеләрнең күп буыннары урнаштырырга омтылган, ***лозунг*** яки ***идеал*** буларак каралган гражданлык җәмгыяте.

Беренче очрактагы гражданлык җәмгыяте сәяси булмаган барлык мөнәсәбәтләрне колачлый. Бу бик җиңел аңлашыла. Күпсанлы иҗтимагый мәнәсәбәтләрдән, үзара тәэсир итешүләрдән, статуслардан, рольләрдән, институтлардан сәяси сферага караганнарын алып ташлыйбыз. Калган өлеш социологиядә «гражданлык җәмгыяте» дип атала да инде. Ул гаилә, кан кардәшлеге, милләтара, дини, икътисади, мәдәни мөнәсәбәтләрне, төрле сыйныфлар һәм катлаулар арасындагы мөнәсәбәтләрне, халыкның демографик составын, кешеләрнең аралашу формаларын, икенче төрле әйткәндә, дәүләт контролендә булмаган барлык нәрсәләрне колачлый.

Әмма «гражданлык җәмгыяте» төшенчәсенең беренче мәгънәсеннән аерылучы икенче асылы да бар. Социологик категория сыйфатында «гражданлык җәмгыяте» чынбарлыкның нәрсә булуын икърарлый, ягъни раслый: ул — сәяси булмаган мөнәсәбәтләр җыелмасы. Ә идеологик төшенчә сыйфатында «гражданлык җәмгыяте» алдынгы карашлы кешеләр омтылган чынбарлыкның нинди булырга тиешлеген күрсәтә. Монда сүз ниндидер идеал турында бара.

Идеал буларак та «гражданлык җәмгыяте» идеаль җәмгыятьне чагылдыра. Ул киң гражданлык һәм сәяси хокуклары булган, дәүләт белән идарә итүдә актив катнашкан, үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтә алган, үз ихтыяҗларын тоткарлыксыз канәгатьләндерүгә сәләтле, шәхесләрнең мәнфәгатьләре са-

гында торучы теләсә нинди оешмалар һәм партияләр оештырган азат, суверен шәхесләрнең җәмгыяте була. Икътисади планда идеал милек формаларының күптөрлелеген, ирекле базарны, ирекле эшмәкәрлекне белдерә, рухи планда сүз һәм матбугат ирегең, барлык массакүләм мәгълүмат чараларының бәйсезлеген, дин тоту ирегең аңлата. Безнең илдә социализмнан базар мөнәсәбәтләренә күчү гражданлык җәмгыяте кыйммәтләрен раслау лозунгы астында алып барыла.

Шулай итеп, «гражданлык җәмгыяте» төшенчәсендә кайвакыт бер-берсе белән каршылыкка керүче ике мәгънә — социологик һәм идеологик мәгънәләр аерыла (тагын юридик мәгънә дә бар әле).

Беренче мәгънәдәге гражданлык җәмгыяте дәүләттән элегрәк барлыкка килә. Ул ыруглык җәмгыяте аучылары һәм азык җыючылары дәверендә үк була. Дәүләт бары тик 5–6 мең ел элек кенә оеша. Икенче мәгънәдәге «гражданлык җәмгыяте» төшенчәсе тарихи яктан иң соңгы продукт булып тора һәм хокукый дәүләт буларак күзаллана. Мондый идеалга хәзерге кайбер дәүләтләр якынайды, әмма дөньяның иң алдынгы демократик дәүләтләре дә тулысынча ул югарылыкка ирешә алмады әле.

А.Мигранян. Дәүләт һәм җәмгыять

«Гражданлык җәмгыяте» төшенчәсе төрле мәгънәләрдә кулланыла. Әмма ул һәрвакыт сәяси булмаган барлык мөнәсәбәтләр суммасын чагылдыра. Борынгы шәһәр-дәүләтләрдә җәмгыятьтән читләшкән ниндидер көч буларак аңлашылган «дәүләт» төшенчәсе булмый. Җәмгыятькә һәм дәүләткә каршы торучы автоном шәхес идеясе дә тумый. Шуңа күрә дә Аристотель, Платон һ.б. кебек борынгы философларның җәмгыятьне ниндидер бер организм итеп күзаллавы очраклы хәл түгел.

Яңа заман бу бердәмлекне бүлгәләде һәм җәмгыятьне — дәүләткә, индивидны җәмгыятькә һәм дәүләткә каршы куйды. Яңа заман сәяси теориясендә дәүләт индивидка һәм гражданлык җәмгыятенә буйсынулы урынны били.

Дәүләт гражданлык җәмгыяте тарафыннан контрольдә торган илләрдә капитализм аеруча нәтиҗәле үсеш алды. Капитализм Англиядә һәм АКШта Франциядәгегә караганда тизрәк, Франциядә исә Германиядәгедән һәм Австро-Венгриядәгедән тизрәк, ә бу илләрдә Россиядәгедән тизрәк үсте.

Индивидуаль һәм иҗтимагый тормыш өлкәләре дәүләт һәм төрле дәрәҗәле дәүләт органнарының кырыс регламентациясеннән никадәр күбрәк сакланган булса, җәмгыять үсеше дә шулкадәр нәтиҗәлерәк бара. Гражданлык җәмгыяте XII гасырдан бирле корольләр таҗы белән көрәшеп, ниһаять, XVII гасырда аны буйсындыруга ирешкән Бөекбритания мисалы һәм АКШның 200 еллык тарихы әлеге нәтиҗәне раслыйлар. Инглизләр азрак тынычлыкка, әмма күбрәк бәйсезлеккә ия булуны хуп күрделәр, башбаштаклык өстенлек иткән тынычлыкны саклауга караганда хәвефле ирекне сайладылар. Алар юлбасарларга түзүне кулайрак күрделәр, чөнки алар белән сугышып була, ә чиновниклар алдында бил бөгәргә туры килер иде.

Югары үсешле гражданлык җәмгыяте сәяси режим тотрыклылыгының нигезен тәшкил итә. Гражданлык җәмгыятенең Россиядә һәм Германиядә тиешле дәрәҗәдә үсешкә ирешмәве аркасында, Беренче бөтендөнья сугышында җиңелүләр бу илләрдә дәүләт системаларының җимерелүенә китерде.

Озак вакытлар дәвамында немец җәмгыяте дәүләт протектораты астында яшәде. Хакимият кризисы вакытында Германиядәге режим җәмгыятькә таяна алмады. Бу Веймар республикасы һәлакәте вакытында ачыктан-ачык күренде.

Социализм вакытында дәүләт үз өстенә үз функцияләрен генә түгел, ә гражданлык җәмгыяте функцияләрен дә ала. Нәтиҗә күз алдында: дәүләт яңадан җәмгыятьне дә, индивидны да үзенә йота һәм аларның бурычларын формалаштыра, үз карарларын карусыз тормышка ашыруны таләп итә. Гражданлык җәмгыяте ныгый барган саен, дәүләт эшчәнлегенең «опекунлык» ягы минимумга калырга тиеш, ә аның үзенә теория билгеләгән урынны алырга — җәмгыять контроле астында аның функциясенә әверелергә туры киләчәк. Революциягә кадәрге Россиядә хокуклардан читләштерелмәгән ирекле индивид та, алдынгы үсешле гражданлык җәмгыяте дә юк иде.

Илебез тарихында гражданлык җәмгыяте үсеше өчен алшартлар барлыкка килгән дәвер дә булды. Бу — НЭП заманы. Әмма илнең Сталин төркеме сайлаган үсеш юлы җәмгыятьнең бөтен өлкәләрен дә тоташ регламентлаштыруга китерде. Нәтиҗәдә демократия өчен хас булган «тыелмаган бар нәрсә дә рөхсәт ителә» принцибы урынына без «рөхсәт ителмәгән бар нәрсә дә тыела» принцибы буенча яши башладык.

Лорд Эктон билгеләп үткәнчә, теләсә кайсы хакимият боза, ә абсолют хакимият тулысынча боза. Гражданлык җәмгыятенең дәүләт хакимиятен нәтиҗәле төстә контрольдә тота алырлык алдынгы үсешле институтлары булмаганда, француз сәясәт белгече Токвиль язган хәл күзәтелә: «Җәмгыятьтә барысы да бер дәрәҗәдә тигез хокуклы була һәм барысы да дәүләт хакимияте алдында бертигез дәрәҗәдә көчсез, ярдәмсез кала».

Чыганактан кыскартып бирелде: Знание — сила.— 1988.— №12.— 1–7 б.

«Гражданлык җәмгыяте», *«граждан»* һәм *«гражданлык»* төшенчәләре үзара тыгыз бәйләнгән. Инглизчәдән тәрҗемә иткәндә «граждан» һәм «шәһәр» мәгънәләрен аңлатучы «citizenship» һәм «city» сүзләре очраклы рәвештә генә бертөрле яңгырамый. Алар икесе дә латинча «city» сүзеннән ясалган. Антик Грециядә һәм Римда шәһәрдә, төгәлрәк әйткәндә, шәһәр-дәүләтләрдә яшәүче иректе кешеләр генә граждан булып саналган. Мең еллар буе яшәгән үзидарәле община әнә шундый булган, аннан соң аңа алмашка кешеләрнең тагы да эрерәк бергәлеге — милләт килгән. Шуннан бирле Европада Яңа заманга кадәр яшәгән шәһәр-дәүләтләр (city-state) урынын (мәсәлән, Төньяк Италиянең XV–XVI гасырлардагы шәһәр-дәүләтләре) дәүләт-милләтләр (nation-state), яки милли дәүләтләр алыштырган.

Хәзерге мәгънәдәге гражданлык башлангычларын без б.э.к. IV гасырда яшәгән борынгы грек галиме һәм философы Аристотель фикерләрендә табабыз. Дәүләт гражданы дип саналу өчен, шул дәүләт эчендә яшәүче шәһәр кешесе булу гына җитми, бәлки ул чит ил кешесе яки кол булмаска тиеш, ди галим. Бары тик шундый гражданнарга гына административ функцияләр башкару һәм шәһәр-дәүләт алдында торган хокукый мәсьәләләрне чишү рөхсәт ителә.

Бүген гражданлык алганнан соң ук кеше гражданлык хокукының тулысынча барлык төрләреннән файдалана башлый. Балалар һәм яшүсмерләр тулы гражданлык статусына ия булмыйлар, чөнки аларның сайлау хокукы юк һәм алар өлкәннәргә генә бирелгән кайбер хокуклардан файдалана алмыйлар. Аларны ил Конституциясе гарантияләгән хокуклар яклый. Хөкем ителгән кешеләр күпчелек илләрдә гражданлык хокукларын югалталар. Алар хакимият органнарына сайлый һәм сайлана алмыйлар.

Кайбер илләрдә җирле хакимиятләр, сайлауларда көндәшләреннән котылу өчен, аларны җинаятьтә гаепләү алымын файдаланалар. 1998 елда Түбән Новгородта сайлауларда җиңүчене көндәшләре элек тикшерү астында торуда гаепләп чыгалар. Сайлауларны гамәлдән чыгарылган дип таныйлар, ә күпчелек шәһәр халкының тавышын туплый алган җиңүчене рәшәткә артына кертеп утырталар.

> **ГРАЖДАНЛЫК** — кеше һәм дәүләтнең даими сәяси-хокукый бәйләнеше, бу бәйләнеш аларның үзара хокукларында һәм бурычларында чагылыш таба.

Гражданлыкны кешеләр кабул итәләр, гражданлыктан үз теләкләре белән баш тарталар (70–80 нче елларда илдән киткән кайбер совет диссидентлары нәкъ шулай эшлиләр дә), гражданлыктан кешене мәҗбүри төстә дә мәхрүм итә алалар. Мәсәлән, 30 нчы елларда Сталин режимы лагерьларына эләккән совет сәяси тоткыннарын шуңа дучар итәләр, шулай ук кешене мәҗбүри төстә илдән куарга, аны үзе илдән китү дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкиннәр (СССРда андый мисаллар шактый күп булды).

Гражданлыкның асылы әлеге илнең Конституциясен танудан гына түгел, ә аның башлыгын танудан һәм югары идарә органнарын сайлауларда катнаша алу мөмкинлегеннән дә гыйбарәт. Гражданлык хокукы булмаганнарны Конституция якламый.

Антик заманнардан бирле гражданлык *сайлау хокукы* белән тыгыз бәйләнә. Антик полис гражданнары булып формаль төстә күпчелек, аерым алганда ирекле һәм ярлы кешеләр санала алган. Ә менә чынлыкта исә җәмгыятьнең азчылыгы — байлар гына гражданнар булганнар. Безнең заманда ярлы кешеләрне «ярымгражданнар» яки «икенче сортлы гражданнар» дип атыйлар. Антик Грециядә коллар, чит ил кешеләре, хатын-кызлар һәм ярлылар сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән була. Әлбәттә, бу дәүләт аларны якламаган дигән сүз түгел. Юк, сүз бары тик гражданлык билгеләмәсен таратучы һәм бер үк вакытта аңа тәгәллек кертүче сайлау хокукы турында бара.

Сайлау хокукы кешеләрне сәяси карарлар кабул итү барышына йогынты ясарга мөмкинлек бирүче куәтле каналлар белән тәэмин итә. Җәмгыять элитасы элек тә, хәзер дә дәүләт белән идарә итү чыганакларына ярлыларны үткәрергә теләми, аларны

кайвакыт, мәсхәрәләп, ***плебс*** дип атыйлар. Бу төшенчәнең ике мәгънәсе бар: а) ярымбелемле, белемсез, надан кешеләрне (өерне) атау өчен әйтелгән кинаяле мәгънә; б) аерым бер илдә аерым дәвердә аерым бер кешеләр төркемен аңлатучы туры тарихи мәгънә.

Борынгы Римда ярлы, әмма ирекле гражданнарны плебейлар (латинча plebejus, plebs — гади халык) дип атаганнар. Алар ирекле булгач, юридик яктан сайларга да тиеш булганнар. Әмма плебейларны, ярлы булулары сәбәпле, сайлауларга уткәрмәгәннәр. Парадокс килеп туган: рәсми төстә алар гражданнар саналганнар, ә чынлыкта исә сайлау хокукыннан файдалана алмаганнар. Шулай да, патрицийлар кебек ук, салымнарны алар да түләгәннәр. Әмма бу инде социаль сыйфат. Плебейларның дошманнары булган патрицийларга аларны сәяси ышанычсызлар рәтенә кертү өчен шул да җитә калган.

Гражданнар булмаган плебейлар белән граждан патрицийлар арасында ике йөз ел (б.э.к. V гасыр башы — III гасыр башы) буена көрәш барган, нәтиҗәдә беренчеләре гражданлык хокуклары алуга ирешкәннәр. Б.э.к. 450 елда 10 патрицийдан торган махсус комиссия ярлылар һәм хәерчеләр өчен тарихта беренче сәяси хокуклар җыелмасын эшлиләр. Ул XII таблица Законы дип атала, чөнки аны 12 бакыр тактага язалар. Аларны Форумга чыгаралар һәм, мөһим закон нигезләмәләрен ахыргача эшләп бетерүдә катнашу өчен, плебейлар вәкилләрен чакыралар. Әнә шулай итеп гражданлык хокуклары һәм ирекләре үсешенә тарихи адым ясала. Әгәр дә элек алар азчылык монополиясе булса, хәзер инде күпчелекнең өстенлегенә әверелә. Әгәр элек плебейлар, үз хисапларына корал алып, хәрби хезмәткә генә чакырылган булсалар һәм патрицийлар белән тигез хокуклы дип саналмасалар, хәзер инде алар Рим законнары яклавына кертеләләр. Плебейлар Халык җыелышына үз вәкилләрен — *халык трибуннарын* сайлау хокукын алуга ирешәләр. Алар вето ярдәмендә теләсә кайсы закон эшчәнлеген туктата һәм закон чыгару инициативасы белән чыга алалар.

Халык трибуннары — изелгәннәрне һәм рәнҗетелгәннәрне яклаучылар — ил тормышында мөһим сәяси роль уйный башлыйлар. Шуннан бирле гражданлык җәмгыяте институты — *халык трибуннары институты* башлангыч ала. Ул халык массаларының гражданлык һәм сәяси хокуклар өчен көрәшенең тарихи яктан беренче законлы формасы була.

Европа җәмәгатьчелеге гражданлык хокукларын киңәйтү өчен бик озак көрәшә, ул хокуклар арасында сайлау-сайлану хокукы мөһим урын алып тора. Хәтта XIX гасырда да АКШ һәм Англия кебек алдынгы илләрдә, башкалар турында инде әйткән дә юк, милек һәм раса цензы яши. Ак тәнле ярлы ирләр сайлау хокукына ия булмыйлар. Хәлле һәм бай гражданнар, аларга сәяси хокуклар бирелсә, дәүләттәге эшләрне контрольдә тотудан һәм өстенлекләреннән колак кагудан куркалар. Бары тик 1965 елда гына сайлау хокуклары турындагы закон америкалы кара тәнлеләргә дәүләтнең сәяси мәсьәләләрен хәл итүдә ак тәнлеләр белән бертигез дәрәҗәдә катнашу мөмкинлеген тудырды.

Бүген демократик җәмгыятьтә гражданнар *сәяси хокукларның* һәм *ирекләрнең* тулы җыелмасыннан файдаланалар. Бу хокуклар сәяси эшчәнлектә катнашу мөмкинлеге тудыра. Алар сайлау һәм сайлану хокукы, сүз, матбугат, җыелыш һәм митинглар, союзлар иреге, шәхси һәм коллектив мөрәҗәгатьләрне (петицияләрне) хакимият органнарына җибәрүдән гыйбарәт. Һәр кеше дәүләт белән идарә итү эшләрендә турыдан-туры үзе һәм үз вәкилләре аша катнашу хокукына ия, сәяси процессның потенциаль актив субъекты булып тора.

Хакимиятләр кабул иткән һәр мөһим карар мәҗбүри рәвештә халык тавыш бирүе аша узганда гына, җәмгыять чын демократик дип исәпләнә ала. Кагыйдә буларак, тавыш бирү системасы бик катлаулы. Мондый җәмгыятьләрнең күпчелегендә «вәкиллекле демократия» дип аталучы система сайлап алынган. Халык фикерен үз сайлау округларында җиңеп чыккан кешеләр чагылдыра.

Чынбарлыктагы гражданлык җәмгыяте идеаль гражданлык җәмгыяте белән бары тик бер очракта — хокукый дәүләт урнашканда гына тәңгәл килергә мөмкин. Мондый дәүләт җәмгыятьтә хокуклар өстенлегенә, кешеләр ирегенә, аларның тумыштан ук тигез хокуклы булуына нигезләнә. Җәмгыять әгъзалары үз ирекләре белән үзләре өчен кайбер чикләүләрне кабул итәләр һәм гомуми законнарга буйсыну йөкләмәсе алалар. Хокукый дәүләттә *гражданлык җәмгыяте* законнар чыганагы булып тора. Ул дәүләтне билгели, ә киресенчә түгел. Мондый вакытта шәхес җәмгыятьтән приоритетлырак, ягъни аның кыйммәте өстенлеклерәк була.

Хокукый дәүләткә хас билгеләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— җәмгыять тормышының барлык сфераларында закон хакимлеге;

— дәүләтнең һәм аның органнарының закон аша бәйләнеше;

— гражданнар хокукларын суд яклавы һәм дәүләт белән шәхеснең үзара җаваплылыгы.

Хокукый дәүләт идеясе антик фикер ияләре тарафыннан ук тәкъдим ителгән иде, немец философы И.Кант аны фәлсәфи яктан нигезләде. Хокукый дәүләт — демократиянең аерылгысыз элементы. Мондый дәүләттә югары хакимият компетенциясе халыктан килүче законнар һәм махсус институтлар ярдәмендә чикләнә.

Хокукый дәүләт — конституционализм принципларының һәм идеяләренең чынбарлыктагы гәүдәләнеше ул. Аның нигезендә кешене дәүләт террорыннан, намус-вөҗданын мәсхәрәләүдән, хакимият органнары тарафыннан вакчыл тыкшынудан саклау, шәхескә индивидуаль ирек һәм нигез хокуклар гарантияләү омтылышы ята. Хокукый дәүләт шәхес ирекен, иминлеген һәм абруен сакларга тиеш. Халык дәүләтне контрольдә тота алсын һәм дәүләт җәмгыять өстеннән хакимлек итүче коточкыч хәшәрәткә әверелмәсен өчен, хакимиятләр бүленеше институты кертелгән: закон чыгаручы, башкарма һәм суд хакимиятләре.

Кешелек хокукый дәүләт идеясенә һәм практикасына бик озак вакытлар дәвамында бара. Барлык кешеләр өчен дә бертөрле закон хакимияте турында б.э.к. VI гасырда ук борынгы грек архонты Солон әйтә. Кешенең табигый хокуклары һәм дәүләт законнарының тәңгәллеге турында Аристотель һәм Цицерон язалар. Борынгы Римда хакимиятләр бүленеше тормышка ашырыла. Хокукый дәүләт концепциясе XVII—XIX гасырларда гына формалаша, аның гамәлгә ашырылуы бары тик безнең көннәрдә генә һәм анда да бик аз илләрдә генә мөмкин була. Хокукый дәүләтнең төрле теорияләре гражданлык җәмгыяте концепциясенә нигезләнәләр.

Тоталитар дәүләт — гражданлык җәмгыятенә һәм аңа тиң сәяси форма булган хокукый дәүләткә тулысынча капма-каршы торучы дәүләт ул. Алар — антагонистлар (капма-каршы системалар). Тоталитар дәүләттә шәхес һәм гражданлык ирекләре

бастырыла, кешенең сәяси хокуклары сакланмый, закон хаким сыйныф яки идарәче файдасына башбаштак рәвештәраслана. Барлык гражданнарның да закон алдында тигезлеге сакланмый.

Тоталитар дәүләткә түбәндәге билгеләр хас:

— **бастыру (буйсындыру) аппараты,**
— **башкача фикерләүчеләрне эзәрлекләү,**
— **кырыс цензура һәм сүз иреген бетерү,**
— **бер сәяси партия диктатурасы,**
— **дәүләт милке монополиясе,**
— **үз халкына каршы геноцид,**
— **шәхесне бастыру (буйсындыру), дәүләттән читләштерү.**

Бер генә зат идарә иткән барлык формалар *«тоталитаризм»* термины белән тасвирлана, дәүләт мондый вакытта гражданнар тормышының барлык якларын контрольдә тота. Идарәнең тоталитар формалары беренче тапкыр Беренче бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килә. Хәзерге заманда аларның ике төре бар: социалистик һәм фашистик дәүләтләр.

ТОТАЛИТАРИЗМ (урта гас. латин теленнән totalis — барлык, бөтен, тулы) — дәүләтнең бер формасы (тоталитар дәүләт), ул җәмгыять тормышының барлык өлкәләрен тулысынча (тоталь) контрольдә тоту, конституцион хокукларны һәм ирекләрне юкка чыгару, оппозициягә һәм башкача фикер йөртүчеләргә карата репрессияләр белән характерлана.

Италиядә 1922 елдан 1943 елга кадәр идарә иткән беренче фашист диктаторы Бенито Муссолини «totalitario» терминын әйләнешкә кертеп җибәрә. Һәм ул аны: «Бөтен нәрсә дәүләт эчендә тора, аннан читтә беркем һәм бернәрсә дә юк, беркем дә дәүләткә каршы тора алмый»,— дип аңлата. Тоталитаризм вакытында бер генә социаль институт та дәүләт контроленнән читкә кала алмаса да, Муссолини заманында дин мондый контроль астына эләкмәгән.

Тоталитаризм Германиядә А.Гитлер идарә иткән 1933 елдан алып 1945 елга кадәр, СССРда 1917 елдан алып 1991 елга кадәр, Албаниядә Э.Ходжи идарә иткәндә һәм Төньяк Кореяда Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Вьетнамда һәм Камбоджада 1975 елдан соң хөкем сөрә. Элекке совет блогының башка илләрендә — Польшада, Румыниядә, Болгариядә, ГДРда, Чехословакиядә, Югославиядә, Кытайда, Венгриядә — тоталитаризмның кайбер элементлары гына гамәлдә була.

Тоталитаризм һәм демократия гражданлык күренешенә карата ике төрле мөнәсәбәттә торалар. Беренче очракта гражданнар хокукы бозыла, икенчесендә яклана. Гражданлык илнең хокукый режимы белән билгеләнә, ә анысы, үз чиратында, җәмгыятьнең сәяси режимыннан бәйле була.

Төшенчәләр: *гражданлык җәмгыяте, гражданлык, хокукый дәүләт.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Гражданлык җәмгыяте нәрсә ул? Аны ни өчен ике мәгънәдә аңлау кирәк? Үз җавапларыгызны нигезләгез.
2. Гражданлык нәрсә ул һәм практикада нәрсәдә гәүдәләнә?
3. Хокукый дәүләтнең нинди билгеләрен беләсез?
*4. Дөнья тарихында ни өчен гражданлык проблемасы тирәсендә кызу бәхәсләр генә түгел, ә хәрби бәрелешләр дә булган?
*5. «Гражданлык», «гражданлылык» төшенчәләре арасында нинди уртаклык бар? Үз фикерегезне әйтегез.
*6. Хокукый һәм гражданлык җәмгыятьләрен чагыштырыгыз. Сез нинди нәтиҗәләр ясарсыз?
* 8. Дәүләт һәм җәмгыять үзара ничек бәйләнгән? Аларның билгеләрен һәм үзлекләрен чагыштырыгыз, үзара мөнәсәбәтләрен ачыклагыз.

? Проблема. Хәзерге Россиянең хокукый дәүләт һәм гражданлык җәмгыятенә таба баруы турында әйтеп буламы?

Практикум. Түбәндәге билгеләр дәүләтнең хокукый тибына карыймы, әллә инде тоталитар тибынамы?
1. Бастыру (буйсындыру) аппараты.
2. Башкача фикер йөртүчеләрне эзәрлекләү.
3. Кырыс цензура.
4. Бер сәяси партия диктатурасы.
5. Дәүләт милке монополиясе.
6. Үз халкына карата геноцид.
7. Шәхесне бастыру (буйсындыру) һәм аны дәүләттән читләштерү.
Сезгә боларны билгеләргә кирәк.

§ 7 (§ 31). Тавыш бирү, сайлаулар, референдум

Тавыш бирү — илнең сәяси тормышында гражданнар катнашуының бер формасы. Аның белән бергә башка формалар да бар, аерым алганда алар түбәндәгеләр: сәяси һәм иҗтимагый хәрәкәтләр оештыру һәм аларда катнашу, парламентка һәм

закон чыгаручы җирле хакимият органнарына тәкъдимнәр һәм проектлар белән мөрәҗәгать итү, җыелышларда һәм митингларда катнашу, теге яки бу партия өчен агитацияләү, партия әгъзасы сыйфатында эшләү, сәяси клубта яки оешмада әгъза булып тору, партия файдасына акча керту.

АКТИВ САЙЛАУ ХОКУКЫ — гражданнарның дәүләт башлыгын һәм вәкиллекле хакимият органнарын (парламентны, муниципалитетны һ.б.) сайлауларда катнашу хокукы. Россия Федерациясендә 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга бирелә (конституцион закон белән каралган искәрмәләрдән тыш).

ПАССИВ САЙЛАУ ХОКУКЫ — гражданнарның вәкиллекле дәүләт органнарына сайлана алу хокукы.

Барлык илләрдә дә сайлау процедурасы якынча бер үк төрле. Аңа түбәндәге элементлар керә: яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегендә теркәлү, махсус кабинада яшерен сайлау, барлык сайлау округлары өчен дә бер үк кандидатлар исемлеген файдалану, сайлауларда сайлау процедурасының дөреслеген контрольдә тотучы чит күзәтүчеләрнең катнашуы, махсус төзелгән комиссия белән бюллетеньнәрне санау, сайлау нәтиҗәләрен рәсми төстә бастырып чыгару.

Сайлаучыларның активлыгы аларның гомуми саныннан күпме проценты сайлауларга килүе белән билгеләнә. Бу процент төрле шартларга: а) гражданнарның сайлауларны никадәр мөһим дип исәпләвенә; б) сайлаучының кайсы партия тарафдары булуына; в) сайлаучының шәхси сыйфатларына, аның кайсы җенестән булуына, яшенә һәм статусына бәйле. Шунысы мәгълүм — Россиядә коммунистлар партиясе сайлаучылары иң актив, ә демократик блокныкылар иң пассивлар. Әгәр сайлаучылар үз партияләре күбрәк тавышка ия булуын һәм барыбер җиңәчәген чамаласалар, аларның активлыгы кими. Ә көндәш партия сайлаучыларының активлыгы арта.

Сайлау күптөрле факторларга: кешенең җенесенә, яшенә, кайсы партиядә торуына, социаль чыгышына, диненә бәйле. Җенес һәм яшь, никадәр гаҗәп булса да, сәяси эшчәнлеккә йогынты ясыйлар. Яшьләр сайлауларда бик теләп катнашмыйлар, аның каравы, партияләр төзүдә һәм көндәлек эшләрдә актив булалар. Көнбатыш илләр өчен тагын түбәндәге тенденцияләр хас: хатын-кызлар сайлауларда ирләргә караганда, кара тәнлеләр акларга караганда, эшчеләр урта сыйныфка караганда,

яшьләр өлкәннәргә караганда сирәгрәк катнашалар. Хатын-кызлар элек-электән сайлау хокукы өчен көрәшеп килсәләр дә, ул хокукка ия булгач, аларның бик сирәге генә аннан файдалана.

Сайлауларда катнашу дәрәҗәсе социаль статуска һәм белемгә бәйле. Кешенең статусы никадәр югары булса, ул сәяси тормышта шулкадәр күбрәк катнаша. Белемлерәк кешеләр сәясәт белән теләбрәк шөгыльләнәләр, моның җәмгыятьтәге социаль үзгәрешләргә китерәчәген тойсалар, бу аеруча көчлерәк чагыла. Сайлауларда актив катнашучыларның күләме теркәлүнең һәм тавыш бирүнең никадәр гадирәк оештырылуына да бәйле.

Тикшерүләр күрсәткәнчә, кайсы сәяси партияне кулайрак күрүгә мәктәп берничек тә йогынты ясамый, аның каравы, гаилә йогынтысы көчле була. Англиядә соралганнарның 80% ы эти-әниләре сайлаган партия өчен тавыш бирүе ачыкланды. Төрле илләрдә сайлаучыларның активлыгы бертөрле түгел. Галимнәр, 20 алдынгы сәнәгать илен шушы критерий буенча чагыштырып караганнан соң, АКШның арттан икенче урында торуын ачыкладылар (сайлаучыларның гомуми санынннан бу хокукка ия булганнарның 52,6 % ы тавыш бирүгә килә). Аннан алдарак Ирландия (62,3%), тагы да алда Швейцария тора (89,4%). Активлык буенча лидерлык Италиягә карый — 94%. Моның сәбәбен гражданнар пассивлыгында түгел, ә сайлау системаларының үзенчәлекләрендә күрәләр. Тавыш бирү мәҗбүри булган илләрдә (сайламаучылар штрафка тартыла) тавыш бирүчеләр саны сайлау иреге куелган илләргә караганда күбрәк була. Өстәвенә, сайлаучыларны теркәү хөкүмәт контроле астында барганда да, һәр граждан үзе мөстәкыйль теркәлергә тиеш булган очракка караганда, сайлауларда катнашучылар саны югарырак була.

Сайлауларда гражданнарга үз теләкләре белән ирекле рәвештә берсен сайлап алу өчен ике һәм күбрәк кандидат тәкъдим ителә. 1989 елга кадәр СССРда узган сайлауларда кандидатлар исемлекләре бер генә партиягә карый иде, һәм аларда, кагыйдә буларак, бер кандидатура гына күрсәтелде. Мондый очракларда, шулай ук бер партиялелелек нигезендә төзелгән парламентка яки хөкүмәткә эләккән кандидатлар хөкүмәттә халыкны түгел, ә халык арасында хөкүмәтне тәкъдим итәләр, дияргә мөмкин. Башка күпчелек илләрдә сайлаулар альтер-

натив нигездә уза, ягъни сайлаучыларга күпләр кандидатурасы арасыннан берсен сайлап алу мөмкинлеге бирелә. Кайбер илләрдә сайлау хокукы 18 яшьтән үк кертелә. Бу очракта әлеге яшьтәгеләрнең армиядә хезмәт итәргә, югары белем алырга, җәмгыять тормышында шактый роль уйнарга сәләтле булуы истә тотыла. Мәсәлән, КПРФ электоратын пенсионерлар һәм эшчеләр тәшкил итә, ә «Яблоко» электроратында яшьләр һәм урта яшьтәгеләр (эшмәкәрләр, менеджерлар, укытучылар, студентлар) күбрәк.

Парламент, президент яки муниципаль сайлауларда теге яки бу сәяси партия өчен тавыш бирүчеләр даирәсен ***электорат*** (латинчадан elector — сайлаучы) *дип атыйлар.* Партияләр башта үз электоратын булдыру өчен, аннары аны арттыру һәм саклап калу өчен көрәшәләр. Һәр электоратның үзенә генә хас үзенчәлекләре була.

Президент бар халыкның турыдан-туры тавыш бирүе белән сайланганда, ул күпчелек яки иң эре электорат яклавына таянырга тиеш. Президентны парламент сайлаганда, ул парламентта күпчелекне алып торган партиянең яки шул партиядәге күпчелекнең яклавын табарга тиеш.

Сәяси партияләр сайлаучылар тавышы өчен көндәшлек ярышы алып баралар. Башка партияләр сайлаучыларының бер өлешен үз якларына авыштырып, бер үк вакытта алар үзләренең сайлаучыларының бер өлешен югалталар. Чөнки партия үзенең элеккеге сәяси платформасын киңәйтеп һәм яңа килүчеләр өчен аны кулайрак ясап, бер үк вакытта аны үзенең элекке тарафдарлары өчен кулай булмаган хәлгә китерә. Нәтиҗәдә элеккеләр үз программаларын җиңелчә төзәтергә өлгергән башка партиягә күчәләр.

Сайлаулар бер яки ике турда узарга мөмкин. Әгәр дә берничә кандидатның берсе дә барлык тавышларның яртысыннан күбрәген җыя алмаса, икенче тур оештырыла, монда инде күбрәк тавыш җыючы җиңүче дип билгеләнә. Чынлыкта бу кабат сайлаулар була. Әгәр билгеле бер округтагы электорат сәяси теләктәшлеген төгәл билгеләмәсә һәм берничә кандидат арасында таркалса, кагыйдә буларак, кабат сайлаулар таләп ителә.

Кандидатны тавыш бирү исемлегенә кертү алдыннан, түбәндәгеләрне эшләргә тиеш: а) сәяси программасын халыкка

игълан итәргә; б) үз сайлаучыларының тиешле күләмдә имзаларын тупларга (имзалар саны, мәсәлән 10000 яки 100000, законда теркәлгән); в) сайлауларда барлык чыгымнарны түләүче йогынтылы партияләрнең, даирәләрнең, оешмаларның финанс яклавын алырга; г) үз керемнәрен һәм милеген күрсәтергә.

Әгәр кандидат кагыйдәләрне бозса (мәсәлән, керемнәре һәм милке күләмен дөрес күрсәтмәсә), сайлау комиссиясе аны кандидатлар исемлегеннән төшереп калдырырга хокуклы.

Төп мәсьәләләр буенча халык үз ихтыярын нинди ысул белән белдерсә, җәмгыятьнең сәяси тормышын, дәүләт төзелешен шул билгели. Андый ысулларның берсе — *референдум*.

> **РЕФЕРЕНДУМ** (латинчадан referendum — хәбәр ителергә тиешле нәрсә) — закон кабул итү формасы яки дәүләт тормышының аеруча мөһим мәсьәләләрен гомуми тавыш бирү юлы белән хәл итү. Турыдан-туры демократиянең бер формасы.

Ул җәмгыять өчен аеруча мөһим мәсьәләләрне бөтенхалык тавыш бирүе юлы белән хәл итүне күз алдында тота, мондый тавыш бирүнең нәтиҗәләре югары хокукый статуска ия һәм дәүләт органнарының барысы өчен дә мәҗбүри. Референдум дөньяның күпчелек демократик дәүләтләре тарафыннан закон чыгару механизмы буларак файдаланыла. Шуңа да карамастан, ул парламентның закон чыгару эшчәнлегенә карата буйсынулы мөнәсәбәттә тора. Референдумның икенчел статусы төрлечә чагылыш таба. Күпчелек илләрдә аны сәяси тормыш читенә күчерделәр, чөнки референдумнар даими төстә дәүләт дәрәҗәсендә түгел, ә җирле дәрәҗәдә генә үткәрелә. Мәсәлән, АКШта бу демократик институт бары тик федерация субъектлары (штатлар) һәм тагын да ваграк административ-территориаль берәмлекләр тарафыннан гына файдаланыла. Аңа бик җитди очракларда гына бөтен ил күләмендә мөрәҗәгать итәләр, мәсәлән, президент парламент белән көрәшкәндә халык яклавын алырга теләгән очракта шулай эшләнә.

Кайбер илләрдә (Бөекбритания) референдум инициаторлары булып парламент һәм хөкүмәт чыгыш ясый, ә башкаларында (Франция) — алардан тыш президент, өченчеләрендә (Италия) турыдан-туры халык инициатор була. Референдум узсын өчен анда күпчелек халыкның катнашуы мәҗбүри түгел. Бөтенха-

лык тавыш бирүе законнар кабул итү өчен генә түгел, ә аларны гамәлдән чыгару өчен дә файдаланыла. Франциядә ул Конституциягә төзәтмәләр керткәндә дә мәҗбүри санала.

Референдум — шактый катлаулы һәм кыйммәткә төшүче чара, әмма халык аның ярдәмендә үз ихтыярын белдерә, законнар иҗатчысына әверелә ала.

Төшенчәләр: *актив сайлау хокукы, пассив сайлау хокукы, электорат, референдум.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Актив һәм пассив сайлау хокуклары нәрсә белән аерыла?
2. Төрле социаль төркемнәрнең сайлауларда үз-үзләрен тотышын сыйфатлагыз.

*3. Уйлагыз, төрле социаль теркемнәрнең сайлауларда үз-үзләрен тотышы нинди сәбәпләрдән бәйле булырга мөмкин? Танышларыгызның сайлауларда үз-үзләрен тотышына конкрет мисаллар китерегез.

4. Электорат нәрсә ул? Аның активлыгы ничек исәпләнә? Россиядә иң актив электорат халыкның нинди өлешенә туры килә? Ул кем өчен тавыш бирә?
5. «Кайсы сәяси партияне кулайрак күрү» гыйбарәсен сез ничек аңлыйсыз? Ул нәрсәдән гыйбарәт?

*6. Сез кайсы сәяси партияне кулай күрәсез? Әти-әниләрегез кайсысын?

7. Сәяси тормышта референдумнар нинди роль уйный?

*8. Бәлки, референдумнар бик үк мөһим дә түгелдер? Аларны файдаланмаска мөмкинме яки референдум зарури очраклар да буламы?

Проблема. Безнең илдә яшьләрнең сайлау активлыгына ничек ирешергә мөмкин?

Практикум. Ни өчен?

1. Үткәрелгән сораштырулар раслаганча, теге яки бу партияне сайлауга партия лидерларының телевидение аша чыгышлары төп фактор буларак йогынты ясый (40%), сайлау алды роликлары икенче урында (13%), ә аннан соң өченче урында гына якыннар һәм туганнар киңәше тора (10%).
2. Әгәр президент барлык халыкның турыдан-туры тавыш бирүе белән сайлана икән, ул электоратның күпчелеге яклавына ирешергә тиеш.
3. Әгәр президентны парламент сайласа, ул күпчелек партияләр яки парламентта күпчелекне алып торган партия яклавына ирешергә тиеш.

§ 8 (§ 32). Сәяси партияләр

Теләсә кайсы дәүләттә сәясәтне халыкның күпчелеге яклавын тапкан һәм үз эшлекләләре аша теге яки бу төркемнәр, катлаулар, сыйныфлар мәнфәгатьләрен чагылдырган партияләр билгели. Алар сайлаучылар тавышы өчен көрәшә һәм күп очракта хакимияткә тыныч юл белән килә.

> **СӘЯСИ ПАРТИЯ** — уртак сәяси программага таянучы һәм, үз президентын куеп һәм үз хөкүмәтен төзеп, законлы юл белән хакимияткә килергә омтылучы бердәм кешеләр төркеме.

Ул *социаль төркемнәр мәнфәгатьләрен чагылдыручы һәм аларның иң аеруча актив вәкилләрен берләштерүче сәяси оешма* булып тора.

Әгәр парламентка депутатларны халык сайласа, партия җитәкчелеге партия җыелышларында яки съездларда сайлап куела. Партиянең барлык әгъзалары акчалата взнос түлиләр, партия аппараты шулар хисабына тотыла, партия чаралары үткәрелә, партия әдәбияты чыгарыла һ.б. Партия әгъзалары күбрәк булган саен, партия казнасы да баерак. Шуңа күрә һәр партия массачыл, зуррак һәм популяррак булу белән кызыксына. Киң яклау таба алмаган кечкенә партияләр тора-бара таркала, эрерәкләре белән кушыла, яңа рәвештә яшәп калырга өметләнеп, үзгәреш кичерә.

Халыкара аренада — төрле илләр, икътисадта — корпорацияләр һәм фирмалар, базарда — сатып алучылар һәм сатучылар арасындагы кебек үк, сәяси партияләр арасында да аяусыз көндәшлек көрәше бара.

Күп партияле система әле туып кына килгән илләрдә дистәләрчә, йөзләрчә сәяси партия һәм берләшмә исәпләнә. Электән үк демократик традицияле илләрдә күп партиялелек юк. Англиядә һәм АКШта икешәр җитәкче партия бар. Бу очракта халыкның сәяси теләктәшлеге икегә бүленә. Ике партия дә гаять зур, алар инде бер-берсен йота алмыйлар. Ике полюслы сәяси дөнья әнә шундый. Россия кебек күп полюслы дөньяда фикер бүленеше әлегә дәвам итә. Күпсанлы партияләрнең уртак билгеләре дә күп, еш кына алар бик кечкенә нәрсәләрдә генә үзгә булалар. СПС һәм «Яблоко» демократиячел, Көнбатыш юнәлешендәге базар мәнфәгатьләрен чагылдыралар, әмма бер-берсе белән кушылырга теләмиләр. Сайлаулар вакытында, гадәттә, алар өчен тавыш бирүче интеллигенция кемгә өстенлек

бирергә белми. Нәтиҗәдә электорат бүлгәләнә, һәр партия аерым-аерым азрак тавыш җыя, бергә булсалар, күбрәк тавышка ирешерләр иде.

Дөрес, соңгы вакытта алар арасында якынаю тенденцияләре һәм күп мәсьәләләрне хәл итүдә теләктәшлек күзәтелә. Күптән түгел генә оешкан «Бердәмлек» партиясе зур абруй казанды: аның вәкилләре Дәүләт думасында күпчелек тавышка ия. Аны инде хакимият партиясе дип атыйлар.

Сәяси партияләр — ил белән идарә итүдә контроль урнаштыруга омтылучы оешмалар. Алар — сәяси йогынтының иң төп чыганагы. Партияләр хөкүмәт һәм индивид арасында арадашчылык итәләр, шул ук вакытта үз лидерларын хакимияткә илтүче чара булып та торалар.

Сәяси партия башкара торган функцияләр:

— **сәяси** — дәүләт хакимиятен кулга төшерү;

— **вәкиллекле** — халыкның аерым төркемнәре һәм катлаулары мәнфәгатьләрен чагылдыру;

— **электораль** — сайлау кампанияләре оештыру һәм катнашу;

— **социальләштерү** — тугрылыклы әгъзалар тәрбияләү, гражданнарда сәяси культура тәрбияләү;

— **рекруиторлык** — сәяси яктан белемле кешеләрне парламентка һәм хөкүмәткә үткәрү өчен сайлап алу һәм тәкъдим итү.

Партиянең профессиональ сәясәтчеләре артыннан хакимияткә аларны әйләндереп алачак аппарат (партия экспертлары, аналитиклар, белгечләр) та килә.

Гражданнарны *сәяси социальләштерү*, хакимияткә карата теләктәшлек сыйфатлары һәм күнекмәләре формалаштыру да мөһим функцияләрдән санала. Сайлаучылар өчен көрәшеп, аларны рәсми органнарда яшерелгән яки мәгълүм булмаган мәгълүмат белән тәэмин итеп, партияләр кешеләр игътибарын күзгә күренмәгән каршылыкларга һәм конфликтларга юнәлтәләр, аларны ерып чыгу юлларын күрсәтәләр, җәмгыятьтә килеп туган хәлне гади гражданнар өчен аңлаешлы итәләр. Башка сәяси көчләр белән фикер төрлелеген төгәл билгеләү дә моның бер чарасы булып тора. Бу исә партия электоратына сәяси чынбарлыкта яхшырак ориентлашырга, тормышта үзләре күрмәгәннәрне күрә белергә ярдәм итә.

Сәяси партия хөкүмәт һәм аның сәясәте турында мәгълүмат җыя, бу мәгълүматларны аңлаешлы формада сайлаучыларга



җиткерә, сәяси постларга кандидатлар билгели, сайлауларда аларны яклау кампанияләре уздыра. Үз вәкилләрен хөкүмәткә көндәшләренә караганда күбрәк үткәреп, алар хөкүмәт өстеннән контроль урнаштыруга ирешәләр. Парламент, гадәттә, арадашчы станция булып хезмәт итә. Хакимлеккә омтылучы партия нәкъ менә анда күбрәк урын алырга тырыша. Әгәр дә билгеле бер илдә, мәсәлән, Англиядә, хөкүмәт парламентта күпчелекне алып торган партиядән төзелсә, югарыга юл турыдан-туры парламентта җиңү аша уза. Әгәр илдә, Конституция буенча, партия мәнфәгатьләреннән өстә торырга һәм бер партияне дә якламаска, әмма парламентка түгел, ә үзенә буйсынучы хөкүмәт төзергә тиешле президент хакимияте көчле булса, контрольгә башкача, ягъни хөкүмәт өчен кулай законнар чыгарып, парламентта аның эшчәнлеген тискәре бәяләп, аның карарларын кире кагып, матбугатта тәнкыйтьләп тә ия булырга мөмкин.

Башта партияләр хакимият өчен көрәшкә омтылучы бердәм оешмалар булып түгел, ә фикердәшләрне бердәштерүнең бер формасы булган төрле клублар, әдәби-сәяси оешмалар сыйфатында танылалар (Бөек француз революциясе заманындагы Кордельерлар клубы яки Англиядә XIX гасырның 30 нчы елларында төзелгән «Реформ Клаб»). Феодаль хакимияткә каршы көрәшүче беренче партияләрне либераль карашлар тарафдарлары төзи (Бөекбританиядә — вигилар, Германиядә — прогрессив партия, Бельгиядә — либераль партия һ.б.).

Шулай итеп, *партияләр тарихи яктан вәкиллекле структуралар буларак формалашалар*, һәм алар билгеле бер төркемнәр — дәүләткә һәм башка сәяси берләшмәләргә карата оппозициядә торучы институтлар мәнфәгатьләрен чагылдыралар. Элек тә, хәзер дә партияләр фикердәшләр берлегеннән гыйбарәт.

Бу төркем һәм катлаулар партияләр аша дәүләткә үз таләп һәм өметләрен җиткерәләр, мөһим мәсьәләләрне хәл итүдә үз партияләре ярдәменә ирешәләр. Шуңа күрә дә партияләрне *җәмгыять һәм дәүләт арасындагы арадашчылар* дип атыйлар. Үз ризасызлыгыңны хөкүмәткә белдерүзең һәм стихияле төстә җиткерү әле ул бер нәрсә. Әгәр дә инде шундый таләпләр тупланса, бер агымга җыелса, кемдер тарафыннандыр юнәлдерелсә, оештырылса, көчәйтелсә, бу инде бөтенләй башка нәрсә булачак. Партия җитәкчелеге — мини-хөкүмәт ул, анда үз эшләренең чын осталары эшли. Әмма алар барлык җәмгыятьне түгел, ә аның аерым өлешләрен яклыйлар.

Хакимиятләргә дәгъва, ризасызлык белдереп, партияләр халыкның дәүләт структуралары белән элемтәсен урнаштыралар, активлыкның стихияле формаларын максатчан юнәлдерелгән формалар белән алыштыралар.

Партияләр — *вәкиллекле демократия продукты* ул. Алар Борынгы Грециядә барлыкка киләләр, Урта гасырларда юкка чыгалар, аннан соң Яңа заманда тагын мәйданга атлыйлар. Күп гасырлар буена законнар бары тик король һәм аның киңәшчеләре тарафыннан гына кабул ителгәндә, партияләр бөтенләй булмый. Хәзерге типтагы партияләр Европада һәм Төньяк Америкада XVIII гасыр ахырында — XIX гасыр башында, халык сайлый торган закон чыгаручы хакимият формалаша башлагач кына барлыкка киләләр.

Шулай итеп, сәяси партияләр — җәмгыятьнең бер үк вакытта яшь һәм борынгы институты. Тавыш бирү хокукына ия кешеләр никадәр күбрәк булган саен, сәяси партияләр дә шулкадәр күптөрле һәм эрерәк була. Сәяси партияләр әле башлангыч кына алган вакытта АКШта һәм Англиядә алар бик аз санлы була, чөнки гражданнарның күпчелеге тавыш бирү хокукыннан мәхрүм хәлдә яши. Ул вакытта оешкан партияләр бай кешеләрдән (җирбиләүчеләрдән, сәнәгатьчеләрдән, сәүдәгәрләрдән) тора. XIX гасыр ахырында АКШта күпчелек ак тәнле ирләргә тавыш бирү хокукы кертелә. XX гасыр уртасында күпчелек илләрдә хатын-кызлар да тавыш бирү хокукына ия булалар. Тиз арада партияләр саны арта. Алар массакүләм төс ала. Төньяк Америка һәм Көнбатыш Европа үрнәгендә башка континентларда да партияләр оеша. Африкада һәр партия артында билгесез затлар түгел, ә мәгълүм кабилә

һәм кардәшлек төркемнәре тора. Якын Көнчыгышта партия әгъзалыгы теге яки бу дини оешмада тору белән билгеләнә.

Сәяси партияләр түбәндәгечә бүленә:

оештырылу ысулы буенча —

а) *парламент* (кадрлар) *партияләре* — алдынгы, күренекле сәясәтчеләрнең аз санлы берләшмәләре, алар, нигездә, парламент фракцияләрендә эшлиләр;

б) *массакүләм партияләр* — катлаулы структуралы һәм теркәлгән әгъзалыктан гыйбарәт күпсанлы берләшмәләр;

хакимияткә мөнәсәбәт буенча —

а) *идарә итүче партияләр*;

б) *оппозицион партияләр*, алар легаль (аларның эшчәнлеге дәүләт тарафыннан рөхсәт ителә) һәм легаль булмаган партияләргә (дәүләт тарафыннан тыелган, яшерен эшлиләр) бүленә;

әгъзалык төре буенча —

а) *ачык партияләр*, алар төрле социаль катлауларның иреклe әгъзалыгы белән билгеләнә;

б) *ябык партияләр*, партия әгъзалыгына кандидат булып торучыларга күпсанлы формаль таләпләр куела һәм аларга катлаулы кабул итү механизмы аша узарга туры килә.

җәмгыятькә мөнәсәбәт буенча —

а) *революцион партияләр* гамәлдәге стройны көч кулланып тамырдан үзгәртү өчен көрәшәләр;

б) *реформачыл партияләр* стройга өлешчә һәм эзлекле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәләр;

в) *консерватив партияләр* — болары гамәлдәге стройны саклап калырга тырышалар;

г) *реакцион партияләр* элек булган стройга кире кайтырга тырышалар;

сәяси программа төре буенча —

а) *сул партияләр* (коммунистик, социалистик, хезмәт партияләре) социаль түбән катлаулар мәнфәгатьләрен, җәмгыять милкен, көйләүле базарны яклыйлар;

б) *уң партияләр* (демократик, республикачы, либераль партияләр) югары һәм урта сыйныф мәнфәгатьләрен, көйләүсез базарны яклыйлар;

в) *үзәк партияләр* (социаль-демократик партияләр) — күбесенчә урта сыйныфларны яклыйлар һәм партияләр куйган кискен таләпләргә тартылмыйлар, килешүчәнлек позициясендә торалар.

Илдә булган партияләрнең барысын бергә ***партияләр системасы*** дип атыйлар. Ул: а) бер партияле, б) ике партияле һәм в) күп партияле була ала.

В.Шелохаев. Патша заманындагы күп партиялелек

Россиядә сәяси партияләр XIX гасырның 80 нче–90 нчы еллары чигендә, чама белән Көнбатыш Европа һәм АКШка караганда ярты гасырга соңрак барлыкка киләләр. Иң элек социалистик ориентацияле партияләр, аннан соң либераль һәм, ниһаять, уң консерватив партияләр формалаша (Көнбатышта киресенчә).

XX гасыр башында бездә 280 нән артык партия исәпләнә иде. Шуларның 60 ка якынын, шартлы рәвештә, Россия күләмендәге (кадетлар, РСДРП һ.б.), калганнарын региональ (мәсәлән, Туладагы «Патша һәм Ватан өчен») яки милли (мәсәлән, Әрмәнстандагы Дашнакцутюн) партияләргә кертеп булыр иде.

Партияләрнең үз карамакларында матбугат органнары, клублар, халык йортлары була, алар сайлау кампанияләрендә гомумроссия дәрәҗәсендә дә (Дәүләт думасына), шулай ук региональ дәрәҗәдә дә катнашалар (земство һәм шәһәр үзидарәсе органнарына). Күпчелек партияләрнең үз символикалары була: анархистларда — кара байраклар, кадетларда — яшел, социал-демократларда һәм эсерларда — кызыл, консерваторларда кара-ак-көрән флаглар яки хоругвлар.

Партияләрнең күплегенә карамастан, аларда торучыларның гомуми саны әллә ни зур булмый. 1906–1907 елларда ул гомуми халык санының 0,5% ын тәшкил итсә, 1917 елның февраленнән соң 1,2–1,5% ка арта.

Дистә ел дәвамында (1907–1917) партияләрнең һәм алардагы әгъзалар саны кимүе күзәтелә. Россия сәнәгатьчеләре һәм эшмәкәрләре оешмалары, кайбер либераль партияләр сәяси аренадан төшеп калалар. Кайбер партияләр фракцияләргә таркала. Патша Россиясендә кризис көчәйгән саен, социалистик юнәлештәге партияләр роле арта. Анархистик һәм экстремистик тенденцияләр илдә барлыкка килгән хакимият бушлыгына большевиклар ыргылганга кадәр дәвам итә.

Чыганак: АиФ.— 1995.— №46.

Кайбер илләрдә бер генә партияле система гамәлдә. Кытай, Куба, Төньяк Африка илләре шундыйлар. Башкаларында исә ике партияле система үзенең файдалы булуын раслады. АКШ, Англия һәм Канада шундый илләргә керәләр. Күпчелек Европа державалары, аерым алганда, Германия, Италия, Бельгия күп партияле системага ия. Авторитар режим вакытында хакимиятне бер партия били. Башкалары яки тыелган, яки ярым яшерен хәлдә яшиләр. Мексикада 12 партия теркәлгән, ә хөкүмәтне бер генә — Инстуциональ революцион партия контрольдә тота. Монда партияләр арасында түгел, ә бер партиядәге урыннар өчен конкуренция җәелә.

Россия Федерациясе Конституциясендә сәяси күптөрлелек һәм күп партиялелек таныла (13 нче статья). Бөтен иҗтимагый берләшмәләр тигез хокуклы. Хәзерге вакытта безнең илдә дистәләрчә партия бар, әмма күп партияләрнең чын социаль базасы, беренчел оешмаларының тармаклы челтәре юк, аларда торучылар саны бик аз.

> **КҮП ПАРТИЯЛЕЛЕК** дип илдә икедән артык легаль сәяси партия булган партия системасын атыйлар.

Ике һәм күп партияле система вакытында бер генә партия озак вакытка җиңә алмый. Күп партияле системада мондый хәл тагын да кискенрәк сиземләнә. Сәяси контрольгә ия булырга омтылучы партияләр коалициягә кереп, *партия блогы* төзиләр. Бер-берсе белән бәйләнеш урнаштырган партияләр уртак кандидатны тәкъдим итәргә, финанслар, кадрлар мәсьәләсен бергәләп хәл итәргә һәм эш-гамәлләрне үзара килештереп эшләргә вәгъдәләшәләр. Сайлау алды очрашуларында лидерлар булачак хөкүмәтнең (ул җиңгән очракта) уртак сайлау алды программасын һәм уртак сәяси платформасын билгеле бер тәртипкә китерәләр, аннан соң аларны үзләренең партия съездларында раслыйлар. Коалициядәге партияләр, гадәттә, үзләренең тигез яки пропорциональ күләмнәреннән чыгып, абруйлы кандидатлар һәм министрлар саны буенча үзара килешәләр.

Сәяси партиягә хас түбәндәге ***билгеләрне*** аерып күрсәтәләр:

— *сәяси программа* булу, анда партиянең максаты һәм стратегиясе формалаштырыла;

— *сәяси устав булу*, анда партиянең эчке тормышының мөһим нормалары туплана;

— *җитәкче органнар* (үзәк комитет) һәм күп очракта азат эшләүче партия функционерлары аппараты булу;

— *беренчел җирле оешмаларның тармаклы челтәре булу*, ул ирекле активистлардан тора;

— дәүләттә югары хакимият өчен көрәшкә *актив катнашу*.

Сәяси программа — җәмгыятьнең булачак төзелеш тәртибен сыйфатлаучы, хакимияттәге хөкүмәткә тәнкыйть белдерүче, халык йөзгә-йөз бәрелгән көнүзәк социаль һәм икътисади проблемаларны хәл итү чараларын һәм ысулларын чагылдыручы нигезләмәләр тупламасы ул. Сәяси программа декларатив расламалар белән тулылана. Ул расламалар ярдәмендә партия күпчелек сайлаучылар яклавын һәм тавышын яулап алырга тырыша. Программа күп очракта үзенчәлекле сәяси реклама булып тора. Партия хакимияткә килү белән, үзенең күпчелек яки бер өлеш игълан ителгән максатларыннан баш тарта яки аларга шактый үзгәрешләр кертә. Моның сәбәбе — объектив чынбарлык: яңа хөкүмәт килү белән үзгәреш кичергән халыкара хәл, дәүләт бурычы, дәүләт бюджеты күләме, ил эчендәге сәяси көчләр торышының үзгәреш кичерүе һәм каршы яктагыларның көче, яңа хөкүмәттә квалификацияле белгечләр булу һәм хакимияткә килгән партия йөзгә-йөз очрашкан тагын шундый башка төрле сәбәпләр. Яңа чынбарлык партия оппозициядә торган һәм гамәлдәге хөкүмәтнең җитешсезлекләрен тәнкыйтьләгән замандагыдан бөтенләй үзгә булып чыга.

Төшенчәләр: *сәяси партия, күп партиялелек, сәяси программа.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сәяси партияне сыйфатлагыз һәм җәмгыятьтә аның урынын күрсәтегез.

***2.** Сәяси партиянең ике сыйфаты — фикердәшләрнең оешкан төркеме булу һәм демократиянең вәкиллекле институты буларак хезмәт итү — үзара каршылыкка кермиләрме? Үз фикерегезне әйтегез.

***3.** Сәяси партияләр күплеге демократия үсешенең кайсы стадиясе турында сөйли? Җавабыгызны аңлатып бирегез.

4. Күп партиялелек нәрсә һәм ул төрле илләрдә ничек чагылыш таба?

***5.** Ни өчен АКШта һәм Англиядә әйдәп баручы партияләр икәү генә булуга карамастан, демократиягә зыян килми, ә Россиядә

партияләр күп, тик демократик үзгәртеп корулар бик авырлык белән бара?

6. Сәяси партияләр ил өстеннән контрольне ничек тормышка ашырырга мөмкин? Сез моны безнең ил яки чит илләр үрнәгендә аңлата аласызмы?

7. Сәяси партия нинди функцияләр башкара? Бу функцияләрнең кайсысын иң мөһим дип исәплисез? Әгәр дә берсе икенчесенә каршы килә башласа, моннан сәяси партиянең абруе зыян күрәме?

Проблема. Ничек уйлыйсыз, яшьләргә сәяси партияләр эшендә катнашу кирәкме?

Практикум. Сәяси партия функцияләрен тасвирлаучы таблицаның ике баганасын бер-берсенә тәңгәлләштереп куегыз.

Функция атамасы	Функциянең эчтәлеге
сәяси	халыкның аерым төркемнәре һәм катлаулары мәнфәгатьләрен чагылдыру
рекруиторлык	тугрылыклы әгъзалар тәрбияләү һәм гражданнарда сәяси культура формалаштыру
социальләштерү	сайлау кампанияләрен оештыру һәм аларда катнашу
электораль	төрле сәяси институтлар өчен кадрлар әзерләү һәм тәкъдим итү
вәкиллекле	дәүләт хакимиятен кулга төшерү



2 (5) нче бүлек. КЕШЕ ҺӘМ АНЫҢ ХОКУКЛАРЫ

Без бу бүлектә һәр гражданга кагылышлы мәсьәләләрне күтәрербез. Бу — кешеләрнең хокуклары һәм бурычлары, аларның закон алдында җаваплылыгы өлкәсе, биредә закон бозу сәбәпләре һәм нәтиҗәләре ачыклана. Хокук гади гражданнарның көндәлек тормышын оештыручы социаль нормалар категориясенә карый. Шуңа күрә бу бүлектә хәзерге заман яшүсмерләре өчен әһәмиятле булган юридик мәсьәләләргә аерым игътибар юнәлтеләчәк.

§ 9 (§ 33). Хокук

Без һәркөнне *юридик әһәмияткә* ия күп кенә гамәлләр кылабыз. Чөнки кеше җәмгыятьтә үз-үзен тотышын билгеле бер кагыйдәләргә — *социаль нормаларга* буйсындыра. Бу нормалар безгә теге яки бу ситуациядә үзебезне ничек тотарга кирәк булуын билгели.

> **Социаль нормалар** — үз-үзеңне тиешле рәвештә (җәмәгатьчелек тарафыннан хупланган рәвештә) тоту күрсәтмәләре, таләпләре.

Бу — кеше аларга сукырларча иярә дигән сүз түгел. Ул тормышта максатларын һәм аларга ирешү юлларын үзе билгели. Һәр кешенең үз язмышы. Дуслык мөнәсәбәтләре дустыңа бәла килгәндә ярдәм кулы сузарга кирәк икәнен күз алдында тота. Әмма үз карьералары хакына дусларына хыянәт итүче, алардан йөз чөерүче кешеләр дә бар. Җәмәгатьчелек тарафыннан андый гамәлләр гаепләнә. Мондый бәяләр әхлакый

характерда булалар, ә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр әхлак нормалары, *ягъни мораль нормалар* белән җайга салына. Бу нормалар яхшылык һәм начарлык, гаделлек һәм гаделсезлек турындагы күзаллауларны ныгыта. Әлеге күзаллаулар чыганагы булып дин — христианлык, буддизм, ислам һ.б. тора.

Эстетик нормалар безнең гүзәллек һәм килбәтсезлек турындагы, шулай ук кешеләрнең үз-үзләрен тотышындагы шундый ук сыйфатлар турындагы күзаллауларыбызны чагылдыралар, югарыдагы ситуацияне (дусларга хыянәт итү) ямьсез дип бәялиләр.

Шулай итеп, җәмгыятьтә кабул ителгән барлык кагыйдәләр
— **рөхсәт итәләр,**
— **күрсәтмә бирәләр,**
— **тыялар.**

Алар арасында дәүләт тарафыннан саклаучы кагыйдәләр үзенчәлекне роль уйныйлар, аларны бозган өчен *юридик җаваплылык* каралган. Бу кагыйдәләр җыелмасыннан *хокук* хасил ителә. Аны өйрәнү белән махсус фән — *юриспруденция* шөгыльләнә, ул өлкәдә профессиональ эшләүчеләр *юристлар* дип атала.

Бик борынгы заманнарда ук туган бу профессия «изге эш» дип саналган. Юристларны каһиннәр (жрецлар) белән тиңләгәннәр, чөнки алар гадел хөкем оештырганнар, мәрхәмәтлелекне явызлыктан, гаделлекне гаделсезлектән аерганнар һәм кешеләрне начар гамәлләре өчен җәзага тартканнар. Борынгы Римда императорлар алар консультациясеннән башка берни дә эшли алмаганнар. Хөкүмәт махсус советлар оештырган һәм юристлар мәктәпләре эшчәнлеген тәэмин итеп торган.



Юриспруденциянең мөһим төшенчәләре белән танышыйк.

Хокук үз атамасын латин телендәге «justitia» (дөреслек, гаделлек) сүзеннән алган, ул борынгы заманда мәрхәмәт һәм гадел эш кылу осталыгы буларак аңлашылган. Шуннан бирле бер генә җәмгыять тә хокуктан башка яши алмый: ул, эш-гамәлләрнең, үз-үзеңне тотуның төгәл кагыйдәләрен урнаштырып, конфликтларны хәл итәргә булыша. «Хокук» сүзе төрле мәгънәгә ия. Сез үзегез дә моны бик яхшы беләсез. Һәр кешенең белем алырга хокукы бар. Бу очракта ул мәктәптә, вузда укырга рөхсәт ителү, төрле фәннәрне өйрәнеп, белем алу буларак аңлашыла. Монда хокук гамәлләр мөмкинлеге булып тора.

Ә менә, мәсәлән, бер егет сабый баланы кыерсыта. Ачуыннан ярсыган әти кеше аңа: «Синең болай эшләргә хакың юк иде», — дип кычкыра. Бу очракта хокукка юридик мәгънә салынмый, һәм ул гадел булмаган гамәлгә бәя буларак яңгырый. Башкача (юридик) аңлаганда, хокук үз-үзеңне тотуның, эш-гамәлләрнең билгеле бер кагыйдәләре буларак гәүдәләнә. Алар җәмгыятьтә кешеләрнең бергәләп тормыш итүләрен тәртипкә салу өчен барлыкка киләләр. Аларны һичшиксез үтәргә кирәк. Дәүләт хокук сагында тора, әмма аны үзе уйлап чыгармый. Дәүләт хакимияте хокукны кертә, безгә бүләк итә яки тартып ала алмый. Ул бары тик аны сакларга гына тиеш. Ә без *хокукны үз-үзеңне тотуның бар кеше өчен дә мәҗбүри булган кагыйдәләре системасы* буларак тикшерербез, ул кагыйдәләр дәүләт тарафыннан рөхсәт ителә (санкцияләнә) һәм билгеле бер нормаларда гәүдәләнә. Тормышыбызда бу мәгънәдәге хокукны түбәндәге *билгеләр* буенча җиңел аерып була:

1. Хокук норматив-хокукый актларда гәүдәләнә. Сез кайсы гына законны укысагыз да, анда язылган кагыйдә хокук була.

2. Хокукны дәүләт органнары, вәкаләтле затлар, махсус рәвештә, хокук иҗат итү эшчәнлеге барышында кабул итәләр.

3. Хокук бозган өчен һәрвакыт юридик җаваплылыкка тартылалар.

4. Хокук кешеләрнең билгеле бер гамәлләрен генә җайга сала, аларның хисләре һәм тойгылары дөньясына тыкшынмый.

5. Хокук мәңгелек түгел. Аны кешеләр булдыра һәм алар аны үзгәртә дә алалар, әмма хокук барлык кешеләр өчен дә бер үк төрле була.

ХОКУК

- билгеле бер рәвештә эш-гамәл кылу мөмкинлеге
- хокук чыганакларында чагылыш тапкан юридик нормалар

ХОКУК

- табигый (кешегә табигать тарафыннан тумыштан ук бирелгән, аны беркем дә тартып ала алмый)
- позитив (кешеләр тарафыннан аңлы рәвештә барлыкка китерелә, үзгәрешләр кертелә)

ХОКУК

- гомумхалыкныкы (хокукый мөнәсәбәтләрдә субъектлар тигез түгел, берсе генә булса да хакимияткә килә)
- шәхси (анда катнашучылар — эшлекле партнерлар, аларның шәхси мәнфәгатьләренә кагыла)

ХОКУК — һичшиксез үтәлергә тиешле кагыйдәләр системасы, алар дәүләт тарафыннан рөхсәт ителә (санкцияләнә) һәм билгеле бер нормаларда гәүдәләнеш таба.

Хокук нормалары иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең якынча 70% ын җайга сала. Галимнәр исәпләвенчә, үз-үзебезне тотышыбызны катгый хокукый кысаларга кертү, бу аеруча хакимиятнең кырыс күрсәтмәләре рәвешендә башкарылса, хакимиятнең башбаштаклыгына, диктатура урнашуга китерергә мөмкин. Кеше мондый очракларда дәүләт механизмының пассив «шөребенә» әверелә, аның һәр адымы контроль астына алына. Хокукның җәмгыятькә йогынты өлкәсенең бик нык тарайтылуы да хәтәр.

Хокук чынлыкта безнең тормышыбызга бөтенләй катнашмый дип күз алдына китерегез. Нәкъ шул чакта хаос һәм тәртипсезлек башланачагына төшенү кыен түгел. Бердәм кагыйдәләр булмау сәбәпле, дәүләт һәр кешене яклый алмаячак. Хокук мәрхәмәтлелек һәм намуслылык идеалларына туры китереп төзелгән гадел җәмгыятьнең нинди булырга тиешлеге турындагы күзаллаулар нигезендә барлыкка килә. Анда мораль, эстетик һәм башка социаль нормаларның элементлары бергә кушыла.

8 нче сыйныф дәреслегенең 3 нче бүлегендә бирелгән 17 нче параграфта сүз барган социаль статус җәмгыятьнең социаль структурасындагы бер позицияләрне, хокук һәм йөкләмәләр (бурычлар) системасы аша, башка позицияләр белән бәйли. «Укытучы» статусы «укучы» статусына карата гына мәгънәгә ярашлы, ә менә сатучы, җәяүле яки инженерга карата аны кулланып булмый. Алар өчен ул бары тик индивид кына.

Укытучы укучыга фәнни белемнәрен тапшырырга, аның белемен тикшерергә, билге куярга, тәртибен күзәтергә тиеш. Аның укучыны аттестацияләмәү һәм аны икенче елга калдыру хокукы да бар. Ә моның яшүсмер язмышына ничек йогынты ясаячагын һәркем белә. Укучы даими рәвештә дәресләргә йөрергә, укытучы таләпләрен үтәргә, өйгә бирелгән эшләрне башкарырга тиеш. Икенче төрле әйткәндә, социаль статуска ия булган укытучы һәм укучы бер-берсе белән ике социаль төркем вәкилләре буларак социаль мөнәсәбәтләргә керәләр.

Социаль статусның эчтәлеге җәмгыятьтә аңа беркетелгән хокуклар һәм йөкләмәләр җыелмасы аша ачыла. Сез метрода вагонга кергәч, «Пассажирның төп хокуклары һәм бурычлары»н күрәсез. Алар шушы статусның асылын ачалар. Статусларның бер өлеше әнә шундый формаль инструкцияләр белән билгеләнә, аларның икенче өлеше язылмаган хокукларга һәм йөкләмәләргә, ягъни традицияләргә таяна. Күршелек статусы үз-үзеңне иркле тоту мөмкинлеген бирә. Монда бернинди дә катгый рәсми таләпләр юк. Булган очракта да алар формаль яки мәҗбүри булмаган характер алалар. Күршелек гамәлләре үзара котлауларны, исәнләшүләрне, көнкүреш кирәк-яракларын алып-биреп торуны, конфликтлы хәлләрне бергәләп хәл итүне күз алдында тота. Әмма бер кеше күршеләр белән аралашырга теләми, ә икенчесе артык аралашучан һәм хәтта бәйләнчек була.

ЙӨКЛӘМӘ (бурыч) — теге яки бу кешегә йөкләнгән һәм һичшиксез үтәлергә тиешле эш-гамәлләр яки бурычлар.

Юлбашчы дини йолаларны башкарырга, үз статусларына кагылышлы таләпләрне бозган кабиләдәшләрен җәзага тартырга, хәрби походларда әйдәүче булырга, община җыелышында җитәкчелек итәргә хокуклы. Университет профессоры аны студенттан аерып торучы кайбер хокукларга ия, ә студентның мондый хокуклары юк. Ул студентларның белемнәрен бәяли, әмма студентларның укуда начар өлгереше өчен штрафка

тартылырга тиеш түгел. Ә менә офицер, хәрби устав таләп иткәнчә, солдатлар кылган тәртипсезлекләр өчен җәзага тартыла.

Профессорның академиклык статусы шундый ук статуска ия булган башка кешеләр, мәсәлән, сәясәтче, табиб, юрист яки бизнесмен ия булмаган хокуклар да бирә. Мәсәлән, ул кайбер сорауларга: «Мин моны белмим»,— дип тә җавап кайтара ала. Бу академикның компетентлы булмавы белән түгел, ә белемнәрнең табигате һәм фәннең торышы белән аңлатыла.

Йөкләмәләр (бурычлар) шушы рольдәге яки шушы статустагы кеше башка рольдәге яки статустагы кешеләргә карата нәрсә эшләргә тиеш булуын күрсәтәләр. Хокуклар кешенең башкалар белән мөнәсәбәтләрендә нәрсә эшли алуын билгеләләр. Хокук һәм йөкләмәләр төгәл билгеләнгән. Алар кешенең үз-үзен тотышын билгеле бер кысаларга куялар, аның нинди адым ясаячагы алдан ук мәгълүм була. Шул ук вакытта алар үзара бик нык бәйләнгән, һәм аларның берсе икенчесен күз алдында тота, берсе икенчесеннән башка була алмый. Дөресрәге, алар аерым-аерым яши ала, әмма ул вакытта социаль структура бозыла. Мәсәлән, борынгы дөньяда колның статусы бары тик йөкләмәләрдән генә торган һәм аның бернинди дә хокуклары булмаган диярлек. Тоталитар җәмгыятьтә хокук һәм йөкләмәләр бүленеше тигез түгел: идарәченең һәм югары вазифадагы затларның хокуклары максималь, ә йөкләмәләре бик аз. Киресенчә, гади гражданнарның йөкләмәләре күп, хокуклары аз. Демократик җәмгыятьтә хокук һәм йөкләмәләр бүленеше тигез диярлек. Димәк, җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсе социаль структурада хокук һәм йөкләмәләрнең ничек урнашуыннан бәйле була.

Теге яки бу йөкләмәләрне үтәп, индивид башкалар алдында билгеле бер күләмдә *җаваплылык* мөнәсәбәтендә тора. Итекче, мәсәлән, заказчы йөкләгән эшне вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарырга тиеш. Әгәр шулай түгел икән, ул ничектер җәзага тартылырга — контрактсыз калдырылырга, штраф түләргә тиеш, хәтта аның профессиональ репутациясенең зыян күрүе ихтимал, аны хөкемгә тартырга мөмкиннәр. Борынгы Мисырда болай булган: әгәр архитектор начар бина төзеп, ул җимерелеп төшсә һәм хуҗасын сытып үтерсә, архитекторның үзен дә үтергәннәр. Җаваплылык чагылышы формалары әнә шундый. Алар күптөрле һәм җәмгыятьнең төзелешеннән, культура дәрәҗәсеннән, тарихи заманнан бәйле.

Хокуклар *йөкләмәләр* белән аерылгысыз бәйләнгәннәр. Статусы югарырак булган саен, кешенең хокуклары да күбрәк, һәм аңа шулхәтле үк күбрәк йөкләмәләр дә өелә. Кара эшче статусы таләп иткән йөкләмәләр бик аз. Күрше, хәерче яки бала турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Ә менә президент яки танылган телевидение күзәтүчесе статусы аның белән бер даирәдә торган социаль стандартларга туры килерлек булуны һәм шуларга хас тормыш рәвеше алып баруны таләп итә.

Шунысы мәгълүм, хокук һәрвакытта булмаган. Ул — *кешелекнең цивилизация юлы буенча дәвамлы һәм авыр хәрәкәте нәтиҗәсе*. Хокук борынгы ыруглык җәмгыятендә дә булмаган. Анда кешеләр инде урнашкан *гореф-гадәтләр* һәм *традицияләр* кушканча яшәгәннәр. *Гореф-гадәтләр* — гадәт буенча үтәлүче кагыйдәләр ул. *Традицияләр* җәмгыять кушуы буенча үтәләләр. Традицияләр һәм гореф-гадәтләр тылсымлы йолалар, ритуаллар һәм чаралар белән әйләндереп алынган, алар үзенчәлекле күтәренкелек рухында һәм тантаналы шартларда башкарылган. Мәсәлән, борынгы славяннар, туендыручы җирне хөрмәтләп, аңа казык кагарга курыкканнар һәм яз көне коймалар кормаганнар — җирне саклаганнар. Шуннан бирле аларда җирне үбү, җир белән ант итү, бер уч туган җир туфрагын саклау гадәте һ.б. сакланган. Үз ата-бабалары *күрсәтмәләрен* кешеләр катгый рәвештә үтәгәннәр. Мондый кагыйдәләр беркая да язылмаган, буыннан-буынга телдән генә тапшырылып киленгән. Соңрак аларны документларда терки башлаганнар.

Кешенең эш-гамәлләренә кертелгән *тыюлар* (табу) — хокукның беренчел формасы була. Мәсәлән, хайваннарның аерым төрләрен аулау яки туганнар белән җенси мөнәсәбәткә керү тыелган. Кешеләр тормышы билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнә. Соңрак мондый кагыйдәләр дәүләт тарафыннан беркетелә. Иң борынгы законнар безгә Месопотамиядән килеп җиткән. Аларның авторы — б.э.к. XXIV гасырда яшәгән Шумер идарәчесе — законнар ярдәмендә базар бәяләрен җайга салырга тырышкан. Ул вакытта әле төгәл юридик тел урнашмаган була, бер законда кешеләр мөнәсәбәтләренең төрле өлкәләрен тәртипкә китерүче нормалар бергә кушыла, ә законнарга илаһи характер бирелә. Үз законнарының керешендә идарәче аларның мәңгелек булуларын һәм аллалардан бирелүләрен искәртә. Кайбер хәзерге заман җәмгыятьләрендә әле дә юридик законнар илаһи көчкә бәйләп аңлатыла.

Әмма законнар илаһи ихтыярны таратучы булып кына хезмәт итмиләр, ә җәмгыятьне килештерү коралы булып та торалар. Хокук *үз-үзләрен тоту турында кешеләрнең үзара килешүен* чагылдыра. Кагыйдәләрнең бер өлеше кешенең башкача түгел, нәкъ менә шулай эшләргә тиешле *йөкләмәсенә* әверелә, ә икенче өлеше башкача түгел, нәкъ менә шулай эшләү *хокукына* әйләнә. Беренчесе эш-гамәлләр иреген чикли, ә икенчесе киңәйтә. Безнең һәрберебез белем алырга хокуклы, ягъни безгә мәктәптә, колледжда яки вузда уку *рөхсәт ителгән*. Хокук эш-гамәлләр *мөмкинлеген* аңлата. Борынгы законнарда башлыча ирекне чикләүләр теркәлә, ә ирек үзе, аеруча ярлылар өчен, бөтенләй булмый. Ирек буларак каралган хокук — яңа заман казанышы ул.

Борынгы монархлар барлык хокукларны үзләре ягында калдыралар, хәтта аларны төгәл билгеләп тә тормыйлар, чөнки алар үзләренә бар нәрсә дә рөхсәт ителгән дип исәплиләр. Бүгенге көндә тигез хокуклар һәм ирекләр бар кешегә дә бирелгән. Әмма иң мөһиме шул — кешенең төп хокуклары тумыштан ук килә. Алар кешегә граждан буларак түгел, ә кеше буларак бирелә. Мондый хокуклар *табигый хокуклар* дип атала. Һәр кешенең тумыштан ук табигый хокуклары бар. Әле генә дөньяга килгән сабый яшәргә һәм ирекле булырга хокуклы. Соңрак аларга *гражданлык хокуклары* өстәлә, алар кешегә ирекле яшәргә генә түгел, ә җәмгыятьнең сәяси, икътисади, социаль һәм рухи тормышында актив катнашу мөмкинлеге бирә. Әлеге хокукларга, аерым алганда, хезмәткә, һөнәргә, милеккә хокук керә.

Борынгы заманда табигый һәм гражданлык хокуклары бүгенге кебек булмый. Бер кабилә икенчесен буйсындыргач, аны үз законнарын онытырга һәм чит законнар буенча яшәргә мәҗбүр итә. Борынгы Грециядә һәм Борынгы Римда яшәүчеләр

ХОКУК ФУНКЦИЯЛӘРЕ

жайга салу (җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, анда катнашучылар өчен билгеле бер модельләр билгели)	саклау (саклый, кешеләр мәнфәгатьләрен яклый, закон бозучылар өчен юридик җаваплылык кертә)

ике категориягә бүленгән: гражданнарга һәм граждан булмаганнарга. Алар төрле законнарга буйсынган.

Кешегә билгеле бер дәрәҗәдәге *хокукый аң* хас. Бу хокук нормаларын белү генә дигән сүз түгел, ә аларга карата *шәхси мөнәсәбәт* тә.

Күп кенә гаиләләрдә сабый бала варенье банкасына рөхсәтсез тыгылмый. Ул ачуланырлар дип куркудан түгел, вареньеның бөтен гаиләнеке икәнен бик яхшы белгәнгә шулай эшли. Җәмгыятьтә дә шул ук хәл күзәтелә. Югары хокукый аңга ия кешеләр җинаять кылмыйлар; алар үзләрен җәза көтә дип уйлаганга түгел, законнарны һәм җәмгыятьне хөрмәт иткәнгә начар эшкә бармыйлар. Ә башкалар законны санга сукмыйлар, аны ачыктан-ачык яки яшерен рәвештә бозалар, аңа үзләренең илтифатсыз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Төрле дәрәҗәдәге хокукый аң — законнарга карата төрле мөнәсәбәт. Сез ничек уйлыйсыз, безнең җәмгыятьтә хокукый аң дәрәҗәсе нинди?

«Хокукый аң» төшенчәсе яңа һәм бик мөһим «*хокукый культура*» төшенчәсен тудыра.

ШӘХЕСНЕҢ ХОКУКЫЙ КУЛЬТУРАСЫН хокукны белү һәм аңлау, шулай ук аңа тиң булган эш-гамәлләр тәшкил итә.

Хокук катлаулы структурага ия, аның үз нормалары, институтлары, тармаклары бар.

Бу системада барысы да үзара бәйләнгән. Аның нигезе — **юридик нормалар**, алар норматив-хокукый актларда теркәлгән. Мәсәлән, гражданнарның тыныч юл белән узган демонстрацияләрдә, халык белән бергәләп урамда йөрүләрдә катнашуы хокукый норма булып тора. Бу норма РФ конституциясендә теркәлгән. Ә менә массакүләм тәртипсезлекләр оештырган өчен 4 елдан 10 елга кадәр вакытка иректән мәхрүм итү каралган (Җинаять кодексы). Башкача әйткәндә, юридик норма *хокук нормасы* дип атала.

> **ХОКУК НОРМАСЫ** — кешеләрнең теге яки бу хокукый ситуациядә үз-үзләрен тоту кагыйдәсе, ул һичшиксез үтәлергә тиеш. Хокук нормасы норматив-хокукый актларда теркәлгән.

Шундый нормаларны бозучылар хокукый, яки ***юридик җаваплылыкка*** тартыла. Күп кенә хокукый нормалар структурасында санкцияләр аерылып тора — бу хокук бозучы үз өстендә кичерәчәк күңелсез нәтиҗәләр. (Мәсәлән, автомобиль йөртүче, хәрәкәт тизлеген арттырса, штрафка тартыла. Әнә шулай, юридик хокукны бозган өчен, ул җаваплылыкка тартыла.)

Тормышыбызда күпсанлы хокук нормалары бар, алар, һичшиксез, күптөрле. Галимнәр ул нормаларны түбәндәге төрләргә бүлделәр:

а) **тыючы нормалар** (мәсәлән, кешеләрне сәяси оешмаларга керергә яки чит кеше әйберләрен урларга мәҗбүр итү ярамый);

б) **йөкләмәле нормалар** (пассажир транспортта баруы өчен түләргә тиеш);

в) **хокукны гамәлгә ашыручы нормалар** (бала тугач, әти-әниләр акчалата ярдәм — пособие ала)



Бертөрле, типик һәм темалары буенча үзара якын хокукый мөнәсәбәтләрне көйләүче хокукый нормалар җыелмасы ***хокук тармакларын*** хасил итә. Аларның кайберләрен карап үтик.

Конституцион хокук. Аңа илебезнең дәүләт төзелешен билгеләүче нормалар, хакимият һәм идарә органнары эшчәнлеге кагыйдәләре керә. Алар гражданнарның хокукларын һәм йөкләмәләрен (бурычларын) күрсәтә. Мәсәлән, РФ Конституциясендә һәр гражданның торакка хокукы булуы турында әйтелә. Ул кагылгысыз: торакта яшәүчеләрнең теләгеннән башка беркемнең ул торакка үтеп керү хокукы юк (РФ Конституциясенең 40 нчы маддәсе).

Җинаятькә каршы хокук. Монда кешеләрнең җинаять адымнарын һәм алар өчен хөкем чарасын билгеләүче нормалар туплана. Мәсәлән, законсыз рәвештә порнографик материаллар тараткан һәм рекламалаган өчен кеше 500 дән алып 800 минималь окладка кадәрге күләмдә штрафка тартыла яки ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителә (РФ ЖКның 242 маддәсе).

Административ хокук. Аны хакимият органнары һәм билгеле бер вәкаләтләре булган кешеләр һәм гражданнар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы нормалар тәшкил итә. Шәһәр транспортында йөрү кагыйдәләре буенча, пассажирлар утырып барган өчен түләргә тиешләр. Кагыйдәләрне бозган очракта штраф каралган, штрафны контролерлар ала, аларның моңа тулы хокукы бар.

Гражданлык-процессуаль һәм җинаяти-процессуаль хокук гражданлык һәм җинаять эшләрен хәл итү тәртибен көйләүче нормалардан тора. Аларның берсе түбәндәгечә яңгырый: әгәр судтагы судья, утырышчы, прокурор яки секретарь суд эше нәтиҗәсе белән турыдан-туры яки башкача кызыксына икән, алар эшне тикшерүдә катнаша алмыйлар һәм бу эшне караудан читләштерелергә тиеш (РФ ГПКның 17 нче маддәсе).

Гражданлык хокукы. Милек һәм милеккә кагылышы булмаган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала. Аңа милекне мирас итеп алу, милек хуҗасы булу һәм аның белән эш итү, вәгъдә куешу, намус һәм абруйны саклау тәртипләрен билгеләүче нормалар керә. Мәсәлән, теләсә кайсы вәгъдәнең яки бурычның тиешенчә үтәлүе зарури. Әгәр сез бурычка акча алып торгансыз икән, аны кире кайтарырга, алай гына да түгел, ә вакытында кайтарырга тиешсез (РФ ГКның 309 нчы маддәсе).

Хезмәт хокукы эш бирүчеләрнең һәм эшләүчеләрнең хез-

мәт процессындагы һәм хезмәткә кагылышлы мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала. Мәсәлән, хезмәткәрләр үз предприятиеләре милкен сакларга тиешләр. Әгәр зыян китерәләр икән, матди җаваплылыкка тартылалар (РФ ХТЗКның [КЗОТның] 118 нче маддәсе).

Гаилә хокукы. Ир кеше белән хатын-кыз арасындагы өйләнешү, аерылышу һәм гаилә тормышы барышындагы мөнәсәбәтләрне көйли. Ул ата-аналарның һәм балаларның хокукларын һәм бурычларын билгели. Бу нормалар күрсәткәнчә, өйләнешү өчен ир кеше белән хатын-кыз арасында үзара килешү булырга тиеш, һәм аларның өйләнешү яшенә җитүе зарур (РФ Гаилә Кодексының 12 нче маддәсе).

Безнең илдә барлык норматив-хокукый актлар юридик көчләре буенча бүленәләр, ягъни *иерархия* төзиләр: кайберләре югарырак дәрәҗәдә булса, башкалары түбәнрәк тора. *Төп закон — Конституция — илдә иң югары юридик көчкә ия.* Аны кабул итүдә илнең барлык гражданнары катнаша. *Федераль законнар* аннан түбәнрәк тора. Алардан соң ил *президенты указлары* килә. *Хөкүмәт карарлары* алардан астарак тора. Болардан да түбәндәрәк урынны *министрлыклар, ведомстволар* һәм *җирле үзидарә органнары норматив актлары* били.

Төшенчәләр: *социаль нормалар, хокук, хокукый культура, хокук нормасы, хокук тармагы.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Хокук нәрсә ул һәм аның билгеләре нинди? «Хокук» юридик төшенчәсенең гомум кабул ителгән мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Хокук һәм йөкләмәләр социаль статуста үзара ничек бәйләнгән? Бу бәйләнешне мәктәп укучысы үрнәгендә тасвирлап күрсәтегез.

3. Закон һәм хокук белән йөзгә-йөз очрашкан вакыйгаларыгыз турында сөйләгез. Закон һәм хокукны ничек сыйфатларга мөмкин?

*4. Кешенең эш-гамәлләрен чикләүче хокукый нормаларга мисаллар китерегез. Хокук кешенең эш-гамәлләрен чикләмәсә, ни булыр иде? (Теләдем — үтердем, чит кеше әйберен алдым, эшләгән эш өчен түләмәдем.)

5. Кешенең хокукый культурасы ни өчен кирәк? Ничек уйлыйсыз, ул сездә бармы?

6. Хокукның кайсы тармаклары белән сез танышырга өлгердегез? Аларга кыскача сыйфатлама бирегез.

*7. Хокукның бер тармагы икенчесеннән мөһимрәк дип әйтеп буламы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

*8. Демократик һәм тоталитар дәүләтләрдә хокук системаларының төп аермаларын анализлагыз.

? Проблема. Дәүләттә хокуклар йөкләмәләрдән башка яши аламы?

Практикум. 1. Ике юрист бәхәсләшә. Аларның берсе, хокук ул «һәрвакыт гадел һәм мәрхәмәтле булган» нәрсәне белдерә — кешенең табигый хокукы әнә шундый, ди. Икенчесе, каршы килеп, хокук ул теге яки бу дәүләттә «бар кешегә яки күпчелеккә файдалы» нәрсәләрне белдерә — гражданның хокукы әнә шундый, дип билгеләп үтә.

Аларга бәхәстән чыгарга булышыгыз.

2. Хокук тармакларын тасвирлаучы таблицаның ике баганасы эчтәлеген бер-берсенә дөрес итеп тәңгәл китерегез.

Хокук тармаклары атамасы	Хокук тармагы эчтәлеге
Җинаятькә каршы хокук	Хакимият органнары һәм гражданнар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.
Административ хокук	Җинаятьне һәм аны хөкем итү чарасын билгели.
Гражданлык-процессуаль һәм җинаяти-процессуаль хокук	Милекне мирас итеп алу, намус һәм абруйны саклау, милек хуҗасы булу һәм аның белән эш итү, вәгъдә куешу тәртипләрен билгели.
Хезмәт хокукы	Эш бирүчеләр һәм эшләүчеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тәртибен урнаштыра.
Гаилә хокукы	Ир кеше белән хатын-кыз арасындагы өйләнешүне, аерылышуны һәм гаилә тормышы барышындагы мөнәсәбәтләрне көйли.
Гражданлык хокукы	Гражданлык һәм җинаять эшләрен хәл итү тәртибен билгели.

§ 10 (§ 34). Закон һәм хакимият

Бик борынгы заманнардан ук хакимият һәм закон аерылгысыз дип исәпләнгән.

XI гасырда Киев митрополиты Иларион «Закон һәм бәрәкәт турында сүз» («Слово о законе и благодати») дигән китап яза,

анда закон кешеләргә карата теләсә нинди түгел, ә бары тик гадел эш-гамәлләрне генә күз алдында тота, диелә. Һәм алар Ходай кушкан эш-гамәлләр дип атала. Ходай тарафыннан бүләк ителгән хакимияткә ия булган һәм гадел, икенче төрле әйткәндә, «хак» законнар чыгаручы патша Ходай ихтыярын аңлап алырга, кабул итәргә тиеш. Хакимият «хак» булырга, ягъни законга нигезләнергә бурычлы. Бөек кенәз барлык эшләрен закон буенча башкарырга: юмарт, мәрхәмәтле булырга, «ятимнәр, авырулар, толлар турында кайгыртырга» тиеш.

Гасырлар уза. Патшалар чикләнмәгән башбаштаклык кыла һәм үзләре язып законнар чыгара башлыйлар. Иван Грозныйның замандашы кенәз Андрей Курбский (1528–1583), хәзер «рәттән бар нәрсәне эләктерәләр», судсыз, тикшерүсез җәзага тарталар, дип яза. Ә салымнарны күтәрү турындагы законнар берничек тә Ходай кушкан закон була алмый һәм күп очракта гаделсез эшкә юнәлдерелә. Ходай тарафыннан яратылган кешеләр, дәүләт законнарына таянып, бер-берсен (мәсәлән, ата-аналар үз балаларын) коллыкка саталар. Әгәр дә патша гадел булмаган законнар чыгара икән, кешеләр әхлакый (мораль) яктан аңа каршы тору хокукына ия булалар. Шулай итеп, кайчандыр бербөтен булган юридик һәм әхлак нормалары аерылалар. Аларның арасы өзелү аңлап булмаслык нәтиҗәләргә китерә. Законнарга буйсынмау әхлакый аклану таба.

Бераз соңрак патшага ярдәмгә күп тармаклы бюрократик аппарат килә. Ул мөмкин һәм мөмкин булмаган циркулярлар, карарлар, күрсәтмәләр һ.б. законга тиң актларны шулкадәр күп чыгара башлый, хәтта үзе дә буталып бетә, подданныйларын аптырашта калдыра. Рус крестьяннары теләсә кайсы законны, хәтта дәүләткүләм мөһим булганын да, чиновникларның ялган уйдырмасы дип карый башлыйлар. Законнарга буйсынмау гадәти хәлгә әверелә. Бүген Россиядә дәүләт хезмәтендә эшләүчеләр бер-берсенә каршы килүче, бер-берсен юкка чыгаручы һәм чикләүче күпсанлы норматив актлар эшлиләр.

Галимнәр инде күптән шундый закончалыкны билгеләделәр: ***законнар күбрәк булган һәм буталган саен, аларны шулкадәр начаррак үтиләр.***

Чиновниклар хәзер законга хезмәт итмиләр — алар законны үзләренә хезмәт күрсәтергә мәҗбүр итәләр. Беренче адымны ясаганнан соң дәүләт үз хезмәткәрләре тарафыннан тагын бер адым атлый — хакимият мәгънәсен үзгәртә.

Элек ул (хакимият) кешеләргә аларның тормышын җайга салу өчен кирәк иде. Әгәр дә хакимият бөтен нәрсәне бутап бетерә торган законнар чыгара икән, димәк, бернинди дә хакимият кирәк түгел дигән сүз. Өстәвенә, закон барлык кешеләр өчен дә язылмый булып чыга. Көнчыгыш деспотлары, корольләр законнарны үзләре өчен түгел, башкалар өчен язалар. Алар законнан өстә торалар. Закон алдында бар кешенең дә тигез булуы бозыла. Бу очракта закон закон булудан туктый, чөнки законның төп принцибы түбәндәгечә яңгырый: закон каршында барысы да тигез, анда искәрмәләр булмый.

Закон совет хакимияте заманында да бик күп тапкырлар бозыла. Аның яраткан (югары дәрәҗәдәге чиновниклар) һәм яратмаган «балалары» (гади халык) була. 80 нче еллар уртасында илебез җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп кора башлады, бу үзгәрешләр илне базарга гына түгел, закон хакимлек иткән демократиягә илтергә тиеш.

Законнарны профессиональ әзерлекле кешеләр чыгара һәм үти башлый. Берәүләр парламентта утыра (депутатлар), башкалар хөкүмәттә эшли (министрлар), өченчеләр Югары суд составына керә. Хәзерге хакимиятнең ***өч төп тармагы*** бар: ***закон чыгаручы, башкарма*** һәм ***суд хакимиятләре***.

Шулар нигезендә югары дәүләт органнары төзелә. Россиянең ***югары закон чыгаручы органы — парламент,*** ягъни ***Федераль Җыелыш***, ул ике палатадан — *Федерация Советыннан* һәм *Дәүләт думасыннан* тора.

Россиядә беренче Дәүләт думасы 1906 елда барлыкка килә. Патша хакимиятен чикләп, ул үзе дә чикләүле башлангычларда төзелә: ул вакытта хатын-кызларның, 25 яшькә җитмәгән кешеләрнең, укучыларның, хәрбиләрнең, губернаторларның һ.б. сайлау хокуклары булмый.

Дәүләт думасында кабул ителгән законнар Федерация Советына яклауга керә, ә аннан соң президентка бирелә, ул исә 14 көн эчендә законга кул куя һәм аны халыкка игълан итә. Президент законны кире кагырга да мөмкин. Бу очракта парламент аны яңадан тикшерә.

Законнарны үтәү өчен ***башкарма хакимият*** куела. Аңа буйсынучы зур аппарат тотыла. Монда төп рольне премьер-министр җитәкчелегендәге ***хөкүмәт*** башкара. Ул күрсәтмәләр һәм карарлар чыгара. Аның вәкаләтләре һәм төзелү тәртибе законда теркәлгән.

Дәүләт башлыгы — президент. Бу сүз Борынгы Римда ук кулланыла һәм барысы арасында беренче кешене, «алда утыручыны» аңлата. Ил президенты — Россия гражданы ирешә алган иң югары вазифа. Аны халык 4 елга сайлап куя. Элек, Россия законнары буенча, сабый бала да дәүләт башлыгы (патша) була алган, бүген 35 яшькә җиткән һәм ачык тавыш бирү юлы белән сайланган граждан гына бу вазифаларны башкарырга мөмкин.

Өстәвенә, президент булыр өчен, Россиядә даими рәвештә ун ел яшәү шарт; бу постны рәттән ике тапкырдан да артык биләргә ярамый.

Россиядә беренче тапкыр президентлык институты 1991 елда кертелә. Закон буенча, президент Кораллы Көчләрнең Югары Башкомандующие булып тора. Ул үзе белән атом-төш чемоданын йөртә, илнең оборона сәләте мәсьәләләрен контрольдә тота. Президент үз хакимиятен указлар һәм боерыклар аша тормышка ашыра. Алар ил законнарына каршы килмәскә тиеш. Президент законнарга кул куя, әмма аның вето (аларны тыю) хокукы да бар. Дәүләт башлыгының вәкаләтләре күп. Мәсәлән, ул Дәүләт думасы ризалыгы белән хөкүмәт рәисен, хөкүмәт әгъзаларын билгели, хөкүмәтне, хөкүмәт әгъзаларын отставкага җибәрү турында карарлар чыгара. Ул Дәүләт думасына сайлаулар билгели һәм Думаны тарата да ала. Президент Куркынычсызлык советын формалаштыра.

Безнең ил күп милләтле. Аның составына республикалар керә. Аларның үз Конституцияләре һәм законнары бар. Аларда хакимият органнары төрлечә атала. РФ Конституциясе урыннарда *үзидарә органнары* эшчәнлеген таный. Алар үзәк органнарга карамаган җирле проблемаларны хәл итәләр (урамнарны җыештыру, шифаханәләр салу, мәктәп проблемалары һ.б.). XIX гасырда Россия авылларындагы бу мәсьәләләрне *земстволар* хәл иткән. Аларның составында дворяннар да, сәүдәгәрләр дә, крестьяннар да булган. Хәзер һәр регионның үз думалары, советлары, җыелышлары бар. Аларда халык сайлап куйган депутатлар эшли. Шәһәрләрдә мэрлар, префектлар бар, алар конкрет территориядә идарә итү белән шөгыльләнәләр. Старосталар, атаманнар пәйда булды. Барлык җирле үзидарә органнары устав нигезендә эшлиләр һәм үзләренең хокукый актларын чыгаралар.

Безнең илдә төрле судлар эшли. Һәр судның үз вәкаләтләре.

Әгәр илдә кертелгән законнар илнең төп законына туры килми икән, ***Конституцион судка*** мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Ул Конституциягә аңлатма бирә һәм барлык закон актларының Конституциягә туры килүе турындагы бәхәсләрне хәл итә. Бу суд Конституциягә каршы килүче законнарны юкка чыгарырга мөмкин.

Җинаять, гражданлык, административ һәм хезмәткә кагылышлы эшләрнең күпчелеге *гомуми юрисдикция судларында* хәл ителә. Бу термин белән *суд хакимияте өлкәсен* атыйлар. Андый судларга Югары суд, крайлар, өлкәләр һәм шәһәр (район) судлары керә. Армияләрдә, гарнизоннарда, флотта *хәрби судлар* эшли.

Судта юридик белемле һәм закон нигезендә генә гамәлләр кылучы профессионал белгечләр хезмәт итә. Судьялар алыштыргысыз һәм кагылгысыз. Аларга халык вәкилләре ярдәм күрсәтә. Суд утырышчылары һәм антлы утырышчылар була. Соңгылары катлаулы җинаять процессларында катнашалар. Алар билгеле бер территориянең сайлаучылары арасыннан (25 яшьтән соң) компьютер җирәбәсе ярдәмендә суд тарафыннан сайлап алыналар. Болар — профессиональ булмаган юристлар.

Антлыларның беренче судлары XII гасырда Англиядә, XIX гасырда Россиядә барлыкка киләләр. 1917 ел вакыйгаларыннан соң юкка чыккан антлылар суды 1993 елда яңадан эшли башлады. Антлылар хөкем ителүчегә гаепле яки гаепсезлек вердикты чыгаралар.

Һәр кешенең судка мөрәҗәгать итү хокукы бар. Моның өчен гариза — дәгъва (иск) язарга кирәк. Аның белән мөрәҗәгать итүчене *дәгъвачы* (истец) дип атыйлар. Ә менә дәгъва гаризасы кемгә мөнәсәбәтле булса, аны *җавап тотучы* (ответчик) диләр. Дәгъва гаризасы билгеле бер үрнәк нигезендә тутырыла. Аңа эш барышы өчен кирәкле дәлилләр һәм документлар да өстәлә.

Якларның үзара ярышы Россия суд эше барышының мөһим үзенчәлеге. Яклаучыны җинаять кылуда шик астына алынган

кеше янына кертәләр. Җинаять эшләре буенча каралган суд процессында суд гаепләүне хуплаучы прокурорны һәм яклаучы адвокатны тыңларга тиеш. Судтагы барлык эшләр дә ачыктан-ачык бара. Һәр теләгән кеше суд эшендә катнаша ала. Аерым очракларда гына эшләр ябык ишекләр артында уза. XX гасыр башында сәяси процесслар ябык рәвештә үткәрелә. Патша тормышына кул күтәрү, гамәлдәге тәртипләргә каршы чыгу очракларына кагылышлы эшләр әнә шулай хәл ителгән.

Хәзерге законнар кушканча, дәүләт һәм коммерция серенә кагылышлы эшләр, җенси җинаять, кешеләрнең интим тормышы, 16 яшькә җитмәгән кешеләрнең җинаятьләре турындагы эшләр дә ябык ишекләр артында уза. Безнең илдә суд эшләрен карау рус телендә бара. Кешеләр телне белмәгән очракта, аларга тәрҗемәче билгеләнә. Суд эшен карау суд карары белән тәгәлләнә, карар дәүләт исеменнән хөкемнәр һәм карарлар рәвешендә чыгарыла.

Юридик затлар арасындагы эшмәкәрлек өлкәсенә кагылышлы икътисади бәхәсләр *арбитраж судларда* карала. Алардан тыш *третейский судлар* да бар. Алар ике якның үз ихтыярлары белән төзеләләр һәм бәхәсләшүче якларның вәкилләреннән торалар. Третейский судларда эшләрне карау түләүсез башкарыла. Әмма мондый судлар илнең суд системасына кермиләр.

Урыннарда *халык (мировой) судьялары* эшли. Алар әллә ни катлаулы булмаган хокукый бәхәсләрне хәл итәләр. Мондый атама аларның җирле халыкка («мир»га) якын булуы белән бәйләнгән. Гасырлар дәвамында кешеләр «халык общинасы» («мировая община») булып яшиләр һәм күп кенә мәсьәләләрне бергәләп хәл итәләр.

2000 елның ноябрь ахырында Бөтенроссия судьялары съезды булды, анда РФ президенты да катнашты. Съездда катнашучылар суд реформасы үткәрү һәм суд законнарын эшләү (җинаять-процессуаль кодексны әзерләү, административ судлар булдыру, хәзергә 9 регионда гына эшләүче антлылар суды эшен яхшырту һ.б.) зарурлыгы турында сөйләделәр. Алар башка күп кенә проблемалар турында да (мәсәлән, суд эшләрен карауның гамәлдәге рәвеше һәм кайбер законнар хәзерге таләпләргә җавап бирмиләр, күп кенә мөһим мәсьәләләрнең нәтиҗәле хәл ителүенә комачаулыйлар) фикер алыштылар.

Россиянең мөһим хокук саклау органы булып *милиция* тора. Россия милициясендә үз вазифалары булган махсус бү-



лекләр бар. Мәсәлән, *Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе* ил юлларында тәртипне тәэмин итә, җәяүлеләрнең дә, машина йөртүчеләрнең дә закон билгеләгән кагыйдәләрне үтәвен күзәтә. *Паспорт-виза хезмәте* кешеләрнең ил эчендә күченеп йөрүе, аларның дәүләт чикләреннән читкә чыгуы, шулай ук чит ил кешеләренең Россиягә килүе өчен җавап бирә.

Криминаль милиция җинаятьләрне ачыклау, куркыныч гамәлләр кылучы кешеләрне эзләү белән шөгыльләнә. Эчке эшләрнең бу бүлегендә җинаятьчеләрне эзләү (уголовный розыск), тикшерү бүлекләре, икътисади җинаятьләр белән көрәшүче махсус бүлекләр бар.

Хокук саклау органнары шәхес һәм дәүләт иминлеген тәэмин итәләр. Хокук саклау көчләренең төп органы булып *РФның Куркынычсызлык советы* тора, аның белән ил президенты җитәкчелек итә. Ул Советның секретарен һәм әгъзаларын билгели. Бу вазифаларга министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, тышкы эшләр министры, эчке эшләр министры, сәламәтлек саклау министры һ.б. куелырга мөмкин.

Шпионаж, террор актларын, коррупцияне, наркобизнесны ачу белән *Федераль куркынычсызлык хезмәте* (Федеральная служба безопасности — ФСБ) шөгыльләнә.

Чит дәүләтләрнең, кешеләрнең Россиягә карата эш-гамәл-

ләре һәм планнары хакында мәгълүмат алу өчен *тышкы разведка органнары* эзләү-күзәтү эшчәнлеге җәелдерәләр. Кешеләрнең һәм төрле товарлар төягән транспортның безнең ил чикләре аша үтүе аерым тәртип белән җайга салына. *Федераль чик буе хезмәте* (Федеральная пограничная служба) шушы тәртип сагында тора. Дәүләт казнасына салымнар, түләүләр керүне *салым хезмәте* (налоговая служба) һәм *салым полициясе* (налоговая полиция) контрольдә тота.

Законнарның үтәлеше *прокуратура* күзәтүе астында тора. Прокурор җинаятьләрнең законга ярашлы тикшерелүен контрольдә тота. Ул судта эш тикшерелгәндә дәүләт гаепләүчесе буларак катнаша. Прокурор тикшерүчеләрнең законсыз карарларын юкка чыгарырга, суд хөкем карарыннан ризасызлык белдерергә хокуклы.

РФ хокук саклау органнарына *нотариат* керә. Нотариуслар документларның төп нөсхә булуын, фактлар дөреслеген һ.б. раслыйлар. Аларның күбесе үз эшләрен ачалар. Мәскәү нотариуслары «Намус кодексы» («Кодекс чести») кабул иттеләр. Анда аларның клиентлар белән ягымлы булырга, эшкә соңга калмаска тиешлеге турында гына түгел, ә шикле урыннарда йөрмәскә тиешлеге турында да әйтелә. «Кодекс» кагыйдәләрен бозу корпорациядән чыгарылуга кадәр китерергә мөмкин. Шәхси эшчәнлекне тормышка ашыру өчен *лицензия* алу таләп ителә. Адвокатура халыкка хокукый ярдәм күрсәтә, ул ирекле рәвештә тупланган юристлардан гыйбарәт була. Адвокатлар теге яки бу юридик мәсьәләләр буенча консультацияләр, аңлатмалар бирәләр. Гражданлык судында адвокат вәкил буларак катнаша, ә җинаять судында яклаучы була. Ул үзенә тапшырылган тикшерү астындагы кешенең серен сакларга тиеш. Предприятиеләрдә һәм фирмаларда *юрисконсультлар* бар. Алар җитәкчеләргә эшмәкәрлек эшен юридик яктан дөрес башкарырга булышалар, төрле договорлар төзиләр, судта фирма мәнфәгатьләрен яклап чыгалар.

Төшенчәләр: *Федераль Җыелыш, хөкүмәт, президент, Конституцион суд, хокук саклау органнары, адвокатура.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Аңлатыгыз, хакимият һәм закон үзара ничек бәйләнгәннәр? Төгәл мисаллар китерегез.
2. Хөкүмәт ни өчен кирәк? Аның вәкаләтләре нинди?

*3. Француз философы Ш.Монтескье болай яза: «Хакимияттән законсыз файдалану булмасын өчен, төрле хакимиятләр бер-берсен үзара тыеп торырлык тәртип урнаштырылырга тиеш». Сез бу фикерне ничек аңлыйсыз? Әлеге принципны бер мисалда тасвирлап күрсәтегез.

4. Хокук саклау органнары дәүләттә нинди роль уйныйлар? Сезнең нинди хокук саклау органнарына эшегез төшкәне бар? Мисаллар китерегез.

Хәзерге Россия хакимияте төзелешен тасвирлагыз.

Хәзерге хакимиятнең өч төп тармагын атагыз.

*5. Борынгы грек философы Менандрның «Көч патшалык иткән җирдә закон көчсез» дигән фикере белән килешеп буламы?

*6. Законнарны үтәмәү илне һәм җәмгыятьне нинди нәтиҗәләргә китерер иде, фараз кылыгыз.

? **Проблема.** Хокук саклау органнары үз вазифаларын сыйфатлы итеп башкарсын өчен, халык аларны хөрмәт итәргә һәм яратырга тиешме? Әллә бу мәҗбүри түгелме?

Практикум. Хәзерге Россиянең үзәк хакимият органнары схемасын төзегез.

§ 11 (§ 35). Конституция

Конституция (латинчадан constitutio — төзелеш, корылыш) — **дәүләтнең Төп законы**, *ул җәмгыять һәм дәүләт төзелешен, хакимиятнең вәкиллекле органнарын төзү тәртибен һәм принципларын, сайлау системасын, гражданнарның төп хокукларын һәм бурычларын билгели.* Ул дәүләтнең нигезләрен, максатын һәм төзелешен, аның оешу һәм эшләү принципларын, сәяси ихтыяр туу һәм карарлар чыгаруны, шәхеснең дәүләттәге урынын билгеләүче тотрыклы кагыйдәләрдән (законнардан) торган махсус документларда (яки берничә документта) теркәлгән җыентыктан гыйбарәт.

1689 елда Англия парламенты «Хокуклар турында билль» (латинчадан bulla — мөһер, мөһерле документ) чыгара, ул король хакимиятен чикли, парламентның хокукларын һәм ирекләрен гарантияли. АКШта Конституция 1787 елда барлыкка килә, ә 1789 елда аңа беренче 10 төзәтмә кертелә («Хокуклар турында билль»), алар 1791 елда гамәлгә керә. Фран-

циядә «Кеше һәм граждан хокуклары Декларациясе» (1789 ел) Конституциягә әверелә, ул Бөек француз революциясенең сәяси манифесты була.

Совет дәүләтендә **1918** елгы РСФСР Конституциясе иң беренчесе була. Бүген бездә 1993 елның 12 декабрь референдумында кабул ителгән Россия Федерациясе Конституциясе гамәлдә.

Конституция гражданнар һәм дәүләт арасында төзелгән «иҗтимагый договор» тексты буларак карала, ул дәүләт эшчәнлеген тәртипкә сала. Халыкның күпчелеге ризалыгы белән кабул ителүче Конституция кешеләрнең бергәләп яшәве өчен кирәкле иҗтимагый ризалык минимумын билгели.

Конституцияләр ике мөһим өлештән торалар. Беренчесендә гражданнар һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр нормалары, шәхес хокуклары билгеләнә, гражданнарның тигез хокуклыгы раслана; икенче өлештә дәүләт характеры (республика, монархия, федерация һ.б.), төрле хакимиятләр статусы, президент, парламент, хөкүмәт һәм судның үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы кагыйдәләр тасвирлана, шулай ук идарә органнары структурасы һәм эшчәнлек тәртибе турында языла. Конституциядә, гадәттә, аерым дәүләт учреждениеләре һәм институтлары турында тәфсилле нигезләмәләр күрсәтелми. Парламент яки президент аппараты Конституциянең төп нигезләмәләренә төгәллек кертүче законнар эшли.

Конституция кешенең шушы ил гражданы буларак хокукый статусын беркетә.

КЕШЕНЕҢ ХОКУКЫЙ СТАТУСЫ аның хокуклары һәм йөкләмәләре (бурычлары) җыелмасын тәшкил итә.

РФ Конституциясе безнең илнең Төп законы буларак эшли. Аның нигезен кеше хокукларын яклаучы халыкара документлар тәшкил итә, ягъни:

1948 — Кеше хокукларының гомуми Декларациясе.

1950 — Кеше хокукларын һәм төп ирекләрне саклау турында Европа Конвенциясе.

1959 — Бала хокуклары Декларациясе.

1960 — Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турындагы Пакт.

1966 — Гражданлык һәм сәяси хокуклар турында Пакт.

1989 — Бала хокуклары турында Конвенция.

Конституцияне төзү проектлары инде күптән мәгълүм булса да, безнең илдә ул бары тик XX гасырда гына барлыкка килә.

1649 елда кертелгән Собор уложениесе — законнар кодексы — беренче Конституция (аны «протоконституция» дип атыйлар) була, аны Земский собор кабул итә һәм патша Алексей Михайлович раслый. 1918 елгы Конституция (аның нигезендә «Хезмәт иләре һәм эксплуатацияләнгән халык хокуклары Декларациясе» ята) эшчеләрнең буржуазия өстеннән җиңү яулавын һәм пролетариат диктатурасын беркетә. Бу атамада яңа дәүләт гражданнарының тигезсез хәле чагылыш таба. Руханилар, жандармерия хезмәткәрләре һәм милек хуҗалары күп кенә хокукларыннан мәхрүм ителә. 1924 елда башка Конституция гамәлгә кертелә, ул гражданнар һәм яңа союз дәүләте — СССР арасындагы мөнәсәбәтләрне терки. Конституциядә үз гражданнары өчен якты киләчәк төзүгә юнәлтелгән идеологик күрсәтмәләр чагылыш таба (1936 һәм 1977 елгы Конституцияләрдә). Аларның беренчесе илдә социализм җиңүен игълан итә, ә икенчесе «нык үскән социализм»ны раслый. Болар сәяси документлар иде. Башкача фикер йөртүчеләр эзәрлекләнә. Аларны дәүләтнең иң явыз җинаятьчеләре һәм дошманнары дип исәплиләр.

Бүген Россия гражданы булу нәрсәне аңлата?

Беренчедән, юридик нормалар билгеләгән хокукларга ия булу.

Икенчедән, дәүләттән хокуклар саклануга гарантия алып, аңа нәрсәдәдер бурычлы булу.

Безнең һәрберебез ил гражданы булып тора яки, билгеләнгән кагыйдәләргә таянып, гражданга әверелә ала. Сез ни өчен Россия гражданы булдыгыз соң? Тәгаен, сез бу дәүләт территориясендә тугансыз һәм сезнең әти-әниләрегез дә ил гражданнары булып торалардыр. Гражданлыкка кабул итәргә дә мөмкиннәр. Моның өчен кеше махсус гаризада гражданлыкка кабул итүне сорап мөрәҗәгать итә, карарны президент чыгара. 18 яшькә җиткән һәр кеше дә мондый хокукка ия. Әмма монда бик мөһим шарт бар — кеше РФда биш ел дәвамында даими яшәгән булырга тиеш. Кайбер категория кешеләр өчен бу вакыт кыскара (качаклар һ.б.). Россиянең һәр гражданы үз теләге белән гражданлыктан чыгарга да мөмкин.

Әмма гражданны мәҗбүри рәвештә гражданлыктан мәхрүм итеп булмый. Шулай да мондый кагыйдәләр безнең ил тарихында булгалады. Аеруча гамәлдәге сәяси режимга каршы үз позицияләрен белдерүчеләрне яратмый иделәр. Алардан котылуны хуп күрделәр. Дәүләт алар белән бәйләнешне өзә килде.

30 нчы елларда кертелгән паспорт кешенең Россия гражданы булуын раслаучы документ була. 14 яшькә җитеп, паспорт алганга кадәр гражданнар туу турындагы таныклыкта теркәләләр. Шулай итеп, әгәр кеше Россия гражданы булып тора икән, ул хокукларга һәм бурычларга ия була.

РФ Конституциясендә теркәлгән төп хокукларны шәхси (яшәүгә хокук), ***сәяси*** (сүз, вөҗдан, фикерләр иреге), ***гражданлык*** (сайлау хокукы), ***социаль-икътисади*** (хезмәткә, ялга, белемгә, чиста экологиягә) һәм ***мәдәни*** (милли мәдәнияткә, телгә) хокукларга классификацияләргә мөмкин.

Гражданның шәхси хокукларына, аерым алганда, *яшәүгә хокук керә*. Кеше үз тормышын ничек корырга икәнлеген мөстәкыйль хәл итә ала. Кемдер тормыш өчен куркыныч эшне сайлый (каскадерлар, космонавтлар, сынаучылар). Кайберәүләр үзләре өстендә тәҗрибә үткәрәләр: даруларны, сывороткаларны сынап карыйлар. Закон үз-үзенә кул салучыны җавапка тартмый. Ә башка берәүне үтерү — бу җинаять, аның өчен җәза бирелә. Әмма җәза да кешене кимсетә торган булмаска, аңа газаплар китермәскә тиеш, чөнки һәр кешенең һәм граждан-

ның *газаплардан, көч куллануга дучар булудан саклану хокукы* бар. Дәүләт үз гражданнарына *шәхси* һәм *гаилә серен саклау* хокукы биреп, аларның шәхси тормышына тыкшынмый. Ул, гадел хөкемнең законлы нигезләренә таянып, үз гражданнарының намусын һәм шәхесен саклый. Шуңа күрә кимсетү һәм яла ягу өчен җаваплылыкка тарту каралган.

Сәяси һәм гражданлык хокукларына *фикер* һәм *вөҗдан ирегенә хокукны* кертәләр. Бу — граждан илдәге теләсә кайсы вакыйга турында үз фикерен, карашларын ирекле рәвештә әйтә, ниндидер проблемаларның хәл ителмәвенә бәйләп, җитәкче органнарны тәнкыйтьли ала дигән сүз. Моның өчен аны төрмәгә дә утыртмыйлар, эшеннән дә кумыйлар, чөнки ул үз гамәлләрендә булган хокукыннан файдалана. Әмма бу хокукта чикләүләр дә бар. Сугышка өндәүләр, халыклар арасында күралмаучылыкка, көч куллануга чакырулар тыела. Вөҗдан иреге гражданның үзе сайлаган теләсә кайсы динне тота алуын белдерә. Дәүләт аңа ниндидер бер динне көчләп такмый һәм дин тотмаучыларны эзәрлекләми. Граждан атеист та булырга, ягъни бернинди динне дә тотмаска мөмкин. Россия гражданнарының *нигезсез кулга алулардан һәм илдән куылулардан саклану хокукы, ярдәм сорап судка мөрәҗәгать итү хокукы бар.* Гражданнар тыныч юл белән үткәрелүче *митингларда, җыелышларда катнашырга хокуклы.*

Дәүләт эшләрен алып баруда һәм суд эшләрендә катнашу хокукы иң мөһим хокуклардан санала. Бу хокукка таянып, гражданнар сайлауларда һәм референдумнарда катнашалар. Депутатлар кемнәр алар? Бу — үз хокукларыннан файдаланган гражданнар. Граждан үзләре яшисе урынны үзләре сайлап алырга, бер шәһәрдән икенчесенә күчәргә, читкә китәргә мөмкин. Әмма һәрвакытта да бу шулай булмаган. Элек крепостной үз теләге белән хуҗасыннан китә, башка урынга күчә алмаган. Ирекка бары тик законсыз рәвештә качып кына чыгып булган. Ул вакытта дәүләт эзләү системасын гамәлгә керткән.

Икътисади һәм социаль-мәдәни хокукларга *хезмәткә һәм ирекле рәвештә һөнәр сайлауга хокук* керә. Хәзер дәүләт гражданны эшләргә мәҗбүр итми. Ул — аның хокукы, ә бурычы түгел. Әгәр дә кеше эшләргә теләп тә эш таба алмаса? Закон тарафыннан аны эшсезлектән саклау чаралары каралган.

Һәр гражданның *ял итүгә һәм эштән буш вакытка* хокукы бар. Дәүләт бу хокукны барлык эшләүчеләргә дә ял (отпуск)

биру юлы белән тәэмин итә, пансионнар, ял йортлары төзүне яклый. *Балалар* һәм *аналар* дәүләт сагы астында тора. Бала туганнан соң, эти-әниләренә (берсенә) ял бирелә, акчалата компенсацияләр түләнә. Гражданнар *сәламәтлекләрен саклауга һәм медицина ярдәменә хокуклы*. Хәзер Россиядә иминият медицинасы эшли. Гражданнарны дәвалау өчен иминият компанияләре түли. Әгәр граждан, олы яшькә җитеп яки гарипләнеп, хезмәткә сәләтен югалтса — *социаль тәэмин итүгә хокукы* ярдәмгә килә. Дәүләт андый кешеләргә матди ярдәм күрсәтергә тырыша.

Белем алуга хокук гражданнарның иң мөһим хокукы санала. Бала төрле формаларда белем алырга мөмкин: экстернат, үзлегеннән уку, мәктәптә белем алу һ.б. Конкурс шартларында бушлай вузга кереп уку мөмкинлеге бирелә.

Дәүләт **Конституциясе** гражданнарның төп **бурычларын** да билгели:

1. *Граждан дәүләт законнарын үтәргә тиеш*. Конкрет ситуациядә нәкъ шулай эшләргә кирәклекне күрсәтүче юридик кагыйдә бар икән, аңа буйсыну зарур.

2. *Граждан салымнар, җыемнар түләргә тиеш*. Бу акчалар дәүләт бюджетына керә, ә аннан соң гражданнар өчен бүлеп бирелә.

3. *Граждан Ватанын сакларга тиеш*. Бу бурычтан нигезсез читләшү җәзага тартыла.

4. *Граждан табигатьне сакларга тиеш*. Бу бурычы аның сәламәтлек саклау хокукы белән бәйләнгән. Кеше тарафыннан харап ителгән табигать аның организмына начар йогынты ясый.

5. *Граждан балалары һәм хезмәткә яраксыз ата-аналары турында кайгыртырга тиеш*. Гаилә хокукы нормалары мондый мәсьәләләрне җентекләп җайга сала.

6. *Граждан мәдәният һәйкәлләрен сакларга тиеш*.

Әгәр кешегә өстәмә бурычлар йөкләнә икән, бу инде аның хокукларын бозу була.

Кызганычка каршы, тормышта безнең хокуклар бозылган очраклар сирәк хәл түгел. Мәсәлән, почтада хатны ачканнар һәм, язышу сере сакланырга тиеш булуга карамастан, аны укыганнар. Яки башка төрле мисал. Шәхси эшмәкәр буларак теркәлергә теләп киләсең, ә җирле үзидарә органында бернинди аңлатма биреп тормыйча, кире борып җибәрәләр.

Гражданның хокуклары һәм ирекләре бозылган очракта нәрсә эшләргә соң? Югары органга яки судка шикаять тапшырырга мөмкин. Анда нәрсә булганын һәм нинди хокуклар бозылганын хәбәр итәргә кирәк. Граждан прокуратурага яки Конституцион судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин, бу суд граждан хокукларын бозган законны юкка чыгара.

Әгәр берниңди чаралар да ярдәм итмәсә, хокук саклау оешмаларына, мәсәлән, БМОның Кеше хокуклары комитетына мөрәҗәгать итәргә мөмкин, ул Женевада урнашкан. Шулай ук бозылган хокукны яклау үтенече белән петиция язып, Страсбургта урнашкан Кеше хокуклары буенча Европа судына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Ил Конституциясе гаранты булып президент тора. Ул дәүләт институтларына ышанмаучыларга Конституциянең зарурлыгын расларга һәм аны дәүләт тормышының аерылгысыз өлешенә әверелдерергә, аның нигезендә үзәктәге һәм урыннардагы законлы хакимият органнарының абруен тәэмин итәргә тиеш.

Төшенчәләр: *конституция, кешенең хокукый статусы, гражданлык, конституцион бурычлар.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Ил Конституциясе нәрсә ул? Башка законнар арасында ул нинди урын алып тора?

2. Сез шәхси, сәяси, икътисади, социаль, мәдәни хокукларыгызны чынга ашыра алырлык тормыш хәлләренә мисаллар китерегез.

3. Россия гражданнарының, аерым алганда, сезнең нинди бурычларыгыз бар?

4. Дәүләтнең үз гражданнарына карата нинди бурычлары бар?

*5. РФ Конституциясе үзенчәлекләре турында хәбәр әзерләгез.

*6. Дәүләттә бурычлардан башка хокуклар, яки хокуклардан башка бурычлар яши аламы?

*7. Конституциядә теркәлгән барлык хокуклар да үтәләме? Чынбарлык тормышта хокуклар үтәлсен өчен нинди шартлар кирәк? Булдыра алсагыз, кеше хокуклары бозылуга мисаллар китерегез.

? **Проблема.** Яшүсмер Россия гражданының барлык хокукларын да тормышка ашыра аламы?

Практикум. Таблицаны тутырыгыз.

Төп Конституцон хокуклар	Хокукларны тормышка ашыру үрнәкләре

§ 12 (§ 36). Хокук һәм милек мөнәсәбәтләре

Икътисадтагы барлык мөнәсәбәтләр дә хокукый нигезгә ия булырга һәм законга яраштырылырга тиеш. Юридик нормалар кулланылучы иң киң таралган өлкәләрнең берсе булып ***милек мөнәсәбәтләре*** өлкәсе тора.

Без товарлар сатып алабыз, бер-беребезгә саклау өчен әйберләребезне биреп торабыз, үзебезнеке булмаса да, ниндидер милектән файдаланабыз. Закон мондый очракларда үз-үзеңне тотуның аерым кагыйдәләрен кертә. Аны бозучы җаваплылыкка тартыла.

Милеккә мөнәсәбәт буенча без ике категориягә бүленәбез: милек хуҗалары һәм милек хуҗалары булмаучылар. Беренче категорияне закон *милекчеләр* дип атый.

> **МИЛЕКЧЕ** — ниндидер милеккә хуҗа булу хокукына ия кеше. Милек хуҗасы булу хокукы өч вәкаләтне берләштерә — ия булу, файдалану һәм шул милек белән эш итү.

Милекче милеккә ия була, аннан файдалана һәм аның белән үзе теләгәнчә эш итә. Закон шулай куша. Ә милеккә хокук буенча бу милеккә ия булмаган кеше, милек хуҗасы теләмәсә, милек белән эш итә алмый.

Дәүләт ни өчен милек мөнәсәбәтләрен җайга салу белән шөгыльләнә? Шундый хәлне күз алдына китерик. Сез машина йөртүче белән үзегезнең яңа фатирыгызга җиһазларны илтү турында килештегез, ди. Шофер әйберләрне төйи, ә фатирга



кадәр барып җитми, үз дустына сата. Алданучыларны кем яклар соң? Беркем дә түгел. Закон юк бит. «Рәнҗетүчеләр» җаваплылыкка тартылмаячак, чөнки милек мөнәсәбәтләрен җайга салучы кагыйдәләр эшләнмәгән. Сез кешеләрнең үз-үзләрен ничек тотачаклары билгеле булмаган илдә яшәргә теләр идегезме?

Безнең илдә хокукый хәлләрдә катнашучыларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен хокукый гражданлык нормалары билгеләде. Беренчедән, хокукый гражданлык мөнәсәбәтләрендә катнашучылар, кем булуларына карамастан, үзара тигез. Аларның берсе дә икенчесеннән өстен түгел. Һәрберсе билгеләнгән кагыйдәләр кушканча эшләргә тиеш. Сез, ике сумкагызны саклау камерасына тапшырып, күрсәтелгән хезмәт өчен түлисез һәм, өч көн узгач, үз әйберләрегезне тулысынча һәм зыян китерелмәгән килеш алырмын дип ышанасыз. Бу кеше һәм оешма арасында туган милек мөнәсәбәтләренә мисал булып тора. Юридик яктан караганда, кеше — физик зат, аның исеме, яшәү урыны, хокукый һәм эшкә сәләте бар. Оешма — юридик зат, аның үз милке бар, ул үз бурычлары буенча җавап бирә.

Милеккә хуҗа булу хокукы төрлечә барлыкка килә. Мәсәлән, дачаны үзең төзергә һәм шунда ук аның хуҗасына әверелергә мөмкин. Яки аны таныш кешеләрдән сатып алырга һәм, сату-алу турындагы килешүгә таянып, дачага милек хокукына ия булырга мөмкин. Дәүләт милкен (мәсәлән, фатирны) хосусилаштырып (приватизацияләп) була, бу очракта сез милек хуҗасына әвереләсез. Милексез калу тагын да җиңелрәк: аны сатып, бүләк итеп, югалтып була, ул янгында юкка чыгарга мөмкин. Милекне шулай ук суд карары буенча конфискацияли алалар. Мондый очракларның барысында да милеккә хокук *юкка чыга*.

Гражданлык хокукы субъектлары

→ **физик затлар** — кешеләр — исем — яшәү урыны — хокукый сәләте — эшләү сәләте

→ **юридик затлар** — оешмалар — аерымланган милек — аталыш, адрес, банктагы хисап — структура — судта дәгъвачы, җавап тотучы булырга мөмкин

Хокукый гражданлык мөнәсәбәтләренең күпчелеге ***килешүләр*** (сделка) нәтиҗәсендә туа. Мөгаен, сез танышларыгызның: «Мин килешүдә катнаштым яки кем беләндер килешү беркеттем (заключил сделку)»,— дигән сүзләрен ишеткәнегез бардыр. Нәрсә соң ул килешү?

КИЛЕШҮ (сделка) — аерым затларның гражданлык хокук һәм бурычларын урнаштыруга, үзгәртүгә яки юкка чыгаруга юнәлдерелгән гамәлләре.

РФнең Гражданлык кодексында шулай язылган. Мәсәлән, әбисе оныгына васыять яза. Бу — килешү. Абыйсы автомобиль йөртүгә ышанычнамә (доверенность) бирә. Бу да килешү. Бер кешенең «килешүе» нәтиҗәсендә гражданлык хокуклары һәм бурычлары барлыкка килә.

Берничә зат катнашкан килешү шартнамә дип атала. Бу — кешеләр, оешмалар, дәүләтләр арасындагы килешү була. Шартнамә төзелгәч, аның бөтен шартларын үтәү мәҗбүри. Аны *икенче якның ризалыгыннан башка үзгәртергә* яки *өзәргә мөмкин* түгел. Җитди бәхәсләр килеп чыккан очракта, эш суд тәртибендә хәл ителә. Шартнамәне бозу очрагы өчен алдан ук ике якның да җаваплылыгы билгеләп куела. Гаепле як китерелгән *зыянны капларга*, штраф түләргә тиеш. Законда шундый кагыйдә теркәлгән: әгәр дә гаепле як шартнамәне үтәмәве белән авыр кичерешләргә дә этәргән, газаплар китергән булса, ул китергән *мораль зыян* өчен дә түләнергә тиеш. Теге яки бу килешүдә катнашканда, үз-үзеңне тотуның билгеле бер кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Әгәр мондый кагыйдәләр үтәлмәсә, килешү гамәлдән чыккан дип исәпләнәчәк. Бу аның бетүен, якларның бер-берсе алдында берниндн дә бурычлары да, хокуклары да булмавын белдерә. Бу мөһим кагыйдәләр законда күрсәтелгән.

Милек мөнәсәбәтләрендә кеше мөстәкыйль рәвештә катнаша ала. Авырып киту, командировкага китү яки нәрсә дә булса эшләүдән бөтенләй баш тарту кебек алдан уйланмаган төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Мондый очракта закон үз хокукларыңны вәкилеңә тапшыруны рөхсәт итә. Даими рәвештә эшмәкәрләр исеменнән эш алып баручы коммерция вәкиле була. Ул бу эшләр өчен түләү ала. Кемдер исеменнән эш алып бару өчен күпчелек очракларда махсус документ — ышанычнамә (доверенность) төзү зарур. Бары тик әти-әниләр генә үз балалары исеменнән эшләрне ышанычнамәсез алып бара алалар.

Хокук теләсә нинди вкилешүләрне рөхсәт итә — моны белү зарур. Хәтта ки законда билгеләнмәгәннәрен дә. Әмма бу килешүләр законга каршы килмәскә тиеш. Килешүдә катнашкан яклар барлык очракларда да ышанычнамә нигезендә эш итәргә тиешләр.

Законда нинди шартнамәләр каралган соң? Аларның РФ ГКнда күрсәтелгән кайбер төрләрен әйтеп үтик. Мәсәлән, *сату* һәм *алу*. Бу шартнамәдә сатучы һәм сатып алучы катнаша. Сатучы сатып алучыга әйберне тапшырырга, ә тегесе моның өчен түләргә тиеш. *Алыштыру* шартнамәсе буенча яклар товарларын алмашалар. Берсе нәрсәнедер икенчесенә бирә, икенчесе ул әйбергә алмашка үзенекен аңа тапшыра. Шулай ук *бүләк итү* шартнамәсе дә бар. Бу очракта бер як икенчесенә

бушлай ниндидер бер әйберне тапшыра. *Рента* шартнамәсе дә була. Монда бер як икенче якка үз мөлкәтен милек итеп тапшыра. Моның өчен икенче як аңа периодик төстә акча түли. *Прокат* шартнамәсе буенча бер як икенчесенә күчемле милкен вакытлыча файдалануга бирен тора, моның өчен билгеле күләмдә түләү ала. *Подряд* шартнамәсе нигезендә бер як икенче як кушкан эшне (заказны) башкара, эш нәтиҗәсе өчен түләү ала.



Эшлекле кешеләр, фирмалар арасындагы мөнәсәбәтләрдә намуслылык, җаваплылык, ышанычлылык мөһим роль уйный. Әгәр дә эшмәкәр яки оешма клиентларын, партнерларын алдый икән, алар белән беркем дә эш итәргә теләмәячәк. Хокукый нормаларны бозмасалар да, алар уңышсызлыкка очрыйлар. Кайвакытларда парикмахер чәчне начар кисә, кибеттә сатучылар сатып алучылар белән тупас сөйләшә, поставщиклар товарны вакытында китерәләр, әмма сүзләрендә тормыйлар. Базар мөнәсәбәтләре эшмәкәрләрдән яхшы исем-дәрәҗәгә ирешүне, профессиональ белемлелекне, закон буенча эшләүне таләп итә.

Милек мөнәсәбәтләренә кагылышлы барлык конфликтлар, әгәр дә яклар бәхәсне үзләре генә хәл итә алмаса, судта хәл ителә. Кемдер законсыз рәвештә милек алган икән, аңа ***дәгъва*** белдерелергә мөмкин. Дәгъвада милек хуҗасы үз милкен кире кайтаруны таләп итә.

ДӘГЪВА (иск) — затның (кешенең яки оешманың) бозылган хокукларын суд тәртибендә яклауны таләп итү.

Кайбер очракларда милеккә мөнәсәбәт милекне алмыйча да бозылырга мөмкин. Мәсәлән, күршеләрнең дачада яңа биналар төзүе аркасында, кеше үз йортына үтеп керә алмый

башлый. Бу хәл өчен җаваплы күршегезгә дәгъва языгыз. Әгәр кешеләр арасында милек мөнәсәбәтләре буенча бәхәсләр туа икән, җавап тотучының яшәгән урыны буенча район (шәһәр) судына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Фирмалар арасындагы икътисади бәхәсләр арбитраж судында карала.

Төшенчәләр: *милек мөнәсәбәтләре, милеккә хокук, килешү, шартнамә, дәгъва.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Гражданлык хокукы нәрсәне җайга сала? Кем милек мөнәсәбәтләрендә катнашучыга әверелергә мөмкин?
2. Шартнамә төзегәндә, нәрсәне белү зарур?
3. Шартнамәләрнең нинди төрләрен беләсез? Сез дустыгыз белән аның кичке сәгать 8 дә шалтыратачагы турында килештегез ди. Мондый килешү юридик юнәлеш алырга мөмкинме?

* 4. Түбәндәге хәлләр гражданлык хокукы нормалары белән җайга салынамы?

— Олег үз дустыннан бурычка акча алып тора;
— Татьяна кибеттән тун сатып ала;
— Виктор «N» фирмасы директоры белән шартнамә төзи, аның буенча ул атнага 4 көн автослесарь булып эшләячәк.

*5. Хәзерге Россиядә гражданнарның милеккә булган хокукларындагы үзгәрешләргә анализ ясагыз.

Проблема. Сез ничек уйлыйсыз, милеккә хокук кешенең башка хокуклары үтәлүе өчен нигез була аламы?

Практикум. Милек мөнәсәбәтләре суд хакимиятләре катнашуын таләп итә торган берничә ситуация уйлап чыгарыгыз (модельләштерегез).

§ 13 (§ 37). Кулланучы һәм аның хокуклары

Закон җитештерү сферасын гына түгел, куллану өлкәсен дә җайга сала. Кулланучылар буларак, без еш кына товарларга заказ бирәбез, сатып алабыз, ателье, кунакханә, кер юу һәм ремонт мастерскойлары хезмәтеннән файдаланабыз һәм югары сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә өмет итәбез. Табыш алу өчен түгел, ә шәхси куллану өчен товарга, эшкә, хезмәткә заказ бирүче яки алучы һәм аннан файдаланучы һәр кеше юридик яктан

кулланучы дип исәпләнә. Ә кулланучы заказларын үтәүчеләр *башкаручылар* дип атала. Башкаручы гамәлләре дә хокукый нормалар белән җайга салына.

КУЛЛАНУЧЫ — табыш өчен түгел, ә шәхси (көнкүреш) ихтыяҗлары өчен товарга, эшкә һәм хезмәтләргә заказ бирергә яки алырга теләүче граждан.

БАШКАРУЧЫ — кулланучыларга түләүле шартларда хезмәт күрсәтүче яки эш башкаручы оешма (нинди милек формасына ия булуына бәйсез рәвештә) һәм шулай ук шәхси эшмәкәр.

Кулланучының төп хокукларын карап үтик. Алар Гражданлык кодексында, кулланучыларның хокукларын саклау турындагы Законда, Реклама турындагы Законда, Шәһәрара һәм халыкара телефон элемтәсе хезмәтен тәкъдим итү кагыйдәләрендә, РФда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү кагыйдәләрендә, Җәмәгать туклануы продукциясен (хезмәтләрен) җитештерү һәм тәкъдим итү кагыйдәләрендә һ.б. закон актларында теркәлгән.

Закон тарафыннан барлык товарларның, эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең *стандартка һәм санитар нормаларга туры килүе* шарты куела. Белгечләр тарафыннан күрсәтелгән бу нормалар кайсы товарның сыйфатлы булуын, кайсы хезмәт күрсәтүнең ышанычлы икәнен төшенергә ярдәм итәләр. Кулланучының үзе алган товарның сыйфаты турында *җентекле мәгълүмат алу хокукы* бар. Белешмәләр рус телендә бирелә. Махсус этикеткаларда җитештерүченең атамасы һәм урыны күрсәтелгән *маркасы булырга тиеш*. Мәсәлән, уенчык аюга аның Мәскәү шәһәрендә, Залесная урамында, 1 нче йортта эшләнүен белдергән марка беркетелгән.

Кибетләрдә сезгә сатучылар хезмәт күрсәтә, һәм сезнең товар алган кибет исемен, аның юридик адресын һәм эш режимын белү *хокукыгыз бар*.

Кулланучы *куркынычсыз һәм сыйфатлы* товар, хезмәт, башкарылган эш нәтиҗәсен алырга хокуклы. Әгәр яңа алынган чәйнек токка тоташтырганда, ялкынланып китеп, кулны пешерсә, аның хуҗасы *зыян күрүче* була. Бу чәйнекне сатучы яки эшләүче (сатып алучы кайсын күрсәтсә — шунысы) ул күргән зыянны кире кайтарырга тиеш. Бу чәйнек сатып алынганмы, әллә аңа бүләк иткәннәрме, анысы мөһим түгел.

Сез бик озаклап кыйммәтле товар, мәсәлән, телевизор сайладыгыз, ди. Әмма кибеттә аның ничек эшләвен әллә ни тикшереп тормадыгыз, өегезгә алып киттегез һәм җитди җитешсезлекләр таптыгыз. Нәрсә эшләргә соң? Кулланучыга закон мондый очракларда да ярдәм итә. Ул аңа тәкъдим ителгән хокук нормаларыннан үзенә кулай вариантны үзе сайлап алу мөмкинлеге бирә.

1. Кулланучы җитешсезлекләрне бетерүне таләп итә ала (җитешсезлекләр 20 көн эчендә бетерелергә тиеш). Әгәр дә товар озак файдалану өчен алынган булса (мәсәлән, суыткыч) аны эшләүче яки сатучы ремонтлаган вакытка башка суыткычны биреп тора һәм аны кешегә үз хисабына китерә.

2. Әгәр бу әйбер кулланучыга шушы хәлендә дә кирәк булса, ул сатучы белән аның бәясен киметү турында килешә ала (закон бу мәсьәләне шундый юл белән хәл итүгә 10 көн вакыт бирә).

3. Шундый ук, әмма сыйфатлы товарга алыштыруны таләп итә (7 көн эчендә).

4. Башка төрле товарга алыштыруны таләп итәргә мөмкин. Әгәр ул товар кыйммәтрәк торса, өстәп түләргә; арзанрак булса, калган аерма акчасын кире алырга мөмкин.

5. Әгәр алынган әйберне кире бирәсе килсә, кулланучы аны билгеле бер вакыт эчендә кибеткә кайтара һәм акчасын кире ала.

Яки сез әйбер сатып алдыгыз, аның сыйфатын тикшердегез, акча түләдегез, өйгә алып кайттыгыз һәм аның төсе яки размерлары сезнең фатирга туры килмәвен күрдегез. Бу очракта нәрсә эшләргә соң, әйбернең сыйфаты яхшы бит. Закон тагын кулланучыны яклый. Сыйфатлы товарны да 14 көн эчендә алыштырырга яки, акчасын алып, кире кайтарырга мөмкин.

Кулланучыларның бу хокукы товар бозылмаган һәм аңа чек булган очракта гына саклана. Кулланучыга төрле хезмәтләр күрсәтелә: фатирын, автомобилен, көнкүреш техникасын ремонтлау һ.б. Эшне башкаруның сметасы — чыгымнар турындагы хисап төзелә. Хезмәт күрсәтүнең яки эш башкаруның шартлары төрле булырга мөмкин, әмма алар хокук тарафыннан тәртипкә салына.

Әгәр закон кулланучылар хокукын билгели икән, димәк, дәүләт аларны якларга тиеш. Безнең илдә дәүләт органы — Монополиягә каршы федераль комитет бар. Ул кулланучылар

хокукларының үтәлешен контрольдә тота. Бу эштә җирле үзидарә органнары ярдәм күрсәтә. Товарларга экспертиза үткәрүче, судта гади гражданнарны яклаучы союзлар, ассоциацияләр — иҗтимагый оешмалар төзелә.

Кулланучыларның хокуклары бозылганда, сатучылар, товарны әзерләүчеләр, хезмәт күрсәтүчеләр милек өчен җаваплылыкка тартылалар. Кулланучыларга неустойка (штраф) түләнә, милеккә китерелгән һәм мораль зыян өчен дә түләнә.

Җитештерүче җитештерелгән әйбернең файдалану (эшләү) срогын билгеләргә хокуклы. Шушы вакыт дәвамында ул товарның сыйфаты өчен җавап бирә. Кайбер товарларга *яраклылык вакыты* билгеләнә. Мәсәлән, эремчек ризык буларак бары тик 5 көн генә кулланылырга мөмкин. Аннан соң ул бозыла, кеше аны ашап агуланырга мөмкин. Яраклылык вакыты дәвамында җитештерүче товарның сыйфаты өчен җавап бирә. *Әгәр яраклылык вакыты чыкса, бу товарны сату тыела.* Җитештерүче тагын бер вакытны — ***гарантия вакытын*** билгели. Бу вакыт эчендә барлык ремонт эшләре бушлай башкарыла.

Үз хокукларыңны ничек якларга соң? Беренче чиратта, теге яки бу товарны сайлаганда, билгеле бер хезмәт күрсәтүгә мөрәҗәгать иткәндә, бик игътибарлы булу зарур. Үзегез мөрәҗәгать иткән оешманың кулланучылар базарында яхшы абруе булуына, аның законнарны бозмавына инаныгыз. Алай булганда, кулланучылар хокукы суд белән яклана. Сез бозылган хокукны яклау турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итә аласыз, һәм суд килеп туган конфликтны юридик күзлектән чыгып хәл итәчәк. Закон кулланучыны дәүләт пошлинасы түләүдән азат итә.

Төшенчәләр: *кулланучы, башкаручы, әзерләүче.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Кулланучы юридик мәгънәдә кем ул? Аның хокуклары нинди законнар белән тәртипкә салына?

2. Берсенә икенчесе диван сатучы ике күрше арасындагы мөнәсәбәтләргә кулланучыларга кагылышлы законнар таралмый. Мондый мөнәсәбәтләр хокук тарафыннан җайга салынамы?

3. Кулланучының төп хокукларын санап чыгыгыз. Алар законнарда җитәрлек дәрәҗәдә беркетелгәнме?

*4. Кулланучы хокуклары чынбарлыкта үтәлсен өчен, сезнең карашка, нәрсә эшләргә кирәк?
* 5. Кулланучылар хокукын саклау турында закон булу дәүләтне нинди яктан сыйфатлый?

Проблема. Кулланучы буларак, үз хокукларыңны ничек якларга мөмкин?

Практикум. Параграф материалларына нигезләнеп, түбәндәге фикерләрне төгәлләгез:

Бөтен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр ... ... булырга тиеш.
Товар сатып алганда, кулланучы ... ... хокуклы.
Сыйфатсыз товар алган очракта ... ... мөмкин.
Дәүләт кулланучыга ... ... ярдәм итә.

§ 14 (§ 38). Хезмәт һәм хокук

Кешеләр һәрвакыт хезмәт белән шөгыльләнгәннәр, әмма хезмәткә мөнәсәбәт бертөрле генә булмаган. Борынгы ыруглык дәверендә кеше шуны төгәл белгән: мамонт ауларга бармыйсың икән — ач калырсың һәм үләрсең.

Гасырлар уза. Кешеләр арасында ярлылар һәм байлар аерыла. Байларга исә туклану өчен эшләү мәҗбүри булмый. Алар өчен башкалар эшли.

Закон кеше эшчәнлегенә дә үтеп керә. Ул кешеләрнең акча эшләү кагыйдәләрен билгели. Кеше тормышының хезмәт сферасында эшләүче кагыйдәләр җыелмасы **хезмәт хокукын** хасил итә.

Әмма һәр хезмәт тә хокук тарафыннан тәртипкә салынмый, һәм һәр хезмәт тә табыш китерми. Мәсәлән, сез үз магнитофоныгызны ремонтлыйсыз яки кер юасыз, ди. Бу эш үзең өчен генә башкарыла, һәм хокук тарафыннан тәртипкә салынмый.

Хезмәт хокукы эш бирүче һәм хезмәткәр арасында хезмәт процессында туган мөнәсәбәтләрне җайга сала. Мондый кагыйдәләр хезмәт процессын көйли, анда катнашучыларның үз-үзләрен тотышы нинди булырга тиешлекне билгели. Хезмәт хокукы нормалары РФнең Хезмәт турындагы законнар кодексында, шулай ук аерым законнарда беркетелгән. Аларны белү кемдер тарафыннан алданмас өчен үзеңне конкрет ситуацияләрдә тиешенчә тотарга булыша, законны белмәү ар-

касында, дөрес булмаган гамәлләр кылып, җаваплылыкка тартылудан саклап кала.

Мәсәлән, сез *эш эзлисез* дип күз алдына китерик. Дусларыгыз киңәше буенча фирмага урнашырга уйлыйсыз. Фирма җитәкчесе белән очрашуга барганда, *паспорт* һәм *хезмәт кенәгәсен* алырга кирәк (әгәр дә алар булса). Шуны белегез: һәр кеше хезмәт эшчәнлеген 15 яшьтән башларга мөмкин. Бу яшькә җиткәнче дә закон мәктәп укучыларына укудан буш вакытта эшләүне тыймый. Кайбер эшләрне башкару өчен *квалификацияле* булу таләп ителә. Әйтик, буш урын булуына һәм аның ошавына карамастан, һәр кеше дә поликлиникада теш врачы булып эшли алмый, монда махсус белем һәм *диплом* таләп ителә. Кайбер очракларда сәламәтлек турында *медицина белешмәсе* (справкасы) кирәк. Эшкә урнашканда, 21 яше тулмаган һәр кеше медицина тикшерүе үтәргә тиеш, һәм бу таләп кайбер белгечләргә, мәсәлән, пешекчеләргә дә кагыла. *Закон тарафыннан каралмаган документларны таләп итү тыела.* Әгәр оешма җитәкчесе милициядән характеристика яки гаилә керемнәре турында белешмә сораса, аның бу гамәле законсыз була.

Хезмәткәр һәм эш бирүче арасында **хезмәт шартнамәсе**, яки ***контракт*** төзелә. Ул язма формада була. Килешү буенча хезмәткәр эчке хезмәт тәртибенә буйсынырга, ә эш бирүче хезмәт хакы түләргә һәм нормаль эш шартлары тудырырга тиеш. Хезмәт шартнамәсе билгесез вакытка, 5 елга кадәр яки билгеле бер эшне башкарып чыкканга кадәр төзелә. Әгәр дә сез хезмәт мөнәсәбәтләренең 1 ел гына дәвам итәчәге белән килешсәгез, *вакытлы хезмәт шартнамәсе* төзегез. Хокук хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый һәм оешма җитәкчеләренә мондый шартнамәләрне аерым очракларда гына төзергә рөхсәт итә: башка хезмәткәрне алыштырырга, конкрет эш эшләргә кирәк булганда яки хезмәткәр моны үзе сораганда. Закон хезмәткәрләр өчен *сынау вакыты* (3 айга кадәр) билгеләүне рөхсәт итә. Бу вакыт эчендә кешенең тәкъдим ителгән эшне башкару сәләте тикшерелә. Мондый вакыт 18 яшьтән кечерәк затлар, яшь белгечләр, ПТУ яки вуз бетереп килгәннәр өчен билгеләнми.

Хезмәт Россиядә *ирекле*, һәм шуңа күрә сез теләсә кайсы вакытта элекке эш урыныгызны калдыра аласыз. Илебез гражданнарына мондый хокук һәрвакытта да бирелмәгән. 30 нчы

елларда предприятиеләрдән киту җинаятькә тиңләнгән. Гасыр уртасында бер эштән икенче эшкә күчеп йөрүчеләрне дә өнәмәгәннәр.

Хәзерге законнар буенча ***хезмәт — бурыч түгел,*** бәлки ***һәр кешенең хокукы.*** Хезмәткәр администрация белән төзелгән хезмәт контрактын, ике атна алдан гариза язып, үз теләге белән *өзә ала.* Әгәр администрация каршы килмәсә, гаризаны язуга ук эштән җибәрергә мөмкиннәр. Мәсәлән, хезмәткәр институтка укырга кереп, анда дәресләр башланган очракта шулай эшләргә тиешләр. Әгәр дә шартнамә вакытлы булса (мәсәлән, 1 елга төзелсә һәм 1 айдан китәргә кирәк булса), администрация рөхсәте белән генә китәргә мөмкин. Әмма администрация риза булмаса, закон мондый очракны түбәндәгечә аңлата: хезмәткәр үзенә йөкләмә алган һәм шуңа күрә шартнамә буенча эш итәргә тиеш. Бары тик *нигезле сәбәпләр* генә шартнамәне өзәргә мөмкинлек бирә (авыру, инвалид булу).

Администрация теләге белән генә эштән җибәреп булмый. Закон хезмәткәр ризалыгыннан башка да контракт өзелү очраклары булуын искәртә. Хезмәткәрләрне предприятиедә *штатны* яки эшләүчеләр санын *кыскартканда* эштән җибәрергә мөмкин. Директор *эшкә начар караучы хезмәткәрне* дә *эштән азат итә ала.* Моңа аның эчкечелеге, үз йөкләмәләрен үтәмәве,

шулай ук дүрт айдан да күбрәк авыруы сәбәп булырга мөмкин. Соңгы очракта бик күп проблемалар килеп чыга. Хезмәткәр авырый. Эш туктала. Башка белгечне чакыру зарурлыгы туа. Эштән җибәрү — бу бары тик администрациянең хокукы гына, ә бурычы түгел.

18 яшькә җитмәгән яшүсмерләрне бары тик балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия яки дәүләт хезмәт инспекциясе ризалыгы белән генә эштән җибәрергә мөмкин.

Хезмәт хокукы нормалары эш вакыты озынлыгын билгели һәм эшләүчеләргә ял да бирә. Бер очракта сез эш көне озынлыгын үзегез билгелисез (мәсәлән, балагызны карарга чакырган кешегезнең эш көне озынлыгын). Башка очракта эш режимын предприятие билгели: 9 сәгатьтән 18 сәгатькә яки 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр. Закон монда да хезмәткәр мәнфәгатьләрен кайгырта. Эш вакыты дәвамлылыгы атнасына 40 сәгатьтән дә артмаска тиеш, ә 18 яшькә җитмәүчеләр өчен ул кыскартыла да. Мәсәлән, 16 яшьтән 18 яшькә кадәрге яшүсмерләр өчен ул атнасына 36 сәгатьтән, ә 14 яшьтән 16 яшькә кадәргеләргә 24 сәгатьтән артмаска тиеш.

Закон кешеләрне тиешле вакыттан артыграк вакытка эшкә тартуны тыя. Бу бик сирәк очракларда гына мөмкин. *Яшүсмерләргә төнлә эшләү* (кичке сәгать 10 нан иртәнге 6 га кадәр), шулай ук *авыр эшләрдә*, мәсәлән, *йөк бушатуда катнашу тыела*. Закон төнге клубларда, уен оешмаларында яки спиртлы эчемлекләр сатуда *балалар хезмәтеннән* файдалануны тыя.

Күп кенә кешеләр бер үк вакытта укыйлар да, эшлиләр дә. Хезмәт хокукы администрациядән аларга кыска хезмәт атнасы бирүне һәм экзаменнар бирү өчен буш вакыт калдыруны (учебные отпуска) таләп итә. Барлык хезмәткәрләргә дә һәр ел саен *ял (отпуск) алу* ***хокукы*** бирелә, ул 24 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

Һәр кешенең язмышында көтелмәгән хәлләр килеп чыгарга мөмкин, эш югалту — аеруча авыр хәл.

Хокук эшсез калучыларга ярдәм күрсәтә.

Теләсә кайсы газетаны, мәсәлән, «Мир вакансий»ны ачып карагыз һәм күпме кешеләрнең эш эзләвен, никадәрле фирмаларга, компанияләргә хезмәткәрләр кирәк булуын күрерсез. Эш эзләүчеләргә һәм эш бирүчеләргә бер-берсен табарга ярдәм итү өчен мәшгульлек үзәкләре, шулай ук Федераль дәүләт мәшгульлек хезмәте булдырылган. Моның өчен паспорт, хезмәт

кенәгәсе, соңгы өч айлык хезмәт хакы турында белешмә, ә беренче тапкыр эш эзләүчеләргә белем турында документ алып килү кирәк. Эшсезләргә пособие түләнә, башка профессия алу мөмкинлеге бирелә. Эшкә урнашу өчен башка яшәү урынына күчкәндә хәтта юл чыгымнары да кире кайтарыла.

Шулай итеп, Россиянең һәр гражданы хезмәткә хокуклы. Бу сезнең ирекле рәвештә һөнәр һәм эш урынын сайларга хокуклы булуыгызны белдерә. Хезмәт хокукый мөнәсәбәтләрендә барлык кешеләр дә бертигез: хезмәткәр дә, хезмәт бирүче дә. Закон аларның эш-гамәлләрен җайга сала һәм хезмәткәрләр хокукын яклый. Әгәр граждан үз хокуклары бозылган дип исәпли икән, ул аларны яклау өчен судка мөрәҗәгать итә ала.

Төшенчәләр: *хезмәт хокукы, балалар хезмәте.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Хезмәт хокукына хас үзенчәлекле сыйфатларны билгеләгез.
2. Хезмәт шартнамәсе нәрсә ул? Бер-берең белән үзара килешүдән ул нәрсә белән аерыла?

*3. Сезнең дустыгызга 18 яшь тулган, ул исә күңеленә ошаган эшне таба алмый. Аңа мондый очракта нишләргә икәнен аңлатыгыз, киңәш бирегез.

*4. Сез берничә елдан үзегезне багышлаячак һөнәрне инде сайладыгызмы? Уйлагыз, ул кирәк булырмы, бу һөнәрдә үз сәләтләрегезне гамәлгә ашыра алырсызмы?

*5. Аңлатыгыз, бүгенге Россия гражданына эшләмәү мөмкинме? Эшләмәү аның башка хокуклары үтәлешенә йогынты ясыймы?

Проблема. РФнең хезмәт турындагы законнары эшкә карата хәзерге яшьләр куйган таләпләрне канәгатьләндерә аламы?

Практикум. Барлык тиешле шартларны күрсәтеп, үз исемегездән хезмәт шартнамәсе төзегез.

§ 15 (§ 39). Хокук, гаилә, бала

Ир белән хатын, бала һәм ата-аналар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр РФ Гаилә кодексында теркәлгән гаилә хокукы нормалары белән җайга салына. Анда өйләнешү, аерылышу кагыйдәләре, гаилә әгъзаларының шәхси һәм милеккә кагылышлы хокуклары һәм бурычлары теркәлгән. Әмма гаилә хокукы барлык мөнәсәбәтләрне дә колачламый. Мәсәлән, Россия закон-

нарында «гаилә башлыгы» дигән төшенчә юк, акчаны кем күбрәк эшләргә бурычлы, һәм ул ничек тотылырга тиеш, анысы да билгеләнмәгән. Өйләнешүчеләр кайда яшәргә тиеш, анысы турында да бер сүз дә юк. Шулай да гамәлдәге хокук ата-аналар һәм балалар, ир белән хатын арасындагы төп мөнәсәбәтләрне иңли. Ул беренче чиратта гаилә иминлеге һәм ныклыгы сагында тора, аның иң йомшак буынын — баланы яклаучы тулы бер чаралар комплексын билгели.

Гаилә төзү — кеше тормышында бик җаваплы адым, кеше яңа юридик хокукларга һәм бурычларга ия була: мәсәлән, уртак милеккә ия булу хокукы яки балалар тәрбияләү бурычы. Гаилә төзү өйләнешүдән башлана. Әгәр дә яклар башка максаттан чыгып өйләнешсәләр (мәсәлән, фатир алу, пропискага керү, мирас алу), ул фиктив өйләнешү була һәм юридик яктан яраксыз дип исәпләнә. Ике якның гаризасы буенча мондый карарны суд чыгара. Өйләнешкәннән соң яшьләргә *танык-лык* — алар арасында юридик мөнәсәбәтләр тууын раслаучы документ бирелә (гаилә һәм өйләнешү турында 8 нче сыйныф дәреслегенең 24 нче параграфыннан укыгыз).

Шулай итеп, яңа гаилә барлыкка килде. Хәзер ир һәм хатын күпчелек мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә тиеш. Алар икесе дә тигез хокуклы, парларның шәхси һәм милек хокуклары закон тарафыннан көйләнә.

Никахлы тормышта булдырылган барлык милек ир һәм хатынның уртак мөлкәте була.

Әгәр дә ир үз хезмәт хакына машина сатып алса, ә хатыны үз акчасына компьютер алып кайтса, аларның икесе дә бу әйберләргә тигез хокуклы. Хәтта хатынның керемнәре бөтенләй булмыйча, акчаны өйгә ир генә алып кайтса да, ул алган барлык мөлкәт, барыбер, уртак милек санала. Аерылышканда аны, юридик яктан төзелгән башка төрле килешү булмаган очракта, тигез өлешләргә бүләләр.

Әмма гаиләдәге бар мөлкәт тә уртак булмый. Һәр кешенең *үзенең генә куллану әйберләре* дә бар: теш щеткасы яки, мәсәлән, затлы тун. Аларның бәясе нинди булуына карамастан, бу әйберләр ир белән хатынның аерым үз әйберләре генә. Берсенең мирас буенча килгән яки бүләк ителгән, шулай ук өйләнешкәнгә кадәр булган милке дә уртак була алмый. Киләчәктә мөмкин булган конфликтлардан котылу өчен, кияү белән кәләш яки ир белән хатын *өйләнешү контракты* төзергә

мөмкиннәр. Анда уртак милеккә ия булуның, бер-берсен матди яктан тәэмин итүнең, уртак милектән файдалануның барлык шартлары искәртелә. Өйләнешү килешүендә кешенең табигый хокукларына зыян китерүче, аның кешелек намусын һәм абруен кимсетүче шартлар булырга тиеш түгел.

Төрле хәлләр аркасында гаилә таркалырга да мөмкин. Соңгы еллар мәгълүматлары буенча безнең илдә һәр өйләнешкән ике парның берсе таркала. Әгәр парларның икесе дә аерылышырга риза булса, аларның балигълык яшенә җитмәгән уртак балалары булмаса, парлы тормышны таркату алар гаризасы буенча загста башкарыла. Әгәр дә инде аларның берсе генә булса да каршы икән яки гаиләдә балигълык яшенә җитмәгән балалар бар икән, бу мәсьәлә бары тик судта гына карала ала.

Гаилә хокукы парлар арасындагы мөнәсәбәтләрне генә түгел, ә ата-аналар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне дә җайга сала. *Ата-аналар үз балаларын карарга, тәрбияләргә*, аларның сәламәтлеге, үсеше һәм белем алуы турында кайгыртырга *тиеш.* Алар балалары мәнфәгатьләрен якларга бурычлы.

Балалар да *ата-аналары турында кайгыртырга бурычлы.* Эшкә сәләтсез, ярдәмгә мохтаҗ ата-аналар, бабайлар һәм әбиләр балалары һәм оныклары карамагында яшәргә хокуклы, Россия законында әнә шулар теркәлгән. Хокукта *тормыш бүләк иткән кешеләргә ярдәм итү кебек гадел принцип чагылыш тапкан.* Әмма әгәр ата-аналар үз балаларын тәэмин итүдән һәм тәрбияләүдән баш тарткан булсалар, балалар мондый бурычтан азат ителәләр. Хокук нормаларында кешеләрнең гаилә турында күп гасырлардан килгән күзаллаулары теркәлгән. Борынгы грек философы Фалес б.э.к. VI гасырда ук: «Шуны исегездә тотыгыз, балаларыгыз белән нинди мөгамәләдә булсагыз, алар да сезнең белән шундый мөгамәләдә торачак»,— дигән.

Россиядә 40 миллионнан артык бала яши. Юридик яктан халыкның мондый категориясенә 18 яшькә кадәрге балаларны кертәләр. Безнең илдә бала шәхес, граждан булып исәпләнә, аның тулы комплекс хокуклары һәм бурычлары бар. Мондый кагыйдәләр хокукның төрле тармакларында беркетелгән (Гаилә хокукы, Җинаятькә каршы хокук, Хезмәт турындагы законнар кодексы һ.б.). 1989 елда БМО *Бала хокуклары конвенциясен* кабул итә, анда Россия дә кул куя.

Россия законнары барлык балаларның да тигез хокуклы булуын раслый. Бала өйләнешкән гаиләдә дөньяга килгәнме,

әллә киресенчә, никахсыз туганмы, бу артык мөһим түгел — аның хокуклары үзгәрми, алар алыштыргысыз. Туу белән, ул РФ гражданына әверелә. Димәк, сабый Конституциядә теркәлгән барлык хокукларга һәм ирекләргә ия була. Юристлар әйткәнчә, кеше туу белән үк хокукый сәләтле дип исәпләнә. **Хокукый сәләтлелек** — хокукларга һәм бурычларга ия булу сәләте ул. Баланың тумыштан ук милек хокукы бар, мәсәлән, әбисе бүләк иткән фатирга хокук. Баланың бөтен хокуклары юридик мәгънәгә ия һәм ата-аналар, опека, попечительлек органнары, прокурор, суд тарафыннан яклана. Бала хокукларын бозу юридик җаваплылыкка тартыла. Әмма хокукый сәләтлелектән тыш балада эш-гамәлгә сәләтлелек, ягъни үз хокукларын чикләүләрсез мөстәкыйль тормышка ашыру һәм үз бурычларын үти алу сәләте булуы да кирәк. Закон буенча, фатир үзенеке булса да, бала аны сата алмый. Мондый хокук аңа билгеле бер яшькә җиткәч кенә бирелә.

Закон 14 яшькә кадәрге балаларны кече *яшьтәгеләр* дип атый. Алар вак характердагы килешүләр башкарырга хокуклы. Мәсәлән, дәфтәр, каләм, уенчыклар сатып алырга. Әгәр дә бу яшьтәге балаларга кемдер кыйммәтле әйберләр бүләк итә икән, монда аларның әти-әниләре ризалыгы таләп ителә, чөнки кече яшьтәгеләрнең милек җаваплылыгына кагылышлы килешүләр өчен нәкъ менә алар җавап бирә. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге *балигъ булмаган балалар* үз стипендияләре яки хезмәт хаклары белән мөстәкыйль эш итә алалар. Әгәр дә кемдер нинди дә булса бер әсәр язса яки кызыклы берәр нәрсә уйлап тапса, ул олы кешеләр кебек үк моның өчен гонорар алачак. Әмма эре килешүләр өчен ата-аналар ризалыгы таләп ителә. Яшүсмерләр милек өчен үзләре җавап бирәләр. 14–18 яшьлек балаларның үз хезмәт хаклары яки үз милекләре булмаска да мөмкин, һәм алар китерелгән зыянны үзләре каплый алмаячак. Мондый очракта аларга әти-әниләре ярдәм итә. Тулы эшкә сәләтлелек 18 яшь тулгач кына башлана. Әгәр дә яшь кеше 18 яшькә кадәр үк өйләнсә һәм эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башласа, бу яшькә кадәрге тулы эшкә сәләтлелеге *эмансипация* дип атала. Әгәр дә әти-әниләр каршы килсә, мондый процедура суд тәртибендә башкарыла. Алар ризалашкан очракта, эмансипация опека һәм попечительлек органы карары белән урнаштырыла (бу җирле үзидарә органы балалар мәнфәгатьләрен кайгырта).

Баланың бөтен хокуклары һәм ирекләре түбәндәге төрләр буенча классификацияләнә.

Гомумгражданлык һәм сәяси хокуклар. Бала ирекле рәвештә үз фикерләрен әйтергә һәм үзенә хөрмәт таләп итәргә хокуклы, чөнки ул ата-аналар милке түгел, ә гаиләнең тулы хокуклы әгъзасы. 10 яшьтән бала фикеренә юридик мәгънә салына. Әти-әниләре баланың кайсы мәктәптә укырга, кайда яшәргә тиешлеге һәм аның исемен яки фамилиясен үзгәртү мөмкинлеге турында бәхәсләшәләр дип күз алдына китерик. Мондый очракта баланың үз фикереннән башка берни дә эшләп булмаячак.

Балалар бернинди тоткарлыксыз илдән читкә чыгарга яки кире кайтырга хокуклы. Кагыйдә буларак, бала чит илгә туристлык юлламасы яки дуслары чакыруы буенча әти-әниләре белән чыга. Башка очракларда алар ата-аналарыннан башка да чыгарга мөмкин. Мондый вакытта ата-аналар баланың чит илгә чыгуына ризалыкларын язма рәвештә бирергә тиешләр, ризалык язуы нотариуста раслана.

Закон балаларга тыныч демонстрацияләрдә, җыелышларда катнашуны, балалар һәм яшьләр оешмаларында торуны тыймый. 10 яшьтән — балалар оешмасы әгъзасы, ә 14 яшьтән яшьләр оешмасы әгъзасы булырга мөмкин. Әмма балаларны сәяси партияләргә һәм оешмаларга мәҗбүри кертү тыела.

Балалар үз хокуклары бозыла дип исәпләсәләр, мөстәкыйль рәвештә опека һәм попечительлек органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Алар 14 яшьтән үз хокукларын яклап судка мөрәҗәгать итә алалар.

Бала, өлкән гражданин кебек үк, вөҗдан ирегенә хокуклы. Ул теләсә кайсы динне тота ала яки аларның берсен дә тотмаска мөмкин. Балаларны дини секталарга мәҗбүри рәвештә кертү тыела.

Гаилә хокукы. Һәр бала гаиләдә яшәргә хокуклы. Аны бернинди сәбәпләр белән дә гаиләсеннән аеру тыела. Бик сирәк очракларда гына ата-аналар ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителергә мөмкин. Ничек кенә булмасын, бала үз әти-әнисенең кем булуын белергә һәм алар белән аралашырга хокуклы. Закон балага әти-әнисе яшәгән илгә тоткарлыксыз керү турында рөхсәт алырга мөмкинлек бирә. Гаилә хокукының махсус нормалары ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала, алар нигезендә ата-аналар үз балаларын тәрбияләргә бурычлы. Баланың ата-ана милкенә хокукы юк, әмма ул аларның әйберләреннән файдалана ала. Ата-аналарның да бала милкенә хокуклары юк. Әгәр бала ятим калса, дәүләт ата-аналар вазифасын үз өстенә ала, балаларны матди яктан тәэмин итеп тора.

Белемгә хокук. Бу хокук балаларга башлангыч, төп, урта (тулы) белем алу һәм конкурс шартларында вузга керү мөмкинлеген бирә. Аларның чит телләр өйрәнергә яки музыка белән шөгыльләнергә теләкләре булган очракта өстәмә рәвештә уку мөмкинлеге дә бар. Мондый белем бирү түләүле яки түләүсез булырга мөмкин. Барлык балалар да тигез хокуклы, шуңа күрә балаларны укытуда бернинди дискриминация дә була алмый.

Социаль хокуклар. Дәүләт һәрьяклап балачакны якларга тиеш. Безнең илдә һәр елны дөньякүләм бәйрәм — Балаларны яклау көне (1 июнь) билгеләп үтелә, аз керемле гаиләләрнең балалары өчен һәртөрле ярдәм программалары эшләнә. Мондый балаларга ай саен пособиеләр түләнергә тиеш. 3 яшькә кадәрге балаларга, ә күп балалы гаиләләрдә 16 яшькә кадәр дарулар табиб рецепты буенча бушлай җибәрелергә тиеш. Мәктәпләрдә алар өчен бушлай ашату оештырыла. Балаларның әти-әниләре үлгән очракта, аларга пенсияләр билгеләнә.

Торак хокукы. Бала, олылар кебек үк, торакка хокуклы. Баланы әти-әниләре теркәлгән фатирга керткәндә, гаиләнең

башка әгъзалары ризалыгы таләп ителми. Әгәр өлкәннәр торак мәйданын хосусыйлаштырырга уйласалар, анда теркәлгән 15–18 яшьлек яшүсмернең торакны милеккә әверелдерүгә ризалыгын алырга тиешләр. Ата-аналар ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән булсалар да, бала алар фатирыннан файдалану хокукын саклый.

Хезмәт хокукы. Бала, әгәр дә күпмедер табыш булуын теләсә, әлбәттә, укудан буш вакытта эшләргә мөмкин. 16 яшьтән закон тыймаган эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә була. Әйтик, яшь кешегә 16 тулды, ә ул үзенә эш таба алмады, ди. Мондый очракта хокук аны эшсез дип танырга һәм пособие алу мөмкинлеге бирергә рөхсәт итә.

Безнең илдә авыр һәм зыянлы эшләрдә аз түләү белән бергә балалар хезмәтеннән файдалану очраклары да шактый. Күп кенә илләрдә балалар хезмәтен файдалану бик кулай була, һәм бала кол хәлендә кала. Безнең илдә балаларны белем алуга зыян китереп эшләтү тыела. Шулай ук балалар хезмәтеннән аларның сәламәтлегенә зыян килү куркынычы янаган авыр җитештерү өлкәләрендә файдалану да тыела.

Баланың хокуклары гына түгел, бурычлары да бар. Мисал өчен, ул төп гомуми белем алырга тиеш. Укучыларның бурычлары уставта беркетелгән. Яшь егетләрнең хәрби бурычлары бар, ул хәрби исәптә торудан һәм хәрби хезмәткә әзерләнүдән гыйбарәт. 17 яшьтән малайлар, хәрби комиссар чакыруы буенча, исәпкә кертелү өчен килергә тиешләр, ә 18 яшьтән алар хәрби хезмәткә чакырылалар. Бу бурыч илебез иминлегенә хокукларыбыз нигезенә ята һәм дәүләтнең оборона сәләтен сакларга ярдәм итә, ә кирәк булган очракта аның гражданнарын якларга булыша. Әмма 15 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар хәрби хәрәкәтләрдә катнаша алмыйлар. Аларга корал сатып алу һәм саклау тыела. Шулай ук газ пистолетлары, аэрозольләр, электрошок, пычаклар йөртергә дә ярамый. Мондый тыюлар балаларны аларның сәламәтлегенә, тормышына янаган куркыныч хәлләрдән саклый. Ил гражданы өстенә йөкләнгән бурычларның үтәлеше балалар өчен дә мәҗбүри.

Төшенчәләр: *өйләнешү контракты, хокукый сәләтле, эшгамәлгә сәләтлелек.*

Сораулар һәм биремнәр

*1. Ни өчен балалар турында кайгырту һәм аларны тәрбияләү ата-аналарның хокукы гына түгел, ә бурычы да?

2. Балаларның карт һәм эшкә сәләтсез ата-аналары турында кайгыртуы нәрсәләрдә чагыла?

3. Балаларның түбәндәге хокуклары мәгънәсен конкрет мисаллар өстендә аңлатыгыз:

вөҗдан ирегенә хокук;

яшәүгә хокук;

белем алуга хокук.

*4. Балаларны тәрбияләүдә һәм аларга белем бирүдә һәр дәвернең үз кагыйдәләре була. Россия хокук нормаларында бала тәрбияләү кагыйдәләре беркетелгән төгәл юридик нормалар юк. Сез балаларны ничек тәрбияләү һәм алар тормышта үзләрен ничек тотарга тиешлеге турында закон чыгару мөмкинлеге туды дип күз алдыгызга китерегез. Ул законда нинди хокук нормаларын билгеләр идегез?

*5. Тикшеренү мәгълүматлары күрсәткәнчә, 79,6% ата-аналар үз балаларының, бик үк белемле булмасалар да, тормышка яхшы яраклашкан булуларын телиләр. Ә сез бу җәһәттән нәрсә уйлыйсыз?

6. Сезнең кайчан да булса бала хокукларын бозу белән очрашканыгыз бармы? Бозылган хокукларны ничек якларга мөмкин?

? Проблема. Галимнәр фәнгә «гаиләдә куркыныч мөгамәлә синдромы» дигән яңа термин керттеләр. Ул балаларга карата көч куллану, басым ясау рәвешендә чагылырга мөмкин. Уйлагыз, бала бу очракта үз хокукларын яклый аламы һәм ничек итеп? Аңа нинди оешмалар һәм кешеләр ярдәм итә ала?

Практикум. Сезгә 7 яшьлек бала ярдәм сорап мөрәҗәгать итте, ди. Әти-әнисе аны икеләләр алган өчен рәнҗетә, урамга чыгарга рөхсәт итми, дуслары белән аралашуын тыя. Аңа закон тарафыннан беркетелгән хокукларын аңлатыгыз. Килеп туган хәлдән чыгу юлын күрсәтегез.

§ 16 (§ 40). Җинаять

Еш кына тормыш хәлләре кешене закон бозуга китерә. Язмыш чәлпәрәмә килә, әйләнә-тирәдәгеләргә зыян китерелә, әмма кеше җаваплылыктан котылмый. Мондый гамәлләрнең күбесе җәмгыять өчен бик куркыныч. Аларны *гаеп эш* (проступок)

диләр. Әмма Җинаять кодексында теркәлгән һәм кешеләр, җәмгыять өчен аеруча куркыныч саналган гамәлләр дә бар. Юридик яктан бу гаеп эшләр **җинаять** дип атала, чөнки алар хокукый нормаларны бозу буларак карала.

Җинаятьләр *эш-гамәлләр* яки *бернинди эш-гамәл дә кылмау* формасында булырга мөмкин. Мәсәлән, бер граждан җаваплы урында эшли һәм ришвәт ала, өендә наркотиклар тота, ә ял көннәрендә фатирлар талап йөри дип күз алдына китерегез. Аның бу эш-гамәлләре җинаятьчел, аларны эшләп ул активлык күрсәтә: планнар кора, җинаятьтәшләр таба. Ә башка кеше исә бернәрсә дә эшләмәгән кебек: ришвәт алмый, наркотиклар тотмый, урламый, салымнар түләми, табиб була торып, авыруларга ярдәм күрсәтми. Беренче өч очракта ул хокукый яктан дөрес эшли, ә менә соңгы гамәлсезлек очраклары җинаятьчел дип исәпләнә. Кешеләрнең җинаятьчел эш-гамәлләре һәм гамәлсезлекләре җәзага тартылырга тиеш.

Җинаятьне теләсә кайсы гаеп эшләрдән өч билге аерып тора:

— кылынган эш-гамәлләр кеше, җәмгыять һәм дәүләт өчен зыянлы һәм бик куркыныч булырга тиеш;

— кылынган эш хокукка каршы, ягъни җинаятькә каршы хокук нормаларын боза торган булырга тиеш; Җинаять кодексында мондый эш-гамәлнең күрсәтелүе зарур;

— кешенең эш-гамәлләре гаепле дип саналырга тиеш. Гаеплелек булмаганда, җинаять тә юк.

Хәзер соңгы вакытта үзегез яки танышларыгыз кылган эш-гамәлләргә анализ ясагыз. Әгәр алар шушы билгеләргә тулысынча туры килә икән, димәк, җинаять кылынган дигән сүз, һәм алар өчен җәза биреләчәк. Шуны да истә тотыйк, *җинаятьне бары тик кеше генә эшли ала*. Әгәр дә яшен аркасында бизнесмен бакчасында янгын башланып, аның мөлкәте янып бетсә, монда бернинди дә җинаять була алмый. Чөнки моны кылган гаепле кеше юк. Әгәр дә гөмбә җыючыга урманда бүреләр һөҗүм итсә? Алар (бүреләр) гаеплеме соң? Юридик яктан караганда — юк һәм җаваплылыкка тартыла алмыйлар, шуңа күрә бу очракны җинаять дип әйтеп булмый.

Кешенең гаебе *явыз ният белән эшләү* яки *саксызлык формасында гәүдәләнергә мөмкин.* Ике ситуацияне карап үтик. Бер җинаятьчел төркем чит илгә корал сату белән шөгыльләнә, ди. Бу турыда бер журналист ишетеп ала. Ул сенсацион репор-

таж әзерләргә тели, әмма банданың бер әгъзасы аны сизеп ала. Үтерүче (киллер), банда җитәкчесе белән килешеп, журналистны үтерә. Бу үтерү алдан планлаштырыла. Монда гаеп *турыдан-туры явыз ният* формасында гәүдәләнеш таба.

Подъезд төбендә, килеп туган бәхәсне хәл итә алмыйча, егетләр сугыша башлый. Аларның берсе бик каты итеп икенчесенә суга. Көтелмәгән хәл килеп чыга: бу сугулардан аның элекке дусты үлеп китә. Егет аны үтерергә теләми, ә акылга утыртмакчы гына була. Бу *алдан уйланмыйча кылынган гамәл* була.

Гаепнең башка формасы *саксызлык* рәвешендә гәүдәләнеш таба. Автомобиль йөртүче, эшкә соңга калмас өчен, светофорның кызыл утына чыгып өлгерергә исәпли. Якында гына җәяүлеләр дә, машиналар да булмый. Әмма кисәк кенә әллә каян бер малай йөгереп чыга, чөнки яшел ут яна. Машина йөртүче тормозга басарга өлгерми кала, бала тән җәрәхәтләре ала. Шофер бу малайга явызлык эшләргә теләгәнме соң? Әлбәттә, юк. Әмма аның саксызлыгы шундый авыр хәлгә китерә.

Җинаятькә алдан әзерләнәләр. Җинаятьтәшләр, ягъни җинаять кылуда ярдәм итүчеләр җәлеп ителә. Законда бу рольләр билгеләнгән, һәм аларның башкаручылары җавапка тартыла. *Оештыручы* план төзи, *башкаручы* аны тормышка ашыра. *Котыртучы* башка кешеләрне хокукка каршы гамәлләргә җәлеп итә. *Ярдәмче эшләрдә йөрүче исә* киңәшләр һәм күрсәтмәләр бирә.

Аерым төркемнәргә тупланып, җинаятьчеләр кырыс кагыйдәләрне канун иткән оешмалар төзиләр, бу кагыйдәләргә төркемнең бөтен әгъзалары да буйсынырга тиеш була. Галимнәр күпчелек кешеләрнең психикасында кемгәдер буйсыну, кемгәдер бәйле булу омтылышы ятуын расладылар. Бу хәл кешене көчсез бер затка әверелдерә. Мондый төркемнәрнең лидерлары, киресенчә, үз өстенлекләрен башка лидерларга сугыш игълан итеп белдерәләр. Җинаятьчел бергәлекләрдә катнашу аеруча кырыс җәзага тартыла.

Шулай итеп, без законнарны беләбез, әмма нишләптер аларны бозабыз. Бу ни өчен шулай килеп чыга соң? Кешеләрнең ни өчен җинаятьләр кылуы һәм хата гамәлләр эшләве турындагы сорау бик борынгыдан ук өйрәнелгән. Кайбер тикшерүчеләр барысы да кешенең индивидуаль үзенчәлекләреннән тора, дип исәплиләр. Менә, мәсәлән, җинаятьчеләрнең баш

сөяге төзелеше һәм тышкы кыяфәте үзенчәлекле була, диләр. Без нindидер бер кешене күргәч, әчтән генә: «Нинди шикле бәндә. Җинаятьчегә тартым»,— дип уйлыйбыз. Әмма бу чыннан да шулаймы соң? Мондый фикерләрне нигез итеп алып, фашистлар җинаятьчел расалар булу турындагы идеягә башлангыч бирделәр. Башка тикшеренүчеләр исә, җинаятьчелек турыдан-туры кешенең яше белән бәйле, дип исәплиләр. «Яшүсмерләрдән куркам,— ди бер хатын автобуста,— алар үзләре кылган гамәлләрнең нәрсәгә китерәчәген әле аңламыйлар. Башка яшьтә алар моны эшләмәсләр иде». Өченчеләр исә барысы да кешенең тәрбиясеннән тора дип исәплиләр. Начар гаиләләрдә үскән бала, һичшиксез, законны бозачак, диләр. Ә менә тәртипле гаиләдә җинаятьче үсмәячәк.

Барлык хокук бозулар өчен дә *җавап бирергә* туры киләчәк, гаепле кеше кылганнарының үзе өчен начар нәтиҗәләрен тоячак. Административ хокук нормаларын бозу ***административ гаеп эш*** дип атала. Хокукның мондый нормалары иҗтимагый һәм дәүләттәге тәртипне, гражданнарның шәхси милкен һәм хокукларын саклый. Кемдер урамда начар сүзләр әйтеп сүгенә һәм үтеп баручыларга бәйләнә дип күз алдына китерик. Закон моны ***хулиганлык*** дип атый. Елгыр автомобильче юл хәрәкәте кагыйдәләрен боза һәм милиция таләпләренә буйсынмый. Бу да административ гаеп эш. Азартлы карта уеннарын, рулетканы, акчага, әйберләргә уймак уйнауны да шулар рәтенә кертәләр. Паркта яки урамда йөрүче исерек тә административ хокук боза. Әгәр дә вазифалы затлар предприятиедә үз хезмәткәрләренә хезмәт хакын тоткарласалар? Алар да кеше хокукларын бозалар һәм җинаять җаваплылыгына (ирегеннән мәхрүм ителүгә кадәр) тартылырга мөмкиннәр. Закон *административ хокук бозуларның* барлык төрләре өчен дә җаваплылык билгели.

Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе хезмәткәре елгыр автомобильчене туктатырга һәм штрафка тартырга хокуклы. Браконьерлар компаниясе тыелган урында балык тота. Аларны штрафка тартып кына калмыйлар, браконьерлык коралларын да алалар. Милиция хезмәткәрләренә хокук бозу коралына әверелгән предметны тартып алу рөхсәт ителә. Җавапка тартуның тагын да кырысрак төрләре бар. Мәсәлән, тәртип бозучының машина йөртергә хокук бирүче махсус документын (правасын) алырга һәм машина йөртүне тыярга

мөмкиннәр. Башка тәртип бозучыларга төзәтү эшләре билгелиләр яки хәтта 15 тәүлеккә административ кулга алулары да мөмкин.

Закон җавапка тартуларны һәр теләгән кеше түгел, ә бары тик моңа махсус вәкаләте булган затлар гына тормышка ашыра алуын искәртә. Мәсәлән, сез завод директорының янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуын белсәгез дә, аңа штраф сала алмыйсыз. Сезнең бу эшкә закон билгеләгән вәкаләтегез юк.

Тагын кемнәр җавапка тарта ала соң? ***Административ җаваплылык 16 яшьтән башлана***. Балигъ булмаганнар белән балигъ булмаганнар эшләре буенча махсус комиссияләр эшли. Хокук бозулар өчен алар 11–14 яшьлек балаларны сәламәтләндерү-тәрбияләү характерындагы *махсус мәктәпләргә*, ә 14 яшьтән соңгыларны *махсус һөнәр училищеларына* җибәрергә мөмкин. Йогынты ясауның тагын да кырысрак чаралары каралган. Гадәттә, андый чараларны наркотиклар алган, саклаган яки кулланган өчен, хайваннарны газаплаган өчен, җәмәгать транспортына яки урам телефоннарына зыян китергән өчен, мотоциклларда һәм башка транспортта төркем булып шәһәр буйлап чабып, юл хәрәкәтенә комачау тудырган өчен кулланалар.

Административ җавапка тарту хокукына ия булучыларга милиция һәм салым полициясе органнары, административ комиссияләр, авыл җирләрендә — җирле администрация керә. Ә суд? Суд шулай ук административ бәхәсләрне хәл итә ала. Мәсәлән, урамда сатучы үзенә милиционерның сәбәпсез бәйләнүен һәм даими төстә штрафка тартуын ошатмый. Закон буенча ул судка мөрәҗәгать итә ала.

Әгәр гражданлык хокукы нормалары бозыла икән, бу **гражданлык хокукын бозу гамәле** була. Мәсәлән, сез фирма директоры һәм партнерыгыз белән курткалар китерү турында контракт төзедегез, ди. Килешү буенча алынган товар сыйфатсыз булып чыкты һәм, өстәвенә, соңрак та китерелде. Сезнең партнерыгыз контракт шартларын бозды һәм моның өчен ул җавап бирәчәк. Мөгаен, мондый очрак турында сез алдан ук сөйләшеп куйгансыздыр. Әгәр дә юк икән, курткалар китерүче барыбер штраф түләргә һәм сезгә китергән зыянны капларга тиеш. Гражданлык-хокукый җаваплылык әнә шулай барлыкка килә.

Эштә хезмәт дисциплинасын бозу **дисциплинар гаеп эшкә** китерә. Һәрвакыт соңга калып йөрергә гадәтләнгән кешеләр була. Алар башкача булдыра алмый. Очрашуларга, кунакка соңга калып киләләр. Әгәр дә мондый кеше даими төстә эшкә соңга кала икән, ул *дисциплинар җаваплылыкка* тартылырга мөмкин. Җитәкче кеше соңга калулар, эшкә килмәүләр өчен хезмәткәргә шелтә белдерергә һәм хәтта эштән азат итәргә мөмкин. Хезмәт барышында еш кына хезмәткәрләр эш бирүченең милкенә зыян китерәләр. Мәсәлән, шофер фирма машинасында йорт җиһазлары ташый һ.б. Саксызлык аркасында машинага зыян килә. Мондый очракта хезмәткәр машинаны үз хисабына төзәтергә тиеш. Шулай итеп, милеккә зыян китерелгән икән, гаепле кеше *матди җаваплылыкка* тартыла. Кеше нинди генә җинаять кылса да, аны җинаять җаваплылыгына тарталар. Безнең илдә ул 16 яшьтән кулланыла. Ирландия җинаять хокукы буенча — 7 яшьтән, Португалиядә 12 яшьтән җавапка тарталар. Әйдәгез, РФ Җинаять кодексының 20 нче маддәсен бергәләп укып карыйк. Ул нинди җинаятьләр өчен 14 яшьтән җинаять җаваплылыгына тартуны күрсәтә.

«Җинаять кылучылар 14 яшькә җиткән икән, алар үтергән, явыз ният белән сәламәтлеккә авыр зыян китергән, явыз ният белән сәламәтлеккә уртача зыян китергән, кеше урлаган, көчләгән, сексуаль характердагы көчләү гамәлләре кылган, талаган, юлбасарлык кылган, янап алган өчен, автомобиль яки башка транспорт чарасын урлау максатыннан тыш законсыз алган, милеккә алдан уйлап бик авыр зыян салган яки аны бөтенләй юкка чыгарган өчен, терроризм, заложниклар алган, террор актлары турында ялган хәбәр җиткергән, бик авыр дәрәҗәдәге хулиганлык кылган, вандализм, корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч чаралар һәм шартлаткыч матдәләр урлаган яки талап алган өчен, наркотик чаралар яки психотроп матдәләр урлаган яки талап алган өчен, транспорт чараларын яки элемтә юлларын яраксыз хәлгә китергән өчен җинаять җаваплылыгына тартылалар».

РФ Җинаятькә каршы хокукында катгый кагыйдә бар: әгәр дә кеше законда күрсәтелмәгән куркыныч эш кылса, ул җинаять җаваплылыгына тартылмый. Тормышта мондый хәлләр буламы соң? Әлбәттә. Шуңа күрә дә законга үзгәрешләр кертәләр. Законга тиңләп кешене җәзага тарту тыела. 30 нчы

елларда мондый очраклар да булгалаган. Көннәрдән бер көнне бер сатып алучы дустын кибеттә очраткан да аңа мәзәк сөйләгән. Анда хакимиятне законсыз рәвештә тартып алган борынгы кабилә юлбашчысы турында сүз барган. Кемдер моны турыдан-туры Сталинга ишарә дип кабул иткән. Ил законнарында мәзәк сөйләү җинаять дип күрсәтелмәгән. Әмма, законга тиңләп, бу кешене советка каршы пропаганда өчен җавапка тартканнар.

Безнең илдә, башка дәүләтләрдәге кебек үк, *гаепсезлек презумпциясе принцибы* гамәлгә кертелгән. Аның буенча бары тик суд кына кешене җинаятьче дип әйтә ала һәм аңа җәза чарасын билгели. Гаепне билгеләгәнче хокук саклау органнары бик җентекле тикшерү эше алып баралар.

Яшүсмерләр төркемен базарда тоткарладылар, ди. Алар сатып алучылардан янап акча талап йөриләр, ә кайберәүләр сумкаларыннан акча янчыкларын чыгаралар. Җинаять эше кузгатыла. Кагыйдәләр буенча, сорау алу һәм башлангыч тикшерү үткәрергә кирәк була. Башта юридик яктан мондый балаларны *шик астына алынучылар* дип атыйлар, чөнки җинаять эшләүдә шик алар өстенә төшә. Гаепләре танылгач, алар инде *гаепләнүчеләр* булалар. Әмма бу һичшиксез шулай булырга тиеш дигән сүз түгел. Шик астына алынучыларны, әгәр аларның хокукка (законга) каршы берни дә эшләмәүләре ачыкланса, бөтенләй

чыгарып ук җибәрергә мөмкиннәр. Аларның кайберләре әлеге *эш буенча шаһитлар* буларак чыгыш ясыйлар.

Тикшерүче — *эчке эшләр органнарының вәкаләтле* заты. Ул кылынган гамәл турында мәгълүматлар туплау өчен сорау алу үткәрә. Тикшерүче сорау алуларда файдалана торган махсус тактик алымнар бар. Алар *криминалистикада* эшләнгән. Криминалистика — җинаятьләрне тикшерүнең техник һәм тактик чараларын, алымнарын өйрәнүче фән. Сорау алу вакытында тупланган барлык мәгълүматлар беркетмәдә (протоколда) теркәлә. Балигъ булмаганнардан сорау алганда педагог һәм ата-аналар чакырылырга мөмкин. Әгәр яшүсмерләр алдында аларның абруе булмаса, аларны чакырып тормыйлар. Менә сорау алулар бетте, эшнең бөтен вакыйгалары ачыкланды. Хәзер тикшерүче гаепләү бәяләмәсе (заключение) төзи, прокурор аңа кул куя һәм эш судка тапшырыла.

Суд процессы утырышында кылынган гамәл һәм гаепләнүченең андагы роле кабат тикшерелә. Суд *аклаучы* яки *гаепләүче* хөкем чыгара. Әгәр дә кеше җинаять кылган һәм суд аны раслый алган икән, һичшиксез, закон тарафыннан каралган ***җәза*** биреләчәк. Җәзаның төп төрләре бар: мәҗбүри һәм төзәтү эшләре, хәрби хезмәт буенча чикләүләр, кулга алу, ирекне чикләү, дисциплинар хәрби частьта тоту, билгеле бер вакытка ирегеннән мәхрүм итү, гомерлеккә иректән мәхрүм итү. Болар белән бергә махсус хәрби званиене яки мактаулы исем-дәрәҗәне, класслы чинны, дәүләт бүләкләрен алу, мал-мөлкәтне конфискацияләү, штраф, билгеле бер эшчәнлек төрен биләү хокукыннан мәхрүм итү кебек җәза чаралары да кулланылырга мөмкин.

Закон ***балигъ булмаганнарга карата җәза чаралары*** куллануның махсус кагыйдәләре булуын искәртә. Аларның хезмәт хаклары бар икән, штрафка тартырга мөмкин. Балигъ булмаганнарны укудан яки эштән буш вакытка мәҗбүри эшләргә тартырга була. Мәсәлән, шәһәрне төзекләндерү яки урамнарны чистарту эшләренә. Яшүсмерләр бер елга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә ала. 1–4 айга кадәр кулга алу, җәза чарасы буларак, бары тик 16 яшь тулганнар өчен генә кулланылырга мөмкин.

Иректән мәхрүм итү аеруча кырыс җәза санала. Балигъ булмаганнар өчен ул 10 ел белән чикләнә. Өлкәнрәк җинаятьчеләргә, законга каршы авыр җинаять гамәлләре кылган өчен,

суд 20 елга кадәр иректән мәхрүм итү турында карар чыгарырга мөмкин. Әгәр дә кеше күп җинаятьләр кылган булса, җәза һәр җинаять өчен аерым-аерым билгеләнә һәм иректән мәхрүм итү вакыты 30 елга кадәр җитәргә мөмкин. Балигъ булмаганнар ябылу срокларын гомуми режимлы тәрбия колонияләрендә уздыралар, ә инде кабат җинаять кылучылар өчен кырыс режимлы колонияләр бар.

Кайчакларда суд балигъ булмаганнарны җинаять җәзасы билгеләмичә дә төзәтү мөмкинлеген таный. Ул очракта аларга карата *тәрбияви йогынты чаралары* кулланыла. Алар мәҗбүр итү характерында була. Боларга кисәтү, ата-аналар күзәтүе астына тапшыру, китерелгән зыянны каплау бурычын йөкләү, ял вакытын чикләү һәм үз-үзен тотышына кагылышлы билгеле бер таләпләр кую керә.

Төшенчәләр: *җинаять, гаеп эш, балигъ булмаганнарга җәза бирү.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Хокук (закон) бозу нәрсә ул? Мисаллар китерегез.

2. Җинаять нәрсә ул һәм гаеп эш-гамәлдән нәрсә белән аерыла?

3. Соңгы көннәрдәге тәртибегезне анализлагыз. Сез гаеп эш-гамәлләр кылмадыгызмы? Ни сәбәпле? Аларны булдырмый калу мөмкин идеме?

4. Сезнең карашка, җинаять сәбәбенә әверелә алырлык 5 хәлгә яки вакыйгага мисаллар китерегез. Аларны ничек булдырмый калу мөмкин иде? Шуны аңлатыгыз.

*5. Уйлагыз, закон бозучылар булмаган дәүләтнең булуы мөмкинме? Җавабыгызны дәлилләгез.

6. Административ гаеп эш нәрсә ул һәм аны кылган өчен закон нинди җаваплылыкка тарта?

7. Гражданлык хокукын бозучылар нинди җаваплылыкка тартыла?

*8. Сезгә нинди төр җинаятьләр мәгълүм?

*9. Аңлатыгыз, нәрсә нигезендә кайбер җинаятьләр өчен җаваплылык 14 яшьтән үк башлана?

*10. Җәза бирүнең кайсы системасы нәтиҗәлерәк һәм ни өчен?

? Проблема. Сенеканың: «Ниятләнгән, әмма тормышка ашырылмаган җинаять ул, барыбер, җинаять»,— дигән фикере белән килешеп буламы?

Практикум. Таблицаны тутырыгыз.

Хокук бозу төрләре	Мисаллар	Җаваплылык

Түбәндәге фикерләр дөресме әллә хатамы?

- Җинаятьнең иң төп билгеләреннән берсе булып гаеп тора.
- Кешенең теләсә кайсы шартларда да берни дә эшләмәве, гамьсезлеге җинаять була алмый.
- Балигъ булмаганнар иректән мәхрүм итү кебек җәза чарасына тартыла алмый.



3 (6) нче бүлек. РУХИ СФЕРА

Җәмгыятьнең рухи сферасы кешенең рухи эшчәнлеге чагылган бар нәрсәне һәм өлкәләрне колачлый (сарайлар һәм храмнар төзүдән алып Яңа ел чыршысын бизәүгә кадәр). «Җәмгыятьнең рухи сферасы» төшенчәсенең «иҗтимагый аң» һәм «рухи мәдәният» дигән синоним терминнары да бар. Мәдәният, мораль, сәнгать, фән, дин, белем өлкәсе яки мәгариф җәмгыятьнең рухи сферасы чагылышлары яки формалары булып торалар. «Культура» («мәдәният») төшенчәсенең киң һәм тар мәгънәсе бар: киң мәгънәсе — җәмгыятьнең рухи сферасы, тар мәгънәсе — аның бер өлеше. Ике мәгънә дә дөрес һәм әдәбиятта икесе дә файдаланыла. Бу бүлектә без мәдәният, дин, сәнгать һәм белем (мәгариф) турында сөйләшербез. Һәм тагын өч сорау алдында калырбыз.

1. Мәдәният кыйммәтләреннән **кайсылары** булдырыла, иҗат ителә: картиналар, биналар, киемнәр, идеяләр һәм теорияләр, традицияләр һәм йолалар, биюләр, шигырьләр, романнар, җырлар һ. б.?

2. Мәдәният әсәрләре **ничек** иҗат ителә һәм тарала?

3. Сәнгать әсәрләрен иҗат итүче, тыңлаучы, тамашачы, тәнкыйтьче, чын бәяләүче, меценат һ.б. **кемнәр** алар?

§17 (§41). Нәрсә ул мәдәният

Җәмгыять — институтлар һәм оешмалар бергәлеге генә түгел, ә кешеләрнең *уртак мәдәниятне* формалаштырган зур төркеме дә. Латин теленнән тәрҗемә иткәндә, мәдәният, ягъни

культура (cultura) сүзе «эшкәртү», «үстерү», «белем», «тәрбия», «хөрмәт итү» мәгънәләрен белдерә. Борынгы Римда «культура» дигәндә, иң беренче чиратта, җир эшкәртүне аңлаганнар. Туфракны культуралаштыру, авыл хуҗалыгы культуралары — крестьян хезмәте белән бәйле төшенчәләр. XVIII гасырда европалылар өчен культура, мәдәният рухи, төгәлрәк әйткәндә, аристократик төсмер ала. Бу термин кеше сыйфатларының камилләшүен белдерә башлый. Күп укыган һәм нәзакәтле кешене культуралы дип сыйфатлый башлыйлар. Моңа кадәр «культура» сүзе бездә матур әдәбият, картиналар галереясе, консерватория, опера театры (бу очракларда без аны татарча «мәдәният» сүзе белән билгели алабыз — *тәрҗ. искәрмәсе*) һәм яхшы тәрбиягә бәйләп аңлатылды.

XX гасырда борынгы гади тормыш рәвеше белән яшәүче халыкларны өйрәнүче антропологлар «культура» («мәдәният») сүзенә тагын яңарак мәгънә салдылар. Борынгы ыруглык законнары белән яшәүче Австралия аборигеннарында Африка бушменнарында опера театры да, картиналар галереясы да юк. Әмма аларны дөньяның иң цивилизацияле халыклары белән бәйләүче *нормалар һәм кыйммәтләр системасы* бар, бу система тел, биюләр, җырлар, гореф-гадәтләр, традицияләр һәм үзүзләрен тоту рәвешләре аша чагыла, алар ярдәмендә тормыш тәҗрибәсе туплана, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җайга салына. Болар барысы бергә бөтен бер җәмгыятьнең яки аның бер кисәгенең яшәү рәвешен сыйфатлый. Кешеләрне көнкүреш тормышта әйләндереп алган матди истәлекләр узган мәдәниятне яки мәдәни мирасны тәшкил итәләр. Гореф-гадәтләр һәм матди истәлекләр кадерләп саклана һәм буыннардан буыннарга тапшырыла.

> **МӘДӘНИЯТ** — җәмгыять әгъзасы буларак кеше үзләштергән белемнәрне, дини караш, ышануларны, сәнгать, әхлак, закон, гореф-гадәтләрне, шулай ук сәләт һәм күнекмәләрне туплаган комплекс ул.

Анда билгеле бер җәмгыятькә, милләткә, төркемгә хас билгеләр чагыла. Җәмгыятьләр, милләтләр һәм төркемнәр үзләренең мәдәниятләре белән бер-берсеннән аерылалар. Халыкның мәдәнияте — *ул аның тормыш рәвеше, киеме, торагы, аш-суы, фольклоры, рухи карашлары, дини ышанулары, теле һ.б.* Мәдәнияткә шулай ук социаль-көнкүреш кагыйдәләре, җәмгыятьтә

кабул ителгән итагатьлелек һәм сәламләү ишарәләре, йөрү рәвеше, этикет, гигиена гадәтләре дә керә. Йорт кирәк-яраклары, кием, орнамент, фольклор — болар барысы этник төсмергә ия, алар буыннан-буынга тапшырылып, этник стильне барлыкка китерәләр.

Әгәр дә без мәдәниятне кешеләрнең меңнәрчә буыннары тарафыннан тудырылган катлаулы система рәвешендә күзалласак, һичшиксез, аның башлангыч күзәнәкләрен яки *элементларын, билгеләрен* күрербез. Алар ике төрле: *матди* һәм *матди булмаган*. Беренчеләрнең кушылмасы ***матди мәдәниятне*** — мәдәниятнең үзенчәлекле формасын барлыкка китерә. Аңа кеше кулы белән тудырылган физик объектлар керә (аларны *артефактлар* дип атыйлар): пар машинасы, китап, хезмәт коралы, торак йорт, галстук, бизәнү әйбере, буа һ.б. Артефактлар кеше кулы тарафыннан тудырылулары, символик мәгънәгә ия булулары, билгеле бер функция башкарулары һәм төркем яки җәмгыять өчен билгеле бер кыйммәткә ия булулары белән аерылып торалар. ***Матди булмаган***, яки ***рухи мәдәниятне*** нормалар, кагыйдәләр, үрнәкләр, эталоннар, үз-үзеңне тоту модельләре һәм нормалары, законнар, кыйммәтләр, церемонияләр, йолалар, символлар, мифлар, белемнәр, идеяләр, гореф-гадәтләр, традицияләр, тел ***барлыкка китерә.*** *Алар да кеше эшчәнлеге нәтиҗәсе, әмма кул белән түгел, ә акыл тарафыннан тудырылалар. Матди булмаган объектлар безнең аңыбызда яши һәм кешеләр арасындагы аралашу белән сакланып тора.*

Күперләр яки храмнар бик озак вакытлар саклана, ә церемонияләр яки йолалар алар белән бәйле гамәлләрне башкарганда гына яшиләр. Өйләнешү тантанасы (церемониясе), күп тапкырлар кабатлануга карамастан, берничә сәгать дәвам итә. Церемония, теләсә кайсы матди булмаган мәдәни объект кебек үк, матди арадашчыга мохтаҗ. Белемнәр китаплар аша чагылыш таба, исәнләшү йоласы кул кысышу һәм сүзләр белән белдерелә. Галстук йөртү — бу да ритуал (яки символик) гамәл, дөньяви этикетның бер кисәге. Әгәр дә матди арадашчы — галстук — катнашмаса, бу гамәл мөмкин булмас иде.

Сабан, пар машинасы, чагыштырмалылык теориясе, тигезлек һәм гаделлек идеясе, кунакчыллык гадәте һ.б. мәдәният элементы булып торырга мөмкин. Кайбер элементлар ялгыз гына да яшиләр, ә кайберләре, тарту көче үзәге кебек, үзләре

тирәсендә яңа элементлар туплыйлар. Бу очракта мәдәният комплексы турында әйтергә мөмкин.

МӘДӘНИЯТ КОМПЛЕКСЫ — башлангыч элемент базасында барлыкка килгән һәм функциональ яктан аның белән бәйләнгән мәдәниятнең барлык сыйфатлары яки элементлары.

Спорт уены, аерым алганда футбол, моңа мисал була ала. Ул уен белән стадион, тамашачылар, реферлар, спорт киеме, туп, пенальти, форфорд һ.б. бәйләнгән. Сабан барлыкка килү игенчелектә чып-чын революция ясый, миллионнарча кешенең тормыш рәвешен, хуҗалык итү ысулын үзгәртә. Китап басу эшен һәм пар машинасын уйлап табу да шундый ук әһәмияткә ия була. Дәрәҗә (звание) һәм титуллар кертү, милекне мирас итеп калдыру яки инициация йоласы (үсмерләрне өлкәннәр тормышына багышлау йоласы), ул кадәр үк күренекле булмасалар да, бик әһәмиятле вакыйгалардан санала. Алар тормышка яңа социаль институтларны, хакимият формаларын, бүләкләү системаларын, законнарны алып киләләр.

Мәдәнилек комплексына иң ачык мисалларның берсе булып *этикет* тора. Ул цивилизацияле җәмгыятьне генә түгел, иң беренче чиратта кешеләрнең бер-берсен хөрмәт итүенә корылган дөньяви җәмгыятьне сыйфатлый.

Өстәмә уку. Дөнья халыкларында этикет

Этикет — француз сүзе, ябыштыргыч («наклейка») яки «ярлык» мәгънәсен белдерә. Соңрак ул яңа мәгънәдә дә кулланыла башлый. Этикет үз-үзеңне тиешле рәвештә тоту кагыйдәләре теркәлгән кәгазь бите буларак күзаллана, бу кагыйдәләр француз корольләре, башлап Людовик XIV сараенда кертелгән була. Алар дворяннарны король каршында тупас хаталардан саклый. «Яхшы гадәтләр җыентыгы» мәгънәсендәге «этикет» сүзе XVIII гасырда инглиз телендә дә урын ала. Этикет турындагы хәзерге китаплар француз короле сараендагы кагыйдәләр җыентыгы кебек үк бер максатка хезмәт итәләр. Алар күп еллар дәвамында тупланган яхшы (уңай) гадәтләр кагыйдәләрен аңлаталар, кешеләргә теләсә-кайсы ситуациядә үзләрен ышанычлы тотарга ярдәм итәләр.

Яхшы гадәтләр дуслар табарга булыша. Ягымлы һәм киң күңелле кешеләрне күпләр үз итә. Күркәм гадәтләр туганнар, дуслар яки бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән аралашудан ямь табарга булыша. Яхшы гадәтләр өйдә башланалар, мәктәптә дәвам итәләр. Сыйныфташлар яки укытучы белән ягымлы мөнәсәбәт кенә түгел, ә биремне намус белән башкару да «этикет»

төшенчәсенә керә. Үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү кичәләрдә хурлыкка калмаска ярдәм итә. Әдәплелек нигезләре кешеләр белән яшәүнең иң гади кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт, мәсәлән, машина йөртүче җәяүлеләргә пычрак чәчрәтеп китмәскә яки кирәксез урында борылып, башка машиналарга комачау ясамаска тиеш.

Этикетның шактый формалары һәм элементлары бик борынгы заманнарга барып тоташа. Мәсәлән, исәнләшкәндә кул кысышу антик заманнарда ук булган. Ир кеше ачык уң кулын сузганда, үзенең коралсыз һәм ниятләре яхшы булуын белдергән.

Башка киелгән эшләпәне күтәреп кую да урта гасырларда таралган борынгы гадәт булган. Мөгаен, ул, бер-берсен тану өчен битлекләрен салган рыцарьлардан башлангыч алгандыр.

Ихтирамлы сүз-мөрәҗәгатьләрнең дә үз тарихы бар. «Мистер» сүзе — «мастер» сүзенең модификациясе, латин телендәге суд термины *magister* терминыннан килеп чыккан, ул «юрист» һәм «закон чыгаручы» мәгънәсен аңлаткан. XVIII гасырда Америкада яшәгән хатын-кызлар ирләренә мөрәҗәгать иткәндә, аларның фамилияләренә исемнәре урынына «мистер» сүзен өстәп эндәшкәннәр. Хәзер исә бөтен ирләргә дә шулай мөрәҗәгать итәләр, бер үк вакытта рәсми дә, хөрмәт күрсәтү дә була. « Сэр» мөрәҗәгате «сеньор» сүзеннән килеп чыккан, бу сүз урта гасырларда Франциядә «алпавыт» мәгънәсен белдергән. Хатын-кызларга «мадам» дигән итагатьле мөрәҗәгать «минем госпожам» дигән күптәнге француз терминыннан башлангыч ала, ул сүз белән түбән катлау вәкилләре король сараендагы ханымнарга мөрәҗәгать иткәннәр.

Кунакчыллык этикетында кунакка чакыру һәр халыкта һәм һәрчак мөһим урын алып тора. Төньяк Америка индеецлары, болан тиресенә язып, кунакларга чапкын белән чакыру җибәрә торган булганнар. Шекспир заманында чакырулар киң ак кәгазьгә язылган һәм бик матур итеп чәчәкләр белән бизәлгән. Башка төрле итеп чакыру кимсетү дип саналган.

Өйдә кунаклар кабул итү — шулай ук этикет элементы. Японнарда чәй тантаналарының аеруча мөһим булуы мәгълүм. Аларда кунакка кәгазь кисәкләренә салып кечкенә конфетлар һәм пирожное бирәләр. Ашап бетермәгән кисәген кунак кәгазьгә төреп өенә алып кайтып китә, бу яхшы гадәт санала. АКШта да хуҗабикәләр кунакларга ризык, мәсәлән, туй яки туган көн бәлеше кисәген өйләренә биреп җибәрәләр.

Борынгы грекларда кунакчыллык символы булып тоз исәпләнгән, ә гарәпләр кунак кулын җылы сөт белән юганнар. Индеецларда татулашу трубкасы тарту — кунакчыллык йоласының төп билгесе.

Европада өстәл приборлары XVII гасыр ахырына кадәр бөтенләй диярлек булмаган. Кешеләр пычакны үзләре белән йөрткәннәр һәм ашаганда файдаланганнар. Бүген пычаклар һәм чәнечкеләр барлык илләрдә дә кабул ителгән, әмма аларны куллану кагыйдәләре төрлечә. АКШта пычакны уң кулда, ә чәнечкене сул кулда тоталар. Ризыкны кискәч, пычакны куялар да чәнечкене уң кулга алалар. Европаның күпчелек илләрендә чәнечке сул кулда кала.

Кытайлар ашаганда таякчыклардан файдаланалар. Савытка таякчыкларны берсе өстенә икенчесен тәре формасында кую кунакның өстәл артыннан чыгарга җыенуын белдерә.

Этикетның милли генә түгел, ә милләтара кагыйдәләре дә була. Мәсәлән, БМО утырышларында илчеләр үз илләре атамаларына карап алфавит тәртибендә утыралар, ә менә чакырулы яки рәсми булмаган кичәләрдә аларның иерархиясе күзәтелә. Дипломат тарафыннан күрсәтелгән теләсә нинди әдәпсезлек билгесе бөтен илнең әдәпсезлеге буларак кабул ителә.

Әгәр дә сүз көндәлек гадәт түгел, ә нәзакәтле яки югары әхлакый тәртип турында барса, этикет үз-үзеңне тотуның үзенчәлекле идеаль бер кодексына әверелә. Ул борынгы чорлардан ук мәгълүм. «Үзеңә карата нинди булуларын теләсәң, башкалар белән үзең шундый бул» кагыйдәсе Иске Гаһедтәге (Ветхий завет) «якыннарыңны үзеңне яраткан кебек ярат» дигән өндәүдән үк башлангыч ала. Мондый кагыйдәләргә борынгы акыл ияләре фикерләрен, мәсәлән, Кытай фикер иясе Конфуций сүзләрен өстәргә мөмкин.

Борынгы Кытай трактаты «И-Ли» (Этикет һәм Церемонияләр китабы) югары аксөякләр өчен язылa һәм дәүләт чиновникларын нәзакәтле гадәтләргә (модалы киләмәк кияргә һәм чәч рәвешен тиешенчә сакларга, үз-үзеңне тоту тәртипләренә, баш ию кагыйдәләренә, йөз-чырай рәвешенә) өйрәтә. Катгый этикет белән, кытайлар үзләрен һәм үз хисләрен контрольдә тотарга өйрәнәләр. Япон самурайлары язылмаган «Бушидо» кодексына таяналар, бу кодекста сугышчының яхшылык, намуслыяык һәм кыюлык сыйфатларының хуҗасына булган тугрылыгы белән үрелүе таләп ителә. Дан һәм хөрмәткә ирешү өчен, самурай бөтен газапларны, михнәтләрне зур сабырлык белән кичерә, хәтта тормышы белән хушлашырга да әзер тора.

Антик Грециядә идеаль кеше «калос кагатос» (матур һәм мәрхәмәтле) булган. Мондый кеше гакыллы, гадел һәм кыю, шулай ук рәхимле, гадел һәм дустанә булырга тиеш дип исәпләгәннәр. Ә тыйнаклык мәҗбүри сыйфат дип саналмаган. Римлылар өчен тышкы матурлык түгел, ә үз-үзеңне яхшы тоту мөһимрәк булган.

Алар ярлыга да, байга да, җитәкчегә дә, гади кешегә дә тигез хөрмәт белән караганнар.

Үз-үзеңне яхшы, матур тоту Европада рыцарьлык заманнарында чәчәк ата. Франциядә әлеге заман XI гасырда башлана. Рыцарьларны кулга кылыч тотып һәм үз үзләрен аямыйча христианлыкны якларга һәм гүзәл ханымга буй сынырга өйрәткәннәр. Еш кына рыцарь үзенең ханымына читтән торып кына баш игән, аның белән беркайчан сөйләшмәгән, мөгаен, хәтта бөтенләй күрмәгәндер дә. Рыцарьлык этикеты соңрак дворяннарның барлык катлауларына, аеруча сарай дворяннарына үтеп кергән. Шуңа күрә дә аның соңрак чор атамасы — «сарай этикеты» сакланып калган. Мондый кагыйдәләр теркәлгән беренче трактат Италиядә 1528 елда нәшер ителә. Урта сыйныф өчен намус һәм гадәтләр кодексы гамәлдә йөргән. Англиядә ул 1479 елда, Италиядә исә XVI гасыр уртасында басылган. Анда тупас киемнәр һәм тупас сөйләм тәнкыйтьләнгән. 1526 елда бөек галим Эразм Роттердамский яшьләр өчен әдәплелек гадәтләре турында «Ихтирамлылык» дип аталган китап чыгарган.

XV һәм XVI гасырларда этикет буенча чыгарылган үгет-нәсихәтләр балаларны һәм хезмәтчеләрне укыту-өйрәтүгә багышланган. Киң танылу тапкан «Балалар китабы» (1475) сарай каршында хезмәт итәчәк малайларны ашыгып йөрмәскә һәм сөйләмәскә, өстәл астына ризык төшермәскә һәм аш өстәле артында йокламаска, үз хуҗалары киенгәндә ярдәм итәргә, алар тукланганда шәм тотып торырга өйрәткән. Кызларны тыйнаклыкка һәм булачак ирләренә яхшы мөгамәләле булырга, хезмәтчеләрне өстәл әзерләргә һәм кунакларны табынга утыртырга өйрәткәннәр. XVII гасырда Франциянең сарай тормышы атаклы Версальдә тупланган. Король Людовик XIV үзе яраннары өчен сарай тантаналары турында китап язган. Сарайдагы үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә гади шәһәр халкы да иярергә тырышкан. Англиядә пуританлык таралгач, этикетка әхлак нормалары үтеп кергән. XVII–XVIII гасырларда инглиз джентльменыннан гадәти ягымлылыктан тыш тыйнаклык, диндарлык, якыннарының хәленә керә белү, үз вакытларын сарай тормышына гына түгел, ә илгә күбрәк хезмәт итәргә багышлау таләп ителгән. Джентльменны ялкау булмаска һәм үз тормышын алып бару чаралары табу өчен нинди дә булса эш башкаруга өндәү яңа күренеш булган.

Англиядәге индустриаль революция урта сыйныф ролен алга чыгарган. Бу сыйныфның вәкилләре яхшы гадәтләргә аксөякләргә караганда күбрәк игътибар итә башлаганнар.

Королева Виктория заманында респектабельлек — аш өстәле артында нәзакәтле әңгәмәләр һәм хезмәтчеләре белән көндәлек гыйбадәт кылулар идеалга әверелгән. Кием-салымда һәм үз-үзеңне тотудагы тыйнаклык төп таләп булган. Хатын-кызлар косметика файдаланмаганнар, шау-шулы әңгәмәләрдә катнашмаганнар, әхлакка зыян китерерлек романнар укымаганнар. Бу заманда идеаль туташ бик аз ашаган, еш кына аңын җуеп ауган, үзенә караганнарын сизсә кызарган.

Виктория чоры гадәтләре Англиядән АКШка да үтеп кергән. Тыйнаклыкка аерым басым ясалган. Ирләр һәм хатын-кызларның бергәләп үлән өстендә утыруы бик начар күренеш саналган. Хатын-кызларга һәм ирләргә кайчакларда ялангач фигуралар карау өчен аерым-аерым музейларга бару рөхсәт ителгән. XX гасыр башында җәмгыятьнең әхлак нигезләре какшый башлаган. Хатын-кызлар кеше алдында тәмәке тарта башлаганнар. Кинотеатрлар экраннарына җилбәзәк фильмнар чыккан. Яшь буын үзен бик иркен тота башлаган.

Чыганак: Compton's Interactive Encyclopedia. Compton's NewMedia, Inc., 1994.

Билгеле бер этноска яки бөтен кешелеккә хас мәдәни комплекслар бергәлеге мәдәни мирасны тәшкил итә.

МӘДӘНИ МИРАС — узган буыннар тарафыннан тудырылган, вакыт сынавы узып, киләчәк буыннарга бик кыйммәтле һәм кадерле нәрсә буларак тапшырыла торган матди һәм рухи мәдәниятнең бер өлеше.

Кеше кулы һәм акылы тарафыннан тудырылган барлык әйберләр дә бу билгеләмәгә лаек була алмый. Бүгенге мода мәдәни мираска керми, ә элекке мода еш кына музей экспонатлары арасында гына урын ала. Әгәр дә әби-бабайларында модалы булган кием-салымга оныклар кире кайта икән, бу әйберләр мәдәни мирасның бер өлешенә әверелә. Мәдәни мирас еш кына идеаллаштырыла, абруй яулый һәм хөрмәт ителә. Уңай яклары күпертеп күрсәтелә, ә тискәре сыйфатлары киметелә. Нәтиҗәдә мирас милләтне туплау факторына, кризислар һәм тотрыксызлык дәверләрендә берләштерү чарасына әверелә.

Бөтен кешелек масштабында мәдәни мирас *мәдәният универсалийларында* чагылыш таба.

МӘДӘНИЯТ УНИВЕРСАЛИЙЛАРЫ — географик урыннан, тарихи заманнан һәм җәмгыятьнең социаль төзелешеннән бәйсез рәвештә, барлык мәдәниятләргә дә хас нормалар, кыйммәтләр, кагыйдәләр, традицияләр һәм белгеләр.

Алар рәтенә, аерым алганда, спорт, бизәнү-төзәнү әйберләре, календарь, азык әзерләү, карау-тәрбияләү, биюләр, декоратив сәнгать, багу, төш юрау, белем, этика, этикет, могҗизалы сәламәтләнүгә ышану, бәйрәмнәр, фольклор, күмү йолалары, уеннар, ишарәле хәрәкәтләр, сәламләү, кунакчыллык, хуҗалык алып бару, чисталык, шаяртулар, хорафатларга ышану, магия, өйләнешү, ашау вакыты (иртән, көндез, кич), медицина, табигый хаҗәтләрне башкаруда тәрбиялелек, музыка, мифология, шәхси исем, йөкле хатыннарга мөнәсәбәт, бала тапканнан соң тәрбияләү, дини йолалар, җан турындагы өйрәтмәләр, хезмәт коралларын әзерләү, сату-алу, кунакка йөрү, һава торышын күзәтү һ.б. керә.

Мәдәният универсалийлары кешеләр, дөньяның кайсы өлешендә яшәсәләр дә, физик яктан бер үк төрле булганга, бер үк төрле биологик ихтыяҗлары булып, кешелек алдында әйләнәтирә мохит куйган уртак проблемалар белән очрашканга барлыкка киләләр. Кешеләр туалар һәм үләләр, шуңа күрә барлык халыкларда да туу һәм үлем белән бәйле гореф-гадәтләр яши. Аларның бергәләп тормыш алып баруы нәтиҗәсендә кешеләрдә хезмәт бүленеше, биюләр, уеннар, сәламләүләр барлыкка килә.

Төшенчәләр: *мәдәният, мәдәният комплексы, этикет, мәдәни мирас, мәдәният универсалийлары.*

Сораулар һәм биремнәр

1. «Мәдәният» сүзе нинди мәгънәдә кулланыла? Сез ничек уйлыйсыз, көнкүреш мәдәнияте һәм шәхси мәдәният күренешләре нидән гыйбарәт?

2. Мәдәният элементлары нәрсә ул? Ут табу, бүләкләр бирү гадәте, тел, чәч ясау осталыгы, траур аларга керәме? Әллә алар мәдәният комплексларымы?

3. Мәдәният универсалийлары һәм аларның нәрсәгә хезмәт итүе турында сөйләгез.

*4. Рус халкына ишарә хәрәкәтләре, тән бизәү әйберләре, мифология, азык әзерләү кебек универсалийлар хасмы? Алар нәрсәдә чагыла?

5. Мәдәният комплексы нәрсә ул? Көндәлек тормыштан мисаллар китерегез. Мәдәният комплексына компьютер пиратлыгын, фәнне, мәктәптә укуны кертеп буламы?

*6. Мәдәни мирас нәрсә ул? Дәүләт һәм гади гражданнар аны ничек саклыйлар? Гаиләдә мәдәни мирас бармы? Конкрет мисаллар китерегез.

7. Матди һәм матди булмаган мәдәният нәрсә белән аерыла? Театр, авторучка, китап, сәламләү, елмаю, бүләкләр алмашу кайсы төргә карый?

8. Көндәлек тормышта сез таянырга туры килгән этикет нормалары турында сөйләгез.

*9. Этикетка таянуны тормыш өчен мөһим дип уйлыйсызмы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

Проблема. Мәдәни мирас җәмгыятьнең алдагы үсешенә булышамы яки, киресенчә, аны тоткарлыймы?

Практикум. 1. Галимнәр еш кына мәдәниятне әйләнә-тирә мохиткә яраклашу формасы яки нәтиҗәсе буларак карыйлар. Төшенчәләргә карата шундый гади мөнәсәбәт сездә аптырау тудырмыймы? Галимнәрдән без: «Бер якта торган халык этносы, Прокофьев сонаталары, Рафаэльнең Сикстин Мадоннасы һәм азык табу, җылыну, торак төзү, җирдә казыну кебек кырыс һәм бик гади ихтыяҗ арасында нинди уртаклык бар соң?» — дип сорыйбыз. Уртаклык нәрсәдә?

Нигезле итеп җавап бирегез.

2. Түбәндә санап үтелгәннәрнең кайсысы матди, кайсысы рухи мәдәнияткә карый, шуны билгеләгез: дуэль, медаль, карета, теория, бокал, магия, амулет, диспут, револьвер, кунакчыллык, чукындыру, глобус, туй, закон, джинсы, телеграф, святки, карнавал, мәктәп, сумка, курчак, тәгәрмәч, ут.

§18 (§42). Мәдәни нормалар

Без хәзер мәдәни нормалар, яки социаль нормалар дип аталган мәдәният элементларын, үз-үзеңне дөрес һәм тәрбияле тоту үрнәкләрен карап үтәрбез.

Мәдәни нормалар — үз-үзеңне тиешле рәвештә (җәмгыятьчелек тарафыннан яклаган) тотуга карата күрсәтмәләр, таләпләр, теләкләр, өметләр. Нормалар — конкрет очракларда кешеләр нәрсә уйларга, сөйләргә, тоярга тиеш икәнлекне күрсәтүче идеаль үрнәкләр алар.

Кайбер нормалар һәм кагыйдәләр шәхси тормыш белән чикләнә, ә кайберләре бөтен бер җәмгыять тормышын колачлый. Коллективта җәмгыятьнеке шәхсилектән өстенрәк куелганга, шәхси тормыш кагыйдәләре җәмгыятьнекенә караганда бераз йомшаграк, аларның кыйммәте дә азрак. Әлбәттә инде, алар үз статусларын үзгәртмәсәләр һәм җәмгыятьнекенә әверелмәсәләр генә бу шулай була.

Мәсәлән, йөз төсе — һәр кешенең үз эше. Күпчелек цивилизацияле илләрдә бу шулай. Әмма Һиндстанда йөз төсе кешенең социаль урынын билгели. Юлбашчы булып (җитлеккән үсеш фазасында торган борынгы ыруглык җәмгыятьләрендә) бары тик матур һәм шома, тиешле төстәге йөзле кеше генә сайлана ала. Кешенең ораторлык сәләтләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Бер очракта бу һәр кешенең үз эше, башка очракларда ораторлык осталыгы югары сәяси постлар биләргә булыша; борынгы җәмгыятьтә ул сыйфат юлбашчы яки каһин (жрец) урынын алырга уйлаучылар өчен төп таләп итеп куелган. Шуңа күрә, ораторның бу сыйфатына һәм тәртибенә карата катгый нормалар куела.

Мәдәният, губка сыман, тормышның барлык вак-төякләрен (азык әзерләү рецептларыннан башлап һәм йокыга яту йолаларын да кертеп) үзенә сеңдерә. Ул шулкадәр кирәкле нәрсә ки, без мәдәниятне, фатирыбыздагы һава кебек үк, еш кына сизмибез дә. Мәдәният вак-төякләре арасында гадәтләр мөһим урын алып торалар. Яшәү рәвешебез *гадәтләрдән* төзелә.

ГАДӘТЛӘР — билгеле бер хәлләрдә үз-үзеңне тотуның урнашкан схемасы (стериотибы).

Ятып йокларга, беренче ризыкны кашык белән, икенчесен чәнечке белән ашарга, үз артыңнан ишекне ябарга, тиз ватылучан әйберләрне саклык белән куярга — болар барысы һәм башка бик күп нәрсәләр безнең көндәлек тормышыбызны чолгап алган. Бу күмәк, яки төркем гадәтләре безнең тарафтан социальләшү процессында үзләштерелә. Алар бик күп, без аларны берничә нигезсез, үз-үзлегебездән башкарабыз.

Болардан тыш бик күп шәхси гадәтләр дә бар: иртә тору, гимнастика ясау, җылырак киенү, иртән кофе эчү, ач карынга тәмәке тартмау һ.б. Гадәтләр күнекмәләргә нигезләнеп барлыкка киләләр һәм күп тапкырлар кабатлану нәтиҗәсендә берегеп урнашалар. Күпчелек гадәтләр әйләнә-тирәдәгеләрнең

хуплавын да, тәнкыйтьләвен дә тапмый. Әмма шундый зарарлы гадәтләр бар (кычкырып сөйләү, ашаганда уку, тырнак кимерү), алар үз-үзеңне начар тоту рәвеше (манера) турында сөйли.

Үз-үзеңне тоту рәвеше (манера) — *кешенең үз-үзен тотуының гадәтләргә нигезләнгән тышкы формалары.* Аларны кешеләр уңай яки тискәре бәялиләр. Манералар тәрбияле кешеләрне тәрбиясезләрдән, аристократ һәм затлы кешеләрне гади халыктан аера. Гадәтләр үзеннән-үзе үзләштерелә, ә яхшы манераларны тәрбияләргә кирәк.

Манералар бик күп төрле була. Алар югары (затлы) һәм көндәлек манераларга бүленәләр. Ыспай киенеп йөрү, ашаганда авызыңны чапылдатмау һәм газета укымау — тәрбияле кешенең көндәлек манералары. Хатын-кызның кулын үбү, аңа купшы комплементлар әйтү һәм баш киемен бераз күтәрә төшеп исәнләшү — затлы манералар, алар тар даирә кешеләренә генә хас.

Һәр аерым манера мәдәният элементларын яки билгеләрен тәшкил итә, ә бергә алганда, алар үзенчәлекле мәдәният комплексын, **этикетны** төзи. **Этикет** — *аерым социаль даирәләрдә кабул ителгән һәм бербөтенне тәшкил итүче үз-үзеңне тоту кагыйдәләре системасы ул.* Король сарайларында, затлы салоннарда, дипломатик даирәләрдә аерым, үзенчәлекле этикет яшәгән. Этикетка үзенчәлекле манералар, нормалар, церемонияләр һәм ритуаллар керә. Ул җәмгыятьнең югары катлауларын сыйфатлый һәм элитар мәдәният (культура) өлкәсенә кагыла.

Авторитар җәмгыятьтә этикет симметриясез корылган: Борынгы Рим җәмгыятендә үзеңне аффектив тотуның кайбер төрләре (агрессия, явызлык, кызып китү, ачу, ярсу) югары һәм түбән дәрәҗәле кешеләр арасында гына рөхсәт ителгән, ә социаль статуслары буенча тигез булганнар арасында тыелган. Трибун-хуҗа үз колына яки урам сукбаена ярсып кычкыра алган, әмма үзе кебек үк башка трибун янында үзен контрольдә тотарга тиеш булган. Демократик җәмгыятьтә сәяси эшлеклеләр үз тиңнәре белән дә, түбән дәрәҗәлеләр белән дә тупас кыланмыйлар.

Манералардан аермалы буларак, ***гореф-гадәтләр*** (customs) киң масса халыкка хас. **Гореф-гадәт** — *үз-үзеңне тотуның традицион ныгып урнашкан тәртибе, рәвеше.* Ул да гадәтләргә нигезләнгән, әмма индивидуаль түгел, ә күмәк (коллектив)

гадәтләргә карый. Кунакчыллык, Раштуа һәм Яңа елны бәйрәм итү, өлкәннәргә ярдәм күрсәтү һ.б. халыкның күмәк казанышы, кадерле казанышы буларак саклана. Кешеләрне еш кына аларны үтәргә мәҗбүр итәләр. Алар эш-гамәлләрнең гомуми үрнәкләре буларак җәмгыять тарафыннан яклана, аларны үтәү киңәш ителә. Аларны бозучыларга карата рәсми булмаган санкцияләр (мәсәлән, хупламау, изоляцияләү, шелтәләү), чаралар кулланыла.

Әгәр дә гадәтләр һәм гореф-гадәтләр бер буыннан икенче буынга күчсә, алар **традициягә** әверелә. Башта бу сүз «риваять» мәгънәсен белдергән. **Традиция** — *алдагы буыннардан мирас булып калган нәрсәләр ул.* Кыйммәтләр, нормалар, үз-үзеңне тоту үрнәкләре, идеяләр, җәмгыятьтә кабул ителгән гадәтләр, зәвык һәм карашлар шулай ук традиция сыйфатында карала. Сабакташлар, полкташлар очрашуы, милли һәм корабль флагын күтәрү дә традицион әһәмият алырга мөмкин. Кайбер традицияләр гадәти шартларда, ә кайберләре бәйрәмнәрдә, тантаналы шартларда башкарыла. Алар мәдәни мираска карый, хөрмәт ителә, берләштерү башлангычы булып хезмәт итә. Аргентинада шундый традиция яши: Яңа елда чиновниклар, иске документларны ертып, үз оешмалары тәрәзәләреннән аларны үтеп баручылар өстенә сибәләр. Шуның белән алар, символик рәвештә, яңа башлангычлар өчен юл чистарталар.

Кеше традицияләрне һәм гореф-гадәтләрне үз ихтыярына һәм теләгенә карамыйча үзләштерә. Монда сайлау иреге юк. Мәдәниятнең зәвык, мавыгу һәм мода кебек элементлары кешенең ирекле рәвештә сайлый алу мөмкинлеген күрсәтә.

Зәвык — *нәрсәгә дә булса хирыслык яки тартылу, күп очракта бу матурлыкны аңлау, яки матурлыкны тану хисе.* Кием зәвыгы индивидуаль стильне, киенү рәвешен (манерасын) формалаштыра. Зәвык индивидуаль нәрсә, шуңа күрә ул кешенең гомуми нормалардан, уртача стандартлардан күпмегә авышканлыгын күрсәтә.

Мавыгу — *кыска вакытлы эмоциональ омтылыш.* Һәр буынның үз мавыгулары була: тар чалбар, джаз музыкасы, киң галстук һ. б. Зур төркемнәрне чолгап алган мавыгулар алмашуын *мода* дип атыйлар.

Нәрсәнеңдер һәм кемнеңдер тиз генә килгән популярлыгын да мода дип атыйлар. Бу «нәрсәләрдер», гадәттә, киемгә, ризыкка һәм үз-үзеңне тотуга карата ниндидер нормаларны

белдерә. Әгәр дә кешенең зәвыгы гомере буена сакланса, мавыгулар исә һаман алышынып тора. Мавыгулар барлык массаларны чолгап ала, алар модага үсеп әверелә.

Мода, иң беренче чиратта, Яңа заманга хас билге. Ул җәмгыятькә революцион үзгәртеп корулар алып килде. Әгәр дә традицион җәмгыятьтә кием һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләре вертикаль буенча — олылардан кечеләргә тапшырылып килсә, хәзерге җәмгыятьтә исә горизонталь буенча — яшүсмерләрнең бер төркеменнән икенчесенә күчә.

Хәзерге мода индустриясе адресаты — яшьләр һәм төрле яшьләрдәге бай кешеләр. Алдынгы, бигрәк тә мода чыгаручы дип исәпләнүче илләрдә (мәсәлән, Франциядә) бу индустрия әйләнеше фантастик колач ала. Мода индустриясенең еллык әйләнеше 25 млрд. долларга җитә.

Техниканың һәр яңа буыны кешелек алдында яңа мөмкинлекләр ача, димәк, яңа максатлар, идеаллар, өметләр уята, мода стильләре һәм юнәлешләре китереп чыгара. Агач гитараны кысрыклаган электр гитарасы технологик үзгәреш кенә булып калмый. Аның белән яшьләр субкультурасында яңа эпоха башлана. Бары тик компьютерлар өлкәсендә генә дә соңгы 20 ел эчендә яшь фанатларның берничә буыны исәпләнә, алар төрле телләрдә сөйләшәләр, төрле максатларга һәм тормыш приоритетларына ышаналар, төрле һөнәр һәм тормыш күнекмәләренә ия булалар. Алар арасындагы аерма гаять зур. ЭВМчылар буыны виртуаль компьютер чынбарлыгының хәзерге буыны тарафдарларын берничек аңлый алмыйлар. Барлык өлкәләрдә дә шундый ук хәл күзәтелә.

Техник прогресс тизләнеше белән техник мода алышынуы цикллары да бик күпкә кыскарды. Теге яки бу технологик яңалыкларга мода бары тик ике-өч ел гына саклана. Үзәктә — алдынгы илләрдә барлыкка килгән яңалыклар, хәзерге заман коммуникацияләре ярдәмендә бик тиз арада дөньяның ерак илләренә дә килеп җитә. Кыска гына вакыт эчендә алмашка яңа мавыгу килә. Мондый узышуга бары тик яшьләр генә сәләтле.

Модалы әйберләр гади киемнәрдән кыйбатрак тора, аларны алу уңыш буларак бәяләнә. Мода күбесенчә шәһәрләрдә киң тарала, анда кешенең статусы һәм дәрәҗәсе аның һөнәреннән һәм холкыннан гына түгел, ә тормыш стиленнән, байлык дәрәҗәсеннән, киенү рәвешеннән һ.б. да бәйле.

Йола — традициянең бер төре. Ул аерым сайланган гамәлләрне түгел, ә гореф-гадәт яки ритуал белән билгеләнгән массакүләм чынбарлыкны характерлый. Аларда ниндидер дини күзаллаулар яки көнкүреш традицияләре чагылыш таба. Йолалар бер социаль төркем белән генә чикләнмиләр, халыкның барлык катлауларын колачлыйлар. Алар кеше тормышының туу (балага исем кушу, чукындыру), туй (яучылык, кәләшне сатып алу, ярәшү), яңа төр эшчәнлек башлау (хәрби ант), гомернең башка өлешенә күчү (инициация), үлем (җирләү, мәет ашларын үткәрү) кебек мөһим мизгелләрендә катнаша.

Йолалар дин өлкәсендә таралыш алганнар дип уйлау дөрес булмас иде. Символик эш-гамәлләр кешелек культурасының барлык өлкәләрен дә колачлый.

Церемония — *символик мәгънәгә ия булган һәм нинди дә булса вакыйгаларны яки даталарны бәйрәм итүгә багышланган эш-гамәлләр эзлеклелеге.* Ул билгеләп үтелгән вакыйгаларның җәмгыять яки төркем өчен аеруча кыйммәтле, кадерле булуын күрсәтә. Президентның үз вазифаларына керешүе — җәмгыять өчен мөһим булган церемониянең ачык мисалы.

Ритуал — *нык стильләштерелгән* һәм *җентекләп планлаштырылган ишарәләр һәм сүзләр җыелмасы, аларны башкаручыларны махсус рәвештә сайлап алалар һәм әзерлиләр.* Ритуал символик мәгънәгә ия. Ул билгеле бер вакыйганы дулкынландыргыч итәргә, тамашачылар күңелендә тетрәнү уятырга тиеш. Кешене мәҗүси аллага корбан итеп китерү —ритуалның ачык мисалы.

Үрнәк гадәтләр (нравы) — *җәмгыятьтә аеруча сакланучы, бик нык хөрмәт ителүче күмәк эш-гамәл үрнәкләре.* Үрнәк гадәтләр — тыныч, мул тормышлы җәмгыять турындагы фәлсәфи һәм этик фикерләрне үз эченә алган гореф-гадәтләр алар, әгәр кешеләр бу гореф-гадәтләрне үтәсәләр, андый җәмгыять, һичшиксез, булачак.

Үрнәк гадәтләр җәмгыятьнең әхлак (мораль) кыйммәтләрен чагылдыра. (Латин сүзе moralis «әхлакый» мәгънәсен аңлата.) Аларны бозу традицияләрне бозуга караганда зуррак гаеп буларак бәяләнә. Әхлак җәмгыять тормышының мөһим өлкәләре нигезенә салынган этик нормаларны, рухи принципларны билгели.

Җәмгыять әхлагы — игълан ителгән нормалар белән чагыштырып, нәрсәнең дөрес, ә нәрсәнең дөрес булмавын билгеләүче күрсәтмәләр. Үрнәк гадәтләр әхлакый әһәмияткә ия. Кешеләрнең шушы җәмгыятьтә кабул ителгән үз-үзләрен тоту формалары әлеге категориягә керә; аларга әхлакый яктан бәя бирелергә мөмкин. Борынгы Римда бу төшенчә «иң хөрмәтле һәм иң изге гореф-гадәтләр» дигән мәгънәне аңлаткан. Күп җәмгыятьләрдә урамда шәрә йөрү әхлаксызлык дип санала (гәрчә өйдә болай йөрү мөмкин булса да), өлкәннәрне рәнҗетү, хатын-кызга кул күтәрү, юашларны кыерсыту, гарип кешеләрне мыскыл итү дә әхлаксызлык була.

Үрнәк гадәтләр җәмгыять традицияләренә нигезләнә һәм бәхәссез абруйга ия. Алар күпчелек тарафыннан шик астына алынмый һәм тәнкыйтьләнми, гәрчә кайбер тикшеренүчеләр, мәсәлән, теге яки бу үрнәк гадәтләрнең тарихи хаклыгы турында шик белдерәләр. Үрнәк гадәтләр нигезле, консерватив, аз санлы. Аларның төп вазифасы үз-үзеңне тоту үрнәкләрен мөмкин кадәр озаграк үзгәрешсез хәлдә саклаудан гыйбарәт.

Үрнәк гадәтләрнең бер өлеше изге кыйммәтләр булып әверелә. Дини кануннар әнә шундыйлар рәтеннән. Алар Ходай абруена нигезләнә. Башка үрнәк гадәтләр дин өлкәсенә карамасалар да, шулай ук диндәге изге васыятьләргә барып тоташалар (мәсәлән, нәселдәге өлкәннәрне хөрмәт итү).

Законнар үрнәк гадәтләрнең бер төре булып торалар. Алар — парламент яки хөкүмәт документы белән рәсмиләштерелгән, икенче төрле әйткәндә, дәүләтнең сәяси абруе тарафыннан беркетелгән үз-үзеңне тоту нормалары яки кагыйдәләре, аларны тайпылышсыз үтәү таләп итәлә.

Гади хокук — индустриаль булмаган җәмгыятьтә үз-үзеңне тотуның дәүләт тарафыннан рөхсәт ителгән, язылмаган кагыйдәләр җыелмасы. Гади хокук илнең төп законы — Конституциядә беркетелгән рәсми, яки *юридик законнарга* әверелә. Законнарны бозучы төрле дәрәҗәдәге җинаять җаваплылыгына тартыла. Җәмгыять законнар белән кеше тормышын, дәүләт серен, кеше хокукларын һәм абруен, милкен саклый.

Мәдәни һәм социаль нормаларның үтәлеше санкцияләр белән көйләнә.

Санкцияләр — *кешеләрне социаль нормаларны үтәүгә этәрүче кызыксындыру яки җавапка тарту чаралары.* Җәмгыятьтә теге яки бу дәрәҗәдә бәяләнгән нәрсәләр күрсәтмәләр теленә

күчерелә. Кеше тормышы һәм абруе, өлкәннәргә мөнәсәбәт, күмәк символлар (мәсәлән, байрак, герб, гимн), дини йолалар, дәүләт законнары һ.б. бик күп нәрсәләр кешеләр бергәлеген туплый, бердәм итә, шуңа күрә аеруча саклана да. Кыйммәтләр һәм нормалар — мәдәният элементлары. Хәтта киң таралган гигиена таләпләрен үтәү дә җәмгыять тарафыннан күрсәтмәләр теленә күчерелә.

Күпмедер дәрәҗәдә нормаларга буйсынмау теләсә кайсы җәмгыятьтә һәм теләсә кайсы төркемдә күзәтелә. Сарай этикетын, дипломатик әңгәмә яки никахлашу ритуалын бозу уңайсызлык китереп чыгара, кешене кыен хәлгә куя. Әмма аның өчен кырыс җавапка тарту каралмаган.

Башка очракларда җитдирәк санкцияләр кулланыла. Имтихан вакытында шпаргалкадан файдалану куеласы билгене киметүгә китерә, ә китапханә китабын югалту өчен штрафка тарталар. Кайбер җәмгыятьләрдә традицияләрдән аз гына булса да читләшкән өчен кырыс җәза бирелгән (җитди гаеп эшләр өчен инде әйтеп торасы да юк). Бар нәрсә дә (чәч озынлыгы, кием рәвеше, үз-үзеңне тоту рәвешләре) контроль астына алынган. Б. э. к. V гасырда борынгы Спарта идарәчеләре һәм XX гасырда совет партия органнары нәкъ шулай эшләгән.

Мәдәният нормаларының асылы хупланган адымнарны рөхсәт итү генә түгел, ә хупланмаган эш-гамәлләр кылуны тыюдан да гыйбарәт. Кайвакыт бер диндә тыелган нәрсә икенчесендә рөхсәт ителә. Мәсәлән, шәригать кануннары мөселман ир-атларга алтын киюне тыя, ә христианнарга бу рөхсәт ителә.

Төшенчәләр: *мәдәният нормалары, манералар, гореф-гадәтләр, традицияләр, гадәтләр, мода, үрнәк гадәтләр, мораль, гади хокук, санкцияләр.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәдәният нормасы нәрсә ул? Мисаллар китерегез.

2. Традицияләр гореф-гадәтләрдән нәрсә белән аерыла? Үз әйләнә-тирәгезне күзәтегез, аларга нинди мисаллар таба аласыз?

*3. Тикшерү предметы — гадәтләр, күзәтү объекты — сезнең гаилә һәм сез үзегез. Көн саен үзегезнең һәм якыннарыгызның үзләрен ничек тотуын күзәтегез. 15–20 ләп индивидуаль һәм коллектив гадәтләр исемлеген төзегез.

*4. Мода һәм мавыгулар — сезнең өчен иң таныш нәрсәләр. Сезнең якыннарыгызның һәм танышларыгызның үз-үзләрен тотышына мода ничек йогынты ясый? «Модалы кеше» гыйбарәсен

аңлатыгыз. Уйлагыз, җәмгыять тормышында мода нинди күренешләр белән бәйләнгән?

5. Йола, ритуал, церемония нәрсә ул? Алар турында сез нәрсә беләсез? Аларны башкару мәҗбүриме?

6. Безнең тормышта зур роль уйнаучы үрнәк гадәтләр турында сөйләгез.

7. Санкцияләр нәрсәгә хезмәт итә һәм ничек кулланыла?

*8. Мәдәни нормаларны үтәмәү нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

? Проблема. Начар гадәтләр белән, сезнеңчә, ничек нәтиҗәлерәк итеп көрәшеп була? Алар белән көрәшү кирәкме?

Практикум. «Икеле»гә укучыга таблицаны төзәтергә ярдәм итегез. Анда терминнар һәм аларның билгеләмәләре китерелгән, әмма аларның урыннары буталган.

Йола	кешеләрне социаль нормаларны үтәргә этәрүче кызыксындыру яки җавапка тарту чаралары
Церемония	җәмгыятьтә аеруча сакланучы, бик нык хөрмәт ителүче күмәк эш-гамәлләр үрнәкләре
Ритуал	нык стильләштерелгән һәм җентекләп планлаштырылган ишарәләр һәм сүзләр җыелмасы, аларны башкаручыларны махсус рәвештә сайлап алалар һәм әзерлиләр
Үрнәк гадәтләр	символик мәгънәгә ия булган һәм нинди дә булса вакыйгаларны һәм даталарны бәйрәм итүгә багышланган эш-гамәлләр эзлеклелеге
Санкцияләр	гореф-гадәт яки ритуал белән билгеләнгән барлык эш-гамәлләр

§ 19 (§ 43). Мәдәният формалары

Мәдәниятне кем тудыруына һәм нинди дәрәҗәдә булуына карап, аның өч формасын аералар:

— ***элитар мәдәният,***

— ***халык мәдәнияте,***

— ***массакүләм мәдәният.***

Шулай ук аның ике төрен билгелиләр: ***субкультура*** һәм ***контркультура***.

Салон музыкасы — элитар мәдәниятнең бер төре

Элитар яки югары мәдәният җәмгыятьнең өстен катлавы яки аның кушуы буенча профессиональ иҗатчылар тарафыннан тудырыла. Аның девизы — «Сәнгать сәнгать өчен». Аңа нәфис сәнгать, классик музыка һәм әдәбият керә. Югары җәмгыять сәнгатен һәм салон музыкасын аның бер төре дип әйтергә мөмкин.

Югары мәдәният, мәсәлән, испан рәссамы П. Пикассо эшләре яки Австрия композиторы А. Шёнберг музыкасы әзерлексез кешегә кыен аңлашыла. Кагыйдә буларак, ул уртача әзерлекле кешенең аңлау, кабул итү дәрәҗәсен дистә елларга узып китә. Аның тарафдарлары — югары белемле кешеләр — тәнкыйтьчеләр, әдәбиять белгечләре, музей, күргәзмәләр, театр сөючеләр, рәссамнар, язучылар, музыкантлар. Халыкның белем дәрәҗәсе үскәндә, югары мәдәният тарафдарларының даирәсе дә киңәя.

Элитар мәдәнияттән аермалы буларак, халык мәдәнияте профессиональ әзерлексез, исемнәре билгеле булмаган иҗатчылар тарафыннан тудырыла. Халык мәдәниятен һәвәскәр (дәрәҗәсе белән түгел, ә чыгышы белән) яки күмәк мәдәният дип атыйлар. Аңа мифлар, легендалар, хикәяләр, эпослар, әкиятләр, җырлар

Халык мәдәнияте профессиональ әзерлексез, исемнәре билгеле булмаган иҗатчылар тарафыннан тудырыла

һәм биюләр керә. Халык мәдәнияте элементлары башкарылу буенча индивидуаль (легенда сөйләү), күмәк (бию һәм җыр башкару), массакүләм (карнавал тантаналарында йөрү) булырга мөмкин. *Фольклор* — халык иҗатының тагын бер атамасы, ул да халыкның төрле катлаулары тарафыннан тудырыла. Фольклор локальләшкән була, ул урын традицияләре белән бәйләнгән һәм демократик, чөнки аны иҗат итүдә һәркем катнаша ала.

Массакүләм яки *һәркемгә аңлаешлы* мәдәният аристократиянең нечкә зәвыгын яки халыкның рухи эзләнүләрен чагылдырмый. Ул XX гасыр уртасында, массакүләм мәгълүмат чаралары (радио, матбугат, телевидение, грамъязмалар, магнитофон) күпчелек илләргә үтеп кергәч һәм бөтен социаль катлаулар вәкилләренә дә барып җиткәннән соң барлыкка килде. Массакүләм мәдәният интернациональ яки милли булырга мөмкин. Популяр һәм эстрада музыкасы — массакүләм мәдәниятнең ачык мисаллары. Ул аңлашыла, халыкның белем дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, барлык катлауларга һәм төрле яшьтәгеләр күңеленә дә барып җитә.

Массакүләм мәдәният, кагыйдә буларак, элитар яки халык мәдәниятенә караганда иҗади яктан азрак кыйммәткә ия. Әмма ул иң киң аудиторияне колачлый һәм аның тәгаен авторлары була. Ул кешеләрнең хәзерге мизгелдәге ихтыяҗларын канәгатьләндерә, теләсә кайсы яңа вакыйгага игътибар итә һәм

аны чагылдыра да. Шуңа күрә массакүләм мәдәният үрнәкләре, аерым алганда шлягерлар, бик тиз актуальлекләрен югалталар, искерәләр, модадан чыгалар. Элитар һәм халык мәдәнияте әсәрләре белән мондый хәл булмый. *Поп-мәдәният* — массакүләм мәдәниятнең сленг атамасы, ә *китч* — аның бер төре.

Д. Карышев. Массакүләм мәдәният гримасалары

Тамга салынган коллар, татуировка төшерелгән җинаятьчеләр, авызлары кискәләнгән һәм яңакларында җөй эзләре калган фахишәләр, борын яфракларына боҗралар эленгән буйволлар һәм баштанаяк алтын алкалар тагылган Африка юлбашчылары — болар барысы гасырлар чигендә читкә кагылганнар атрибутикасыннан хәзерге сәнгать төренә әверелә. Сәнгатьнең боди-арт дип аталган бу төре үз тәнең өстендә экспериментлар ясауны гәүдәләндерә. Һаман булган, әмма җәмгыять тарафыннан яшеренергә мәҗбүр ителгән татуировка бүген модага керде һәм гадәти күренешкә әверелде.

Блатнойлар жаргонында — «прошивка», «регалка», «наколка», ә гади сөйләмдә исә — татуировка. Әгәр дә филологлар әйтүенә ышансак, бу сүз безгә ерак Таити утравыннан килгән. «Та» — «сурәт» мәгънәсен, «ату» рух мәгънәсен белдерә. Һәр сурәт аны ясаткан кеше турында билгеле бер мәгълүмат җиткерә. Мәсәлән, кулындагы тюльпан рәсеме бу кешенең 16 яшен рәшәткә артында билгеләп үтүен аңлата. Явыз гладиатор сурәте бу кешенең садизмга һәм явыз хулиганлыкка сәләтле булуын күрсәтә. Ә менә уч төбенә чиркәү төшерелгән, ди. Аның гөмбәзләр саны буенча, ә алар бишәү, кешенең ничә тапкыр хөкем ителүен яки төрмәдә утыру вакытын белергә мөмкин. Сабый белән бергә төшерелгән Мадонна сурәте «төрмә баласы» дип аңлатыла. Һәм бу сурәтләргә кеше үзеннән берни дә өсти алмый, һәр регалка өчен аның хуҗасы үзе җавап бирә.

Тату-салоннарда, заман техникасы ярдәмендә, үз тәнеңә өстәмә «концептуаль» мәгънә биреп, төрле сурәтләр төшерергә була. Сигарет кабы кадәр бизәк төшергән өчен дә 50 доллар түләргә кирәк.

Мондый сурәт төшерүләр ир-атларны гына җәлеп итмәгән. Әгәр дә элек татуировка төшерелгән гәүдәләре белән фахишәләр һәм җинаять дөньясы хатын-кызлары гына «мактана» алса, хәзер исә яшь кыз балалар да пляжда «бизәлгән» кендекләрен, тубык сөяге һәм муеннарын күрсәтеп фыртланып йөриләр.

Пирсинг — инде үтә «текә»ләр шөгыле. Безнең илдә әлегә киң колач җәймәгән бу күренеш Көнбатышта 90 нчы еллар

«чирена» әверелде. Профессиональ пирсингерлар раславынча, тәнне тишү — бик «йогышлы» шөгыль. Бер, ике тишек ясаткан кеше инде аларның санын арттырудан туктап кала алмый.

Бу эштә дә, башкаларындагы кебек үк, четерекле яклар җитәрлек. Җитди кеше борын яфракларына, күз кабакларына, теленә, күкрәк башларына алтын әйберләр элмәячәк. Затлы металл пирсинг дөньясында вак-төяк, кирәкмәс нәрсә дәрәҗәсенә төшерелгән. Алкалар өчен файдаланылучы металлардан беренче урында махсус медицина корычы тора. Мондый бизәнү әйберен профессиональ салонда беркетү 70 долларга төшә.

Пирсингны массакүләм мәдәнияткә кертеп җибәрүдә күпләр «Aerosmith» төркеменең «Crying» видеороликгын иң беренче урынга куя. Борынына һәм кендегенә тишеп алка беркеткән яшь кыз бик күп яшүсмерләр күңеленә хуш килә, һәм хәзер аларның һәр бишенчесе күпсанлы алкалар йөртүчегә әверелә.

Монда да татуировкалар белән охшаш үзенчәлек күзәтелә. Колагыңда нәрсә түгел, ә аның ничәү булуы мөһимрәк икән. Телеңә беркетелгән тимер белән ашавы сиңа уңайлымы, юкмы анысы бөтенләй исәпкә алынмый. Сәнгать корбаннар таләп итә, шуңа күрә түзәргә туры килә. Аеруча нечкә урыннардагы яра (иреннәр, тел, күкрәк башлары, җенси органнар) берничә ай дәвамында төзәлә. Кечкенә генә пычрак керсә дә, ялкынсыну башланырга мөмкин.

Скарт — җөйләр төшерү сәнгате. Хәзер үткән заманнар трагедиясе герое, җөйләр белән яргаланып беткән чырайлы егет үзен иң текә кеше дип исәпли ала. Йөзгә төшерелгән җөйләр өчен хәзер зур акчалар түлиләр. Һәм монда да авырту һәм курку хисе — һичшиксез булырга тиешле атрибут.

Скарт төшерүче профессионаллар моның белән өй шартларында шөгыльләнергә киңәш итмиләр. Монда да, ничек кенә булмасын, оста кулы таләп ителә. Өстәвенә, алар фикеренчә, скарт — бик азлар, сайланганнар сәнгате. Чыннан да, останың кулына кыскычлар алып, алар белән махсус металл пластинканы кыстыруын, аннары баллоннан бөркелүче ут астында аны кыздыруын һәм аны яңа юылган, стерильләштерелгән тәнгә китерүен күрүчеләрнең бик азы гына эшнең ахырына кадәр утыра ала... Тагын бер ысул бар — тирене зур һәм үткен пычак белән кисү. Кан саркыган яраларны антисептик сыекча белән эшкәртәләр. Җөйләр бик яхшы күренә торган урыннар — яңаклар, күкрәкнең югары өлеше, куллар һәм кайчакта — арка.

Чыганак: АиФ.— 1996.— №13.

Мәдәниятнең төп формалары *Таблица*

Мәдәният формалары	Тану билгеләре	Аларны өйрәнүче фәннәр
Элитар (югары) мәдәният	Рәсем сәнгате, скульптура, архитектура, әдәбият, икона төшерү, мозаика, музыка	Сәнгать белемс, әдәбият белеме
Халык мәдәнияте	Эпос, былина, хикәят, әкият, ритуал, йола, гореф-гадәт	Этнография, атропология, фольклористика
Массакүләм мәдәният	Эстрада, шлягер, китч, сленг, цирк, кино, радио, телевидение	Социология, философия

Җәмгыятьнең күпчелек әгъзалары таянган кыйммәтләр, ышанулар, традицияләр һәм гореф-гадәтләр барысы бергә өстенлек итүче мәдәният **(доминирущая культура)** *дип атала.*

Җәмгыять төрле (милли, демографик, социаль, профессиональ) төркемнәргә бүленү сәбәпле, аларның һәрберсенең үз мәдәнияте, ягъни кыйммәтләре һәм үз-үзләрен тоту кагыйдәләре системасы формалаша. Кече мәдәният дөньяларын *субкультуралар* дип атыйлар.

Субкультура — *гомуми мәдәниятнең бер өлеше, зур социаль төркемнәргә хас булган кыйммәтләр, традицияләр, гореф-гадәтләр системасы.*

Бер телдә берничә диалект була. Төрле диалектларда сөйләшүче төркемнәр — субкультуралар, төрле телләрдә сөйләшүче төркемнәр — төрле мәдәниятләр алар. Ике төркем кешеләре, яшәү рәвеше детальләренең бертөрле булмавына карамастан, гомуми нигез кыйммәтләрне уртаклашалар һәм шуңа күрә берниндн киртәләрсез аралаша алалар, аларның мәдәниятләре — бер төп мәдәниятнең вариантлары гына. Роман телләре тартыкларның һәм сузыкларның саны үзгәрү нәтиҗәсендә латин теленнән килеп чыкканнар. Алар — яңа телләр, ә диалектлар түгел. Ул телләрдә сөйләшүчеләр төрле мәдәниятләргә карыйлар, субкультура түгелләр.

Субкультураларның берничә төре бар: яшьләрнеке, өлкәннәрнеке, милли азчылыкныкы, профессиональ, криминаль һ.б. Субкультура гомуми мәдәнияттән тел, тормышка караш, үз-үзеңне тоту рәвеше, чәч, кием һәм гореф-гадәтләр белән

аерылып тора. Аермалар гаять зур булырга мөмкин, әмма субкультура гомуми мәдәнияткә каршы тормый. Наркоманнарның, чукрак-телсезләрнең, бомжларның, эчкечеләрнең, спортчыларның, ялгыз кешеләрнең үз мәдәниятләре бар. Аксөякләрнең, урта сыйныф вәкилләренең балалары үз-үзләрен тотышлары белән түбән сыйныф балаларыннан аерыла. Алар төрле китаплар укыйлар, төрле мәктәпләргә йөриләр, төрле идеалларга юнәлеш тоталар. Һәр буынның һәм һәр социаль төркемнең үз мәдәни дөньясы була.

Даими рәвештә ишек алдында аралашучы сабый балалар үзләренә генә аңлаешлы үзенчәлекле субкультура тудыралар.

Яшьләр һәм *яшьләр мәдәнияте* — чагыштырмача яңа күренешләр. Мөстәкыйль буларак, алар XX гасырның 50 нче елларында алдынгы илләрдә, аерым алганда, АКШта барлыкка киләләр.

Гомумән, 50 нче еллар урталарына кадәр «тинэйджерлар» (яшүсмерләр) төшенчәсе булмый. 40 нчы елларда үсмерләр өлкәннәр алган әйберләрне сатып алдылар. Алар әти-әниләре йөргән клубларга биергә йөрделәр, уртак җырчыларга табындылар һәм бер ук төрле киенә иделәр.

Һәм бервакыт кемдер, үсмерләрнең акчалары аз булса да, бу акчаларның барысының да буш вакытларны үткәрүгә китүен төшенеп ала. Алар заманча модага нигезләнгән ял вакыты мәдәниятен булдыруга алыналар. Дөньяга коммерциячел караш әнә шулай барлыкка килә. Яшьләр күбрәк һәм төрлерәк әйберләр алырга тырышалар, алар бу әйберләрне үзләренә бик кирәк булганга түгел, ә башкалардан аерылып тору өчен алалар. Яшьләрнең барлык энергиясе социаль протест әзерләүгә түгел, ә чираттагы «модалы әйбер» артыннан кууга сарыф ителә башлый. Яшьләр субкультурасының социаль функциясен тинэйджерларның үз-үзләрен тотышын контрольдә тотуның өстәмә чарасына әверелүендә күрәләр.

30 нчы елларда ук инде кинематограф һәм грамъязма Көнбатыштагы алдынгы илләрдә чәчәк атучы бизнеска, мөстәкыйль һәм эзлекле рәвештә көч туплаучы индустриягә әверелә. Массакүләм радиотапшырулар үсеше дә шушы чорга карый. Россиягә цивилизациянең бу казанышлары бераз соңарып килә.

50 нче еллар уртасында хәзерге җәмгыятьтә радикаль үзгәрешләр башлана. Тарих сәхнәсенә иң зур аудиторияне тәшкил итүче яңа социаль категория — яшьләр чыга. Көнбатышта

эшмәкәрләр, җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне бик тиз сизеп алып, арзан грампластинкалар, магнитофоннар һәм магнитофон кассеталары чыгаралар, ә радио һәм телекомпания хуҗалары — махсус яшьләр программалары әзерләүгә, ә киңрәк колачта алганда, махсус *шоу-бизнес* оештырырга керешәләр. Ул вакытта өлкәннәрнең ял итү, күңел ачу базары инде югары тәэмин ителү дәрәҗәсенә җиткән булса, яшь гражданнарның даими төстә матди хәле яхшыру сәбәпле, яшьләр базарында киң перспективалар ачыла.

50 нче еллар уртасында яшьләр мәдәнияте шаукымы башлангач, массакүләм мәдәният продукциясен беренчеләрдән булып эшчеләр куллана башлыйлар. Мәшһүр «Битлз» эшчеләр арасыннан үсеп чыга. Урта сыйныф вәкилләре яшьләр мәдәниятенә соңрак тартылалар, чөнки аларның колледжларда һәм университетларда озаграк укулары сәбәпле, үз акчалары әлегә булмый. Киресенчә, эшчеләрнең балалары мәктәпне иртәрәк тәмамлыйлар, иртәрәк эшли башлыйлар һәм икътисади яктан да иртәрәк мөстәкыйльлек алалар.

Заман яшьләренең күпчелек өлешендә *ял* һәм *буш вакыт* тормыш рәвешенең төп формасына әверелә, алар мөһим ихтыяҗ булган хезмәтне кысрыклап чыгаралар. Гомумән, тормыштан канәгатьлелек хәзер ял вакыты белән канәгать булуга бәйле. Яшьләр субкультурасында үз-үзеңне культуралы тоту нәзберeклеге юк, анда стереотиплар һәм конформизм (килешүчәнлек) өстенлек итә. Яшьләр субкультурасының үз теле, модасы, сәнгате һәм үз-үзеңне тоту стиле бар. Ул торган саен күбрәк формаль булмаган мәдәнияткә әверелә бара, формаль булмаган яшүсмерләр (неформаллар) төркемнәре аның тарафдарлары рәтендә торалар.

1989 ел ахырында Н. В. Кофырин формаль булмаган яшьләр төркемнәрен өйрәнә. Алар яшәү урыннарында оешалар: анда катнашучыларның 70%ын егетләр, ә 30%ын кызлар тәшкил итә. Аларны бу төркемнәргә китәргә эчке ялгызлык, дуслар табу ихтыяҗы, мәктәптәге һәм гаиләдәге конфликтлар, өлкәннәргә ышанмау, ялганга каршылык хисе этәрә. Һәр сигезенче бала «алга таба ничек яшәргә икәнен белмәгәнгә» төркемгә керә. Яшьләр субкультурасы күп очракта суррогат характерда була, ул чынбарлыктагы кыйммәтләрне аларның ясалма төрләре белән алыштыра: ялган мөстәкыйльлек рәвешендәге озайтылган укучылык чоры, көчле шәхесләрнең өстенлеге һәм

хакимлеге системасына корылган өлкәннәр мөнәсәбәтләренә ияру, үз омтылышларын тормышка ашыру урынына экран һәм әдәбият геройлары мажараларында катнашабыз дип уйлау, ниһаять, социаль чынбарлыкны үзгәртеп кору һәм камилләштерү урынына нәфрәт яки аннан качу. Чынбарлыктан качу, яки *эскапизм* ысулларының берсе — наркотиклар куллану.

Яшьләр субкультурасы балалар, өлкәннәр яки картлар субкультурасыннан кискен аерыла. Әмма ул үз эчендә дә бертөрле генә түгел. Кайсы сыйныфтан булу иң беренче һәм күренеп торган билгеләрнең берсе. Социологлар билгеләгәнчә, югары, урта, түбән сыйныф яшьләре барлык илләрдә дә үзләренең киенү рәвеше, буш вакытларын үткәрү һәм яшәү рәвеше белән аерылып торалар. Өстәвенә, ак һәм кара тәнлеләр субкультурасында да шактый аерма күзәтелә.

Теге яки бу субкультураны сыйфатлаучы үзгә билгеләр барысы бергә стиль дип атала. Стиль — киенү, үз-үзеңне тоту, сөйләшү, музыка тыңлау рәвеше, күңелгә якын нәрсәләрне аңлата белү ысулының суммар характеристикасы ул. Стиль бер төркемнең икенчесеннән үзгә булуын күрсәтә.

Контркультура гомуми мәдәнияттән үзгә булган гына түгел, ә аңа каршы торган һәм төп кыйммәтләр белән конфликтта булган субкультураны белдерә. 60 нчы елларда яшьләрнең хиппи хәрәкәте Америкадагы төп кыйммәтләрне (тырыш хезмәт, матди уңыш һәм табыш, конформизм, сексуаль тотнаклылык, сәяси лояльлек, рациональлек) инкяр итә.

Төшенчәләр: *элитар мәдәният, халык мәдәнияте, массакүләм мәдәният, субкультура, контркультура.*

Сораулар һәм биремнәр

1. «Халык мәдәнияте» төшенчәсенең эчтәлеген ачыгыз.

2. Элитар мәдәният нинди элементлардан гыйбарәт һәм ул ничек иҗат ителә? П. Пикассо картиналарын, И. Бах музыкасын һәм У.Шекспирның сәхнәләштерелгән әсәрләрен элитар мәдәнияткә кертергә мөмкинме?

3. Массакүләм мәдәният кайчан һәм нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килгән? Көндәлек тормышта сез аның белән очрашасызмы?

*4. Массакүләм мәдәният, сезнең карашка, җәмгыятькә ничек йогынты ясый?

5. Яшьләр мәдәнияте ни рәвешле чагылыш таба?

*6. Аңлатыгыз, яшьләр сленгы ни өчен кулланыла?

7. Субкультура һәм контркультура нәрсә белән аерыла?

*8. Мәдәниятнең төрле формалары бер-берсе белән бәйләнәме? Ничек итеп?

Проблема. Формаль булмаган яшьләр төркемнәре яшүсмерләр проблемаларын хәл итүдә булышамы?

Практикум. 1. Түбәндәге әсәрләр өч төрле мәдәниятнең кайсына карый?

а) В. Высоцкий һәм Б. Окуджава җырлары,

б) Дж. Верди опералары,

в) «Юнона һәм Авось» рок-операсы,

г) такмаклар,

д) «күбек» опералар,

е) детектив әдәбият.

2. Һәр буынның (яшь буенча төркемнең) үзенә ошаган нәрсәләре, үз гадәтләре һәм зәвыклары, шул исәптән музыкаль зәвыклары була. Картлар рәхәтләнеп халык җырларын һәм совет композиторлары язган җырларны башкара. Урта буынның һәм яшьләрнең — үз музыкаль мавыгулары. Төрле яшьтәге кешеләрнең музыкаль мавыгуларын таблицага төшерегез. Аларның зәвыкларын, башкарган һәм яраткан җырларының характерын һәм эчтәлеген тасвирлагыз.

Буыннар	Музыкаль мавыгулар
Яшьләр	
Урта яшьтәгеләр	
Олылар һәм картлар	

§ 20 (§ 44). Дин

Дин кешелек җәмгыяте рухи сферасының бер чыганагы булып тора, ул җәмгыятьнең тарихи үсеш юлында төрле формаларда аның белән янәшә атлый.

«Дин» ике мәгънәгә ия. Бер мәгънәсе — латинча **religare** сүзеннән — җир (тудырылган) һәм күк (илаһи) дөньяларының матди булмаган, үзенчәлекле рухи бәйләнешен белдерә. Икенче мәгънәсе — латинча **religio** сүзеннән — диндарлык, изге нәрсәләр, культ предметы. Икенче мәгънә дини тәҗрибәнең

төп асылын тулысынча ача. Галимнәр дингә фәнни билгеләмә бирергә тырышалар.

Дингә бирелгән фәнни билгеләмәләр мәдәнияткә бирелгән билгеләмәләр саныннан калышмыйлар, алар инде 500 гә якынлашты. Шуларның барысын берләштереп, төшенчәнең төп асылын ачучы һәм бер үк вакытта аның төрле төсмерләрен дә исәпкә алучы билгеләмә биреп карыйк.

Динне без түбәндәге төп мәгънәләрдә аңларбыз:

1. Дин мәдәният, мәгариф һәм фән белән берлектә җәмгыятьнең *рухи сферасы компонентларының* берсен тәшкил итә.

2. Дин — кешелек җәмгыятенең төп нигез *институтларының* берсе.

3. Дин — *иҗтимагый аң сферасы* (идеология, фәнни белемнәр, гади фикерләр белән беррәттән), табигатьтән өстен көчкә ышану аның аермалы билгесе булып тора.

4. Дин — *дөньяга карашның* һәм дөньяны сиземләүнең үзенчәлекле *төре*, ягъни дөньяны Ходай яраткан (тудырган) дигән карашлар кушылмасы.

5. Дин — *мораль принциплар бердәмлеге*, алар шушы дини ышануда торучы кешеләрнең үз-үзләрен тотышын һәм яшәү рәвешләрен җайга сала.

7. Дин — бертөрле ышану һәм үзара бурычлар белән бәйләнгән күпсанлы кешеләр *төркеме*, *бердәмлеге*, союзы яки оешмасы (чиркәү мәхәлләләре, дини общиналар һәм җәмгыятьләр, монахлар орденнары, секталар).

8. Дин — *ышанулар һәм гамәлләр системасы*, аның ярдәмендә кеше тормышындагы мәсьәләләр хәл ителә.

Дин тарафыннан хәл ителүче проблемалар, җәмгыять строеның, фән һәм техника үсеше дәрәҗәсенең, халыкның мәдәни үзенчәлегенең нинди булуына карамастан, теләсә кайсы җәмгыять алдында хасил булалар.

Барлык диннәр дә түбәндәгеләргә бүленә:

а) *архаик политеистик диннәр — тотемизм, фетишизм, анимизм*;

б) дөньякүләм монотеистик диннәр — буддизм, христианлык, ислам.

Санап үтелгән өч дөньякүләм диннәрдән тыш яһүдләр тарафыннан тотылучы монотеистик дин — *иудизм* һәм тарафдарлары саны буенча дөньяда иң эре диннәрнең берсе —

индуизм да бар (бу динне Һиндстанда дини халыкның 95%ы тота).

Архаик диннәр — иң борынгылар. Алар мифология нигезен тәшкил итүче инануларга һәм мифларга таяна. Дөньякүләм диннәр яшьрәк булып, дини ышануга нигезләнәләр.

Архаик инанулар хәзерге дини ышануның элгәре формасы булып торалар. Шуңа күрә дә алар ышану дип түгел, ә инану дип аталалар.

Инану — реаль яки иллюзияләрдә генә булган нинди дә булса идеягә эмоциональ бирелгәнлек, ышану. Борынгы кешеләр Җирнең яссы булып, өч кит өстендә торуына ышанганнар. Алар моны ялгыш фикер яки ялган мәгълүмат дип исәпләмәгәннәр, ә расланган белем буларак кабул иткәннәр. Мифлар әнә шундый инануларга нигезләнгән.

Миф — *барлык дөньяның, җәмгыять белән кешенең андагы урыны турында фантастик, уйлап чыгарылган сурәте.* Мифлар легендар геройлар һәм аллалар образында табигать һәм социаль күренешләр чагылыш тапкан борынгы ыруглык яки антик җәмгыятьтә генә түгел, ә хәзерге заманда да яшиләр.

> **МИФ** (грекчадан mythos — риваять) — билгеле бер халыкларда, билгеле бер вакытта аларның тарих таңында урын алган кайбер вакыйгаларның символик чагылышы буларак сөйләнгән хикәят.

Мифлар, риваятьләр кебек үк, халык тарихы турындагы, әйләнә-тирә дөнья һәм бөек борынгы бабалар кылган батырлыклар хакындагы белемнәрне туплый.

Инанулар һәм мифлар мифологиягә берләшә. *Мифология* — дөньяга карашның иң тәүге формасы, аның аша кеше дөньяга һәм анда булган вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерә.

> **МИФОЛОГИЯ** — кешенең коллективка, коллективның — табигатьтән өстен дөньяга, әлеге дөньяның галәмгә кушылуы турындагы киң колачлы кагыйдәләр (борынгы ата-бабалар башлап җибәргән гореф-гадәтләрдән алып) системасы.

Мифология барлыкка килү *анда* гаять зур *революция буларак* кузаллана, аны неолит революциясе белән генә чагыштырып булыр иде. Борынгы ыруглык кешесенә ниндидер табигатьтән өстен көчләрне уйлап табу һәм үзләрен аларга ышанырга мәҗбүр итү генә түгел, ә җирдәге тәртипләрне, ягъни ни өчен дөньяда ярлылар һәм байлар булуын, кешеләрнең

үлгәннән соң кая китүен, башка дөнья барлыгын һәм анда кемнәр яшәвен аңлатучы дөньяга карашларның бербөтен системасын тудыру да мөһим була. Әгәр борынгы мифология дөньясына күз салсагыз, сез аның зур һәм киң колачлы булуына төшенерсез. Хәзерге заман композиторларының, рәссамнарының һәм шагыйрьләренең әлегә кадәр аннан илһам алуы очраклы хәл түгел.

Славян мифологиясе буенча, Җир Галәм үзәгендә тора; Җир эчендә тәмуг урнашкан, анда коточкыч ут дөрли. Күк йөзе каты әйбердән гыйбарәт гөмбәз буларак күзаллана. Өстәвенә күк бер генә түгел, җидәү. Иң түбән катында яңгыр, кар, чык һәм башка метеокүренешләр урнаша, алар белән фәрештәләр идарә итә. Кояш, ай һәм йолдызлар дүртенче катта торалар. Күкнең җиденче катында оҗмах урнашкан («Үземне җиденче кат күктә сыман бәхетле сизәм» гыйбарәсе әнә шуннан килә). Җир яссы булып, дәрья-диңгездә өч кит өстендә йөзеп йөри. Күктәге планеталар тере затлар дип кабул ителә, аларга кешеләр үтенечләре белән мөрәҗәгать итәләр. Йолдызларны халык үлгән кешеләрнең җаны дип уйлый, гадел кешеләрнең җаннары яктырак яна, ә гөнаһ ияләренеке тоныкк кына була, имеш.

Архаик диннәргә, инанулар, мифлар һәм мифологиядән тыш, үзенчәлекле йолалар һәм ритуаллар да керә. Аларының төрле комбинацияләре борынгы диннең 3 төрен — *тотемизм, фетишизм* һәм *анимизмны* китереп чыгара. Аларны иң борынгы культура комплекслары дип исәпләргә мөмкин.

Тотемизм борынгы җәмгыятьнең (элгәреге ыруглык строеның) инанулары һәм йолалары комплексыннан гыйбарәт, алар кешеләр төркемнәренең туганлык турындагы күзаллаулары һәм тотемнар (Төньяк Америка индеецларының оджибве кабиләсе телендә «ототем» — аның нәсел-ыруы) — хайваннар һәм үсемлек төрләре (сирәк кенә табигать күренешләре һәм җансыз предметлар) белән бәйләнгән. Тотемизм билгеле бер ыругның нинди дә булса тотем белән кан кардәшлеге һәм табигатьтән өстен бәйләнеше турындагы ышануга нигезләнгән. Бу тотем илаһи зат дип түгел, ә кардәш һәм дус дип исәпләнгән. Һәр ыруг үз тотемы исеме белән аталган. Ул тотемны үтерү һәм ризык итеп файдалану тыелган.

Инануның беренче объекты — *хайван*. Борынгы кешеләр тотем (ыруг символы) итеп сайланган хайван, әйтик, аю яки бүре белән иң якын туганнар арасында булган кебек кан кар-



дәшлегән тойганнар. Тотемнары аю булган төркем әгъзалары үзләрен аюлар дип исәпләгәннәр һәм бөтен аюлар — алар төркеменең әгъзалары дип уйлаганнар. Тотемлы кабиләләр һәр кеше үлгәннән соң үз тотемы хайванына әверелә һәм, димәк, һәр хайван аларның мәрхүм туганы булуына ышанганнар. Тотемга табыналар, аннан мәрхәмәт көтәләр, аның белән аралашалар, дошманнардан һәм йола башкаруга багышланмаган кабиләдәшләреннән саклыйлар. Кеше тормышының бөтен этаплары — туу, үсмер чордан өлкәннәр тормышына күчү, үлем — махсус багышлау йолалары аша узган. Бу йолалар процессында индивид социальләшкән, гореф-гадәтләрне, традицияләрне һәм община кыйммәтләрен үзләштергән.

Фетишизм хайваннарга түгел, ә конкрет предметларга дини табынудан гыйбарәт. *Фетиш* (фр. fetiche< португ. feitico — бөти; тылсым) — *дингә ышанучылар күзаллаулары буенча, табигатьтән өстен сихри көчкә ия булган һәм дини табыну объекты буларак хезмәт итүче җансыз предмет ул*. Кешене нәрсә беләндер гаҗәпкә калдырган теләсә кайсы предмет, мәсәлән, гаҗәеп формадагы һәм төстәге таш, хайван теше, агач кисәге, урмандагы агач төбе һ.б. фетиш була алган. Предмет фетишка әверелсен өчен аның могҗизалы көче ачылырга тиеш булган.

Борынгы кешеләргә фетишлар һәркайда (сукмакта, елга кичүендә, ишектә, муенда) очраган. Алар авырулардан саклаганнар, уңыш китергәннәр, сулыкларны балык белән тутырганнар, юлбасарларны тотарга һәм аларга җәза бирергә булышканнар, кыюлык өстәгәннәр, дошманны каушау хәленә китергәннәр.

Фетишизм үз тарихи эпохасын узып китеп, соңгырак чор мәдәнияте элементына әверелгән. Рыцарь тәре походына үзе сөйгән хатын-кызның яулыгын һәм сурәтен алып киткән, студент имтиханга барганда кесәсенә «бәхетле» әйбер сала, эшмәкәр яки автоузышчы кыйммәтле реликвияләрдән файдалана. Полк байрагын, дәүләт флагын, клуб символын, мундир абруен хөрмәт итүдә фетишизм кайтавазлары яңгырый. Спортчылар ярышларга үзләре белән йөрткән бүгенге бөтиләр-*фетишизм калдыгы* күренешләре.

Фетишизмның бер төре *потларга табынудан* гыйбарәт. Пот (*Идол*, грекчадан eidolon — образ, рәвеш) сүзенең ике мәгънәсе бар: а) кеше яки хайван сыны формасында ясалган матди җисем; б) дини табыну объекты булып хезмәт итүче илаһи зат яки рух сурәте. Күчерелмә мәгънәдә бу сүз сукырларча табыну предметын аңлата. Хәзерге диннәрдә иконаларга яки изгеләр җәсәденә табынулар — бер үк вакытта фетишизм һәм потларга табыну калдыгы алар.

Архаик инануларның өченче формасы булып **анимизм** тора. Анимизм (латинчадан anima, animus — җан, рух) — *рухлар һәм җаннар булуына ышану*. Аның асылы кешедән, хайваннан яки үсемлекләрдән *аерым яшәргә сәләтле рухи көч барлыгын танудан* гыйбарәт. Ул бер урыннан икенче урынга күчеп йөри, кешегә яки хайванга иңә һәм аларны калдырып китә. Бу рухи көч бөтен Галәмне йоткан чиксез субстанция, яки матди булмаган, үлгән ата-баба буларак күзаллана. Полинезиядә, мәсәлән, рухларга ышанучы кабиләләр яши. Әле хәзер дә күп кенә интеллигент кешеләр, полинезиялеләр кебек, рухларны чакыру белән шөгыльләнәләр. Миллионнарча кешеләр хәзер дә спиритизмга, рухлар белән аралашуга, җаннар күчешенә һ.б. ышаналар.

Җанның мөстәкыйль рәвештә яши алуына ышану анимизм үсешенең иң югары формасы булып тора. Җан башка кешеләргә, хайваннарга, үсемлекләргә күчә ала. Үле тәнгә күчкән җан аны терелтә. Кеше үлгәндә аның җаны тәненнән аерыла. Җаны булмагач, ул инде кеше түгел. Соңрак кешеләр

җанны конкрет кешенең игезәге, аның икенче «мин»е дип уйлый башлыйлар. Классик һәм хәзерге әдәбиятта без еш кына явыз кеше җанының, бозылмыйча сакланып, әчке намус ролен башкаруы, акылга килеп мәрхәмәтле эшләр кылырга чакыруы белән очрашабыз.

Тотемизм, фетишизм һәм анимизм нәрсәнедер яки кемнедер (хайванны, предметны, рухны) гадәттән тыш югары күтәрүгә, аны бөек, өстен дип уйлауга корылган. Бу юлның алдагы адымы аерым бер предметка баш июне изге әйбер алдында табынуның катлаулы системасына әверелдерүдән гыйбарәт. Бу табынуга бер генә түгел, ә күп гамәлләр, ритуаллар, йолалар кирә, аңа үзенчәлекле космик мәгънә салына. Башкача әйткәндә, *дини культ* барлыкка килә.

Культ (латинчадан cultus — хөрмәт итү, баш ию) — *диннең төп элементларының берсе; дини табынуга күзгә күренеп торган рәвеш бирү яки аны башкаручыларга илаһи «көч» иңдерү (тылсымлы дини йолалар) максатына корылган хәрәкәтләр* (тән хәрәкәтләре, билгеле бер текстларны һ. б. уку яки җырлау) ул.

Кайбер галимнәр *культ системасына* теләсә кайсы диннең төп элементы дип карыйлар. Ул мәгълүм ***йолалар*** кушылмасыннан тора. Йоланың асылы турында без инде сөйләшкән идек. Монда бары тик йоланың *символик* характерына игътибар итәбез.

Символ (грекчадан symbolon — тамга, аеру билгесе) — *матди җисемне алыштыручы идеаль билге.* Таҗ патша хакимиятен символлаштыра. Дини йолада теләсә кайсы хәрәкәткә, ишарәгә, сүзгә яки предметка билгеле бер мәгънә салынган, алар символлар буларак аңлашылалар.

Күп кенә йолалар һәм культлар, архаик диннәрдә барлыкка килеп, тора-бара хәзерге заманнарга барып җиткәннәр. Менә, мәсәлән, начарлыктан чистарынуны гәүдәләндергән суга чуму белән бәйле *чистарыну, арыну йолалары* борынгы ыруглык җәмгыятендә үк барлыкка килгәннәр һәм хәзерге дөньяда да саклананалар. Христианнарда су белән чукындыруга корылган чистарыну йоласы баштагы гөнаһтан чистарынуны һәм чиркәүгә кушылуны аңлата.

Мәрхәмәтләндерү хәрәкәтләренә корылган *корбан китерү* дә борынгы йола. Бик борынгы заманнардан ук кешеләр ата-бабаларына, аллаларга һәм рухларга, аларның ачуын китермәү

яки яхшылыклары өчен рәхмәт йөзеннән, корбан биргәннәр. Күп очракларда корбан итеп сарык яки сыер чалганнар.

Борынгы җәмгыятьтә корбан китерүнең өч төре яшәгән: сыйлау корбаннары, чистарыну корбаннары, багу корбаннары. Беренче очракта корбан Алланы сыйлау буларак аңлатылган. Әгәр Алла бер кешегә барлык эшләрендә дә булыша икән, һәр уңышлы очрактан аңа да өлеш чыгарырга кирәк була. Уңыш җыйганда, беренче башакларны, беренче җимешләрне Аллага биргәннәр. Ашаганда, Аллага махсус пешерелгән печенье яки баллы белен калдырганнар.

Икенче очракта корбан кешенең гаебе өчен китерелгән. Әгәр дә кеше очраклы рәвештә кеше үтерсә, ул туган ягыннан китәргә һәм, чит җирләрдә яшәп, бу гөнаһыннан арынырга тиеш булган. Каһин алтарьда ут кабызган, дуңгыз баласын чәнчегән, аның канын килгән кешенең кулларына чәчрәткән, ә аннан соң кулларны изге су белән юган һәм сөрткән. Бу канның кан белән юылуын һәм кешенең туганнары янына кайта алуын белдергән. Сугышлар алдыннан багу корбаннары китерелгән. Хайванны суйганнар да алтарьда аның ите, аеруча койрыгы ничек януын күзәткәннәр; әгәр дә койрык бөгәрләнеп килсә, бу алда торган авырлыкларны аңлаткан, әгәр дә инде койрык очы аска караса — җиңелүне, күтәрелсә җиңү килүне белдергән. Кешенең ләззәтләрдән, байлыктан баш тартуы да корбан китерү булып исәпләнгән. Христианлык реаль корбан китерүләрне символик корбаннар белән алыштырган. Иконалар алдында шәм һәм лампадалар яндыру ритуалы шуның ачык мисалы булып тора.

Ата-бабалар культы — иң борынгы йолаларның берсе. Үлгән ата-бабалар рухы үз варислары тормышына йогынты ясый дип уйлаганнар. Борынгы кешеләр генә түгел, хәзерге күп кенә халыклар да тере кеше белән аның мәрхүм бабасы арасында күзгә күренмәс элемтә бар дип исәплиләр. Ата-бабалары рухларыннан ярдәм һәм яклау сорыйлар. Үлгәннәрнең тереләрне ***яклау институты*** әнә шуннан килеп чыккан. Мәрхүм туганның рухы даими төстә «кунакка» килеп йөри, кыен хәлләрдән, авырулардан саклый, дөрес булмаган адымнар өчен җәза бирә, тормыш авырлыклары килгәндә, дөрес юл сайларга булыша, җыеп аласы уңышка һәм терлек үрчеменә йогынты ясый. Кайбер архаик җәмгыятьләрдә абруйлы кешеләрнең мәетләре яшәгәндәге көчләренең бер өлешен саклап

кала дип уйлыйлар. Азия илләренең күпчелегендә борынгы ата-бабалар культы «уллар хөрмәте» кебек хәзерге заман этикасына әверелә, *модификацияләнә*. Ул үзенең дини эчтәлеген югалтып, дөньяви тәрбиянең генә түгел, ә халык тәрбиясенең нигезен тәшкил итә. Мәсәлән, әти-әниләрне хөрмәт итү һәм алар турында кайгырту кытай кешесенең изге бурычы санала.

Мифлар эпохасының тәмамлануы яңа *дөньякүләм диннәр эпохасы* башлануын һәм бер үк вакытта ипануларлан дини ышануга күчүне аңлата. *Дини ышану* — гаять катлаулы мәдәният феномены, анда югары интеллектуальлек, илһамлану, рухи яктан үзеңнән югары торган дөнья белән элемтәң булуы өчен горурлану хисләре бергә кушылган.

Дөньякүләм диннәрдә (буддизм, христианлык, ислам) ышану катлаулы мәдәният комплексын тәшкил итә. Аңа дини ышану предметы, дини ышану доктринасы, дин тоту практикасы, дини тәгълимат һәм башка элементлар керә. Мәсәлән, барлык христианнарны Алла кеше Иисус Христоска — дөньяны коткаручыга ышану берләштерә. Ул бердәм Алла өчлегенең — Ата-Алла, Угыл-Алла һәм Изге Рухның 2 нче заты булып тора. Өчлек — христианлыкның иң төп догматларыннан берсе. Дини ышану тәгълиматының төп чыганагы — Библия, ул Иске Гаһедтән (христианлыкта да, иудизмда да Изге Язма булып исәпләнә) һәм Яңа Гаһедтән (христиан дине тарафыннан гына таныла) тора.

«Ышану» сүзеннән *дини ышану тәгълиматы* дигән фәнни төшенчә килеп чыккан. Ул төшенчә белән табигатьтән өстен дөньяга, илаһи затка ышануга нигезләнгән системалаштырылган тәгълиматны (өйрәтмәне), концепцияне, бердәм идеяләрне билгелиләр. Бу мәгънәдән чыгып караганда , буддизм, христианлык һәм ислам дини ышану тәгълиматларына керәләр. Дини ышану тәгълиматлары чыганагы булып нигез принциплар системасы тора, алар Изге Язмада — христианнар өчен Библиядә, ә мөселманнар өчен Коръәндә теркәлгән. Дини ышану тәгълиматының төп чыганагы — мәңгелек, иҗат ителмәгән «Алла сүзе», вәхи.

Алланың асылы һәм гамәле турындагы дини доктриналар һәм тәгълиматлар барысы бергә *теология* (грекчадан theos — Алла һәм logos — сүз) дип атала, турыдан-туры мәгънәсе — *дини өйрәтмә, дини тәгълимат*. Ул абсолют Алла концепциясенә таяна, Алла кешегә үзе турында хакыйкый хәбәр, вәхи

аша мәгълүмат җиткерә. Теологияне төгәл мәгънәдә кулланганда иудаизм, христианлык һәм ислам күз алдында тотыла. Теологиянең мөһим элементы булып *Алла вәхие* тора.

Вәхи — илаһи затның (Алланың) турыдан-туры ихтыярын, теләген белдерү яки, кеше гамәлләренең һәм танып-белүенең абсолют критерие буларак, Алладан иңүче гыйлем. Ул Изге Язма текстында (иудаизм һәм христианлыкта — Библиядә, исламда — Коръәндә) һәм Изге Риваятьтә (иудаизмда — Талмуд, христианлыкта — «чиркәү атакайлары» язмаларында, исламда — сөннәдә) язма рәвештә теркәлгән.

Дөньякүләм диннәрнең төп идеяләре *канунда* (грекчадан kanon — норма, кагыйдә) чагылыш тапкан. Чиркәү һәм Библия кануннарын аерып йөртәләр. *Чиркәү кануны* — догматика, культ, чиркәү төзелеше турындагы кагыйдәләр, христиан чиркәве аларны законга әверелдергән. *Библия кануны* — барлык Библия китаплары, аларны чиркәү «Алла иңдергән» дип таный, бу китаплар гыйбадәт кылганда Изге Язма буларак кулланыла. Гади телдә «канун» сүзе ныклап урнашкан, барлык халык тарафыннан кабул ителгән нәрсәләрне белдерә.

Төшенчәләр: *дин, архаик диннәр, дөньякүләм диннәр, мифология, тотемизм, фетишизм, анимизм, культ.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Дин нәрсә ул? Дин — ышанулар һәм гамәлләр системасы, аның ярдәмендә кеше тормышындагы мәсьәләләр хәл ителә. Сез моны ничек аңлыйсыз? Нинди мәсьәләләр турында сүз бара?

2. Мифология нәрсә ул?

3. Безнең көннәрдә дә мифология бармы? Сез моңа ышанасызмы? Үз фикерегезне дәлилләгез.

4. Фетишизмны сыйфатлагыз. Аның бүгенге чагылышларына мисаллар китерегез.

5. Анимизм кайчан һәм ни өчен барлыкка килгән?

6. Бу параграфта тасвирланган борынгы культларның мәгънәләрен аңлатыгыз. Корбан китерүләр бүгенге көндә дә мөмкинме?

7. Дөньякүләм диннәр дип кайсы диннәрне атыйлар?

8. Инанулар һәм дини ышану арасында аерма бармы? Билгесез очкыч объектлар (НЛО) булуына ышануны сез аларның кайсына кертер идегез?

9. Сез нинди дини йолаларны беләсез?

*10. Хәзерге заман кешесе тормышында дини йолалар нинди урын алып торалар?

? Проблема. Тарихта шунысы мәгълүм: җәмгыятьтә кризис булган вакытларда диннең кешеләрнең иҗтимагый һәм шәхси тормышына йогынтысы үсә, аларның дини һәм дини булмаган инанулары колачы киңәя, хорафатларга ышану, оккультизм, мистика күренешләре артуы күзәтелә. Аңлатыгыз, ни өчен шулай була?

Практикум. Түбәндә архаик инануларның төп формалары чагылыш тапкан һәм аларга билгеләмәләр бирелгән. Әмма кемдер аларны бутап бетергән. Тәртипкә китерергә ярдәм итегез.

Тотемизм	рухлар һәм җаннар булуына ышанудан гыйбарәт
Фетишизм	кешеләр төркемнәре белән хайваннар һәм үсемлекләр төрләре арасында кардәшлек бар дигән күзаллау белән бәйләнгән инанулар һәм йолалар комплексыннан тора
Анимизм	хайваннарга түгел, ә конкрет предметларга дини табынудан гыйбарәт

§ 21 (§ 45). Сәнгать

«Сәнгать» сүзен кимендә өч мәгънәдә аңларга кирәк.

— *Киң мәгънәдә сәнгать* — тулаем нәфис иҗат ул. Аңа әдәбият, архитектура, скульптура, рәсем сәнгате, музыка, бию, театр, кино һәм кеше эшчәнлегенең дөньяны танып-белү барышында әдәби образ формалары рәвешендә берләштерелгән башка төрләре керә.

— *Тар мәгънәдәге сәнгать* — бары тик сынлы сәнгать буларак кына аңлашыла.

— Теләсә кайсы эшчәнлек өлкәсендә осталыкның, *махирлыкның иң югары дәрәҗәсен билгеләүче сәнгать.*

Сәнгатьне бик тар итеп аңлатып, аны сынлы сәнгатькә генә кайтарып калдырырга мөмкин, киң мәгънәдә аңлату очрагында ул иҗатның барлык төрләрен колачлый дияргә мөмкин. Бу нюансларны төшенү өчен, сынлы сәнгать һәм әдәби иҗат арасында нинди аерма булуын кыскача гына әйтеп үтү кирәк.

Сынлы сәнгатьләр — пластик сәнгать төрләренең бер бүлеге, ул рәсем сәнгатен, скульптураны һәм графиканы үз эченә ала. Сынлы сәнгатьләр чынбарлыкны күзалларлык, күреп аңларлык образларда чагылдыра. Иҗатчының иҗади хыялы, гомуми-

ләштерү, типиклаштыру алымнары нәтиҗәсендә сынлы сәнгатьләр шул вакытта вакыйгалар агышын, кешеләрнең рухи йөзен, кичерешләрен, фикерләрен, үзара мөнәсәбәтләрен эстетик яктан ачу һәм иҗтимагый идеяләрне чагылдыру мөмкинлегенә ирешәләр.

Нәфис иҗат «нәфис мәдәният» (художественная культура) сүзенә синоним булып тора.

> **НӘФИС МӘДӘНИЯТ** нәфис иҗат эшчәнлегенең сүз, музыка, театр, сынлы сәнгать һ.б. кебек барлык төрләрен берләштерә, аңа бу эшчәнлекнең барышы һәм нәтиҗәсе дә керә, төгәлрәк әйткәндә, ул иҗат итүдән, саклаудан, таратудан, аңлау-кабул итүдән, бәяләүдән, әдәби әсәрләрне өйрәнүдән, шулай ук иҗатчыларга белем бирүдән, тәнкыйтьчеләрне, сәнгать белгечләрен, тамашачыларны тәрбияләүдән гыйбарәт.

Көндәлек тормышта без әледән-әле «мәдәният һәм сәнгать», «мәдәният һәм әдәбият», «мәдәният һәм тормыш» гыйбарәләре белән очрашабыз. Алар нәрсәне аңлата соң?

Мәдәният һәм сәнгать янәшә торганда, мәдәният үз-үзеңне тотуның күптөрле чагылышларын, шул исәптән көнкүреш мәдәниятен дә колачлый дип исәпләнә, ә сәнгать исә профессиональ сәнгать өлкәсе белән генә чикләнә. Әгәр дә сәнгать сүзе тормыш белән янәшә урнашса, аның хәзерге чынбарлык мәшәкатьләреннән читтә торуын, образлар һәм идеяләр дөньясына китүен күз алдында тоталар. Әгәр дә сәнгатьне әдәбият белән янәшә куйсалар, сүз иҗаты сәнгать өлкәсенә керергә тиеш түгел, ул үзе аерым тора дип әйтергә телиләр. Димәк, роман, шигырь яки театраль пьеса сәнгать түгел булып чыга.

Көнкүрештә сәнгать гаять киң төшенчә буларак аңлатыла. Режиссерлар, артистлар, шагыйрьләр һәм рәссамнар үзләрен мәдәният эшлеклеләре, сәнгать эшлеклеләре дип атыйлар. Бу очракта мәдәният белән сәнгать арасында тигезлек билгесе куела. Гәрчә мондый якын килү мәдәният һәм сәнгать төшенчәләрен төгәл билгеләүдә өстәмә авырлыклар тудырса да, әлеге ике күренешне аңлауның бөтен вариантларын истә тоту зарур.

Сәнгатьне без нәфис мәдәният белән якынайтырбыз, әмма алар арасында тулысынча тәңгәллек билгесе куймабыз. Аларның охшаш һәм аермалы билгеләре бар. Охшашлык шунда ки, сәнгать һәм мәдәният — әйләнә-тирәлеккә карата образлы

чагылдыру мөнәсәбәте өлкәсе, үзеңнең эчке халәтеңне эстетик чагылдыру алымы ул; эстетик чагылдыру вакытында, идея һәм хисләр эчтәлеге белән чагыштырганда, форма беренче планга чыга. Сәнгатьтә иң төп нәрсә — әйләнә-тирә дөньяны эстетик сурәтләү һәм аны югары профессиональ дәрәҗәдә, бик оста итеп ташта, спектакльләрдә, картинада чагылдырудан гыйбарәт.

Аерма түбәндәгеләрдә күренә. ***Сәнгать — нәфис мәдәниятнең иң югары ноктасы гына ул.*** Соңгысы иҗади кыйммәткә ия булган профессиональ әсәрләрне генә түгел, ә һәвәскәрләрнең, дилетантларның үзләре өчен генә кадерле булган эшләрен дә колачлый. Нәфис мәдәнияткә караган күпсанлы күренешләрне без бер төп критерий буенча, ягъни *чынбарлыкны*, кешеләрнең кичерешләрен, уй-фикерләрен *образлы итеп чагылдыру* аша аерабыз. Бу чагылдыру камил яки камил булмаска мөмкин. Нәфис мәдәниятнең бары тик югары дәрәҗәдә эшләнгән һәм башка кешеләр өчен дә иҗади кыйммәткә ия булган өлеше генә сәнгатькә керә.

Димәк, нәфис мәдәниятне аерып карауның критерие — предмет, ә сәнгатьнеке — осталык дәрәҗәсе. Нәфис мәдәнияткә

профессионаллар эшчәнлеге нәтиҗәләре генә түгел, ә алар эшчәнлегенә ярдәм итүче киң колачлы инфраструктура да кирә. Бу — рәссамнар остаханәләре, заллар, картина галереялары, консерваторияләр, филармонияләр, махсус журналлар, газеталар, матбугат продукциясе, телевидение каналлары, нәшриятлар, вуз кафедралары һәм лабораторияләре, махсус мәктәпләр, гимназияләр, лицейлар, артистлар, рәссамнар, язучылар берлекләре һ.б.

Профессионал яки дилетант тарафыннан язылган шигырьләр бер-берсеннән бик нык аерыла. Беренчеләре киң даирә укучылар тарафыннан танылганга, ә икенчеләре авторга һәм аның дусларына кадерле булганга гына түгел, әлбәттә. Профессиональ әсәрләр башка төрле иҗтимагый мәгънә ала. Сәнгать әсәренең чын социаль мәгънәсе халыкка тәкъдим ителгәч кенә, мәдәният ягыннан әзерлекле тамашачылар һәм белгечләр катнашындагы фикер алышуларда, бәяләүләрдә генә ачыла. Дилетант исә үз әсәрләрен тамашачыга тәкъдим итми, алар иҗтимагый танылу тапмый.

Профессионал һәм дилетант аудиториясе бөтенләй башка төрле: беренчесендә — зур социаль төркемнәр, икенчесендә исә киресенчә хәл күзәтелә. Профессиональ әсәргә хөкемне тәнкыйтьчеләр, сәнгать әһелләре, ягъни белгечләр һәм белемле тамашачы чыгара, ә һәвәскәрләргә исә теләге булган һәр кеше бәя куя ала. Теләсә кайсы җәмгыятьтә сәнгатьне тирәнтен аңлау бары тик әзерлекле азчылыкка гына хас. Сәнгать әсәрләрен туплау, фәнни анализ ясау, тәнкыйди бәяләү, таныту һәм меценатлык белән шулай ук әзерлекле кешеләрнең аз санлы төркемнәре генә шөгыльләнә.

Шуңа да карамастан, һәвәскәр шигырьләре дә, профессионалныкылар да, нәфис мәдәниятнең һәвәскәрлеккә корылган башка төрләре кебек үк (аларга фольклорның барлык катламы — эпостан һәм бәетләрдән алып такмакларга һәм әфсеннәргә кадәр керә), эшчәнлекнең бер үк рухи өлкәсенә карыйлар. Алар барысы да кеше рухының иң югары омтылышлары һәм эчтәлекнең эстетик принциплары белән сугарылган.

Сәнгать — кешенең үз кичерешләрен иҗади образлы чараларда һәм жанрларда чагылдыру сәләтенә корылган махсус профессиональ эшчәнлек ул.

Нәфис мәдәният субъектлары түбәндәгеләргә бүленә:

— яңа әсәрләр һәм идеяләр тудыручылар;



— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне коммерциягә корылмаган нигездә таратучылар;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне финанслаучылар;

— яңа әсәрләр һәм идеяләр белән таныштыручылар;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне өйрәтүчеләр;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне массакүләм тиражлаучылар;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне коммерция нигезендә сатучылар һәм табыш алучылар;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне бәяләүчеләр һәм тикшерүчеләр;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне булдыру һәм тарату өстеннән дәүләт контролен һәм идарәсен тормышка ашыручылар;

— яңа әсәрләрне һәм идеяләрне укучылар, караучылар, тыңлаучылар;

— яңа әсәрләрнең һәм идеяләрнең тарафдарлары.

Мәдәният формалары турында (халык мәдәнияте, элитар һәм массакүләм мәдәниятләр) сөйләгәннәрне искә төшерсәк, нәфис мәдәнияткә халык һәм элитар (югары) мәдәниятләр әсәрләренең тулаем, ә массакүләм мәдәният әсәрләренең өлешчә генә керүен күрербез. Сәнгатькә без бары тик элитар сынлы сәнгать әсәрләрен — Пикассо картиналарын, Чайковский симфонияләрен, Нерль буендагы Покров храмын, Станиславский театрын кертәбез.

Халык иҗаты белән теләсә кем шөгыльләнә ала, ә сәнгать белән шөгыльләнү билгеле бер әзерлек таләп итә. Сәнгать белән профессиональ рәвештә шөгыльләнү өчен рәссам осталык

нигезләрен өйрәнергә тиеш. Сәнгатьнең өченче мәгънәсен искә төшерик — югары дәрәҗәдәге осталык, махсус күнекмәләр. Теге яки бу әсәрне тулаем нәфис мәдәнияткә яки аның бер өлеше булган сәнгатькә кертүнең критерие әнә шундый.

Ниһаять, нәфис мәдәният һәм сәнгать аермалары схемасына соңгы штрих. Нәфис мәдәният, исегездәдер — элитар мәдәният белән халык мәдәнияте ул. Сәнгать бары тик яки күпчелек очракта элитар мәдәният кенә була. *Сәнгать белеме* иҗатның профессиональ төрләрен генә өйрәнә.

Шулай итеп, *сәнгать* — профессиональ иҗат өлкәсе, *фольклор* — халык иҗаты өлкәсе, *нәфис мәдәният* — бу ике өлкә бердәмлеге.

Мәдәният артефактларының гаять зур колачлы дөньясында сәнгать әсәрләре — сонаталар һәм романнар, картиналар һәм театр спектакльләре — иң югары позицияне билиләр. Фәнни теорияләр, дини тәгълиматлар һәм фәлсәфи язмалар белән беррәттән, нәфис мәдәният продукциясе кеше рухының иң катлаулы һәм иң югары чагылышы булып тора.

Элек «сәнгать» сүзе белән кеше ясаган теләсә нинди эшләнмәләрне — керамик савыт-сабаны, ювелир бизәнү әйберләрен, медицинаны, агрокультураны һәм хәтта сугышның тактик алымнарын атаганнар. Алар барысы да «сәнгатьләргә» (arts), яки һөнәрләргә кертелгән, файдалы практик белгеләргә генә түгел, ә югары эстетик сыйфатларга да ия булганнар. Бары тик соңрак кына рәсем сәнгате, әдәбият, архитектура, скульптура, балет һәм аларга якын торган гүзәл иҗат төрләрен сәнгатькә кертә башлаганнар. Нәтиҗәдә терминның мәгънәсе тарайган. Әмма киң мәгънәдә дә сәнгать бары тик бик оста иҗат ителгән әсәрләрне генә колачлаган.

Бүген сәнгать өлкәсенә өч мәҗбүри критерийга туры килгән әсәрләрне генә кертәләр. Сәнгать әсәре

— **танып-белү кыйммәтенә,**

— **эстетик кыйммәткә,**

— **әхлакый кыйммәткә**

ия булырга тиеш.

Сугыш алып бару сәнгате бер критерийга туры килсә дә, икенчеләренә туры килми. Ювелир бизәнү әйберләре яки медицина турында да шуны ук әйтергә мөмкин. (Уйлап карагыз, алар нинди критерийларга туры килмиләр?)

Кыйммәтнең күрсәтеп үтелгән өч төрен (аларга сәнгать әсәрләре буйсына) башкача да формалаштырырга мөмкин:

— **хакыйкать,**

— **гүзәллек,**

— **мәрхәмәт.**

Мөгаен, рухи дөньяны тулысынча чагылдыручы дүртенче критерийны табу бик авыр булыр (бишенчесе яки алтынчысы турында инде әйтеп тә торасы юк). *Хакыйкать, Гүзәллек һәм Мәрхәмәт — җәмгыятьнең рухи өлкәсе таяна торган өч кит ул.* Без бу өлкәдән нәрсәне генә алып карасак та — фәнни теорияне, педагогик алымны яки дини тәгълиматны — алар теге яки бу дәрәҗәдә өч төп рухи принципка туры киләчәк. Фәнни теориядә беренче планга Хакыйкать чыга, дини тәгълиматта — Мәрхәмәт, белем өлкәсендә тегесе дә, монысы да аз-азлап катнаша. Әдәби әсәрләрдә беренче планга Гүзәллек алга чыга.

Әдәби иҗатның шушы критерийларга туры килгән барлык төрләрен без *гүзәл сәнгатьләр*, яки гади генә итеп сәнгать төрләре дип әйтә алабыз. Аларга әдәбият, рәсем сәнгате, скульптура, театр, кино, балет һәм классик бию, архитектура һ.б. керә.

Инглиз телендә сәнгатьләр (күплек санда) arts дип атала. Бу сүз латинча ars, artis — һөнәр, шөгыль; сәнгать, фән сүзләреннән килеп чыккан. Аңа сыйфат өстәгән очракта конкрет шөгыль төрләре мәгънәсе килеп чыга. Мәсәлән, artes liberalis — ирекле сәнгатьләр, artes sordidae — һөнәр, artes optimae — фәннәр, artes disserendi — диалектика. Күпчелек санда алынган artes сүзе сәнгать әсәрләрен аңлата. Аның туры мәгънәсе әнә шундый, ә күчерелмә мәгънәсе — әхлак сыйфатлары, гамәлләр, омтылышлар. Киң мәгънәдә әлеге сүз нәрсәнедер әзерләү өчен кирәк булган белем һәм осталыкны белдерә. Мәдәният турындагы параграфта сезгә очраган «артефакт» төшенчәсе дә шул ук тамырдан килеп чыккан.

Борынгы грекларда башка сүз файдаланылган — techne. Аннан «техника» һәм «технология» сүзләре килеп чыккан. Ул, беренче сүз кебек үк, шөгыль, һөнәр, фән мәгънәләрен белдерә. Әмма аның ориентациясе башка төрле. Латин сүзе күбесенчә гуманитар белемнәргә юнәлеш тота, ә грек сүзе — техник һәм табигать фәннәренә. Шуңа күрә без беркайчан да

«техника» сүзен әдәбият яки театрга бәйләп әйтмибез. Шул ук вакытта башкару сәнгатенең барлык техник алымнарын (мәсәлән, балет сәнгатенекен) без техника дип атыйбыз.

«Ирекле сәнгатьләр» термины бик күптәннән барлыкка килгән: урта гасырларда грамматика, риторика, логика, арифметика, геометрия, музыка, астрономия кергән университет фәннәре курсы шулай аталган. Бу курсны укып бетергән студент сәнгать бакалавры дәрәҗәсен алган.

Борынгы грек философлары, иң беренче чиратта Платон һәм Аристотель, сәнгатьне гүзәл һәм гамәли төрләргә аермаганнар. Алар ирекле гражданнар шөгыльләнгән ирекле сәнгать белән коллар өлешенә караган «сервис» (хезмәт күрсәтү) сәнгатьләре арасында чик сызыгы билгеләгәннәр. «Ирекләләр» сыйфаты латинча liberalis сүзенә барып тоташа, бу сүз ирекле кешегә лаек шөгыльне белдерә. Ирекле гражданнар авыр физик хезмәт яки хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләмәгәннәр. Моның өчен грекларда һәм римлыларда коллар җитәрлек булган. Гражданнарның акыл эшчәнлеге өчен бик күп вакытлары калган, алар бу вакытны театрларга, стадионнарга, музейларга, мунчага, фәлсәфи әңгәмәләргә, бәхәсләргә, сәяси митингларга, күпсанлы дини ритуалларга һәм церемонияләргә, багуга һәм оккультизмга, йолдызларны күзәтүгә, шигъри ярышларга багышлаганнар. Моның өчен логика, риторика, астрономия, музыка сәнгатьләре таләп ителгән. Һөнәрләр (итек тегү, авыл хуҗалыгы хезмәте, төзелеш эше, металл эшкәртү һ.б.) белән халыкның башка катлаулары — коллар һәм ярлылар шөгыльләнгән. Физик кул хезмәте — товар җитештерүме ул, әллә хезмәт күрсәтүме — *сервиль сәнгать* (латинчадан servio — кол булу, тырышып хезмәт итү) дип аталган. Элек аңа рәсем һәм скульптура сәнгате дә кертелгән. Ә хәзер алар гүзәл сәнгать төрләренә карыйлар.

Урта гасырларда (400–1400 еллар) нәфис иҗатның соңрак гүзәл сәнгатькә кертелгән төрләре, иң беренче чиратта рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура, чиркәүләрне, монастырьларны, сарайларны, шәһәр җәмәгать биналарын, парк һәм виллаларны декоратив бизәү алымнары сыйфатында файдаланылган. Бай аксөякләр һәм туып килүче сәүдәгәрләр катлавы рәссамнардан үз утарлары, галереяләре, коллекцияләре өчен, бер-берсен уздыра-уздыра, картиналар һәм скульптуралар ясатканнар. Әгәр дә алар шул рәвешле үз мәнфәгатьләрен өстен

куймасалар, иҗат төрләре үсә алмыйча, билгесезлектә калырлар иде.

Рәссамнарның диварларны, плафоннарны, колоннадаларны бары тик файдалану максатыннан (утилитар максаттан) чыгып бизәүдән югарырак күтәрелгән беренче буыны Яңарыш (Ренессанс) чорында гына (XIV–XVI гасырлар) барлыкка килә. Алар үз хезмәтләрендә мәңгелек бөек идеалларны чагылдыруга ирешәләр. Рәсем сәнгате һәм скульптураның утилитар максатлардан бәйсез, үзенчәлекле кыйммәткә ия булуы тагын да ачыкланa төшә. Алар тамашачыны дулкынландыра, борчый, сөендерә, сокландыра һәм уйга сала.

Бай һәм урта сыйныф (вак буржуазия) рәссамнар, архитекторлар һәм скульпторларга гына түгел, ә артистларга һәм композиторларга да теләктәшлек, ярдәм күрсәткән. Урта гасырларда шәһәрләрдә күпсанлы театраль труппалар һәм сукбай музыкантлар йөргән, аларны король сараенда үткәрелүче массакүләм бәйрәмнәргә, халык тантаналарына чакырганнар. Кешеләрнең киң практик яклау тапкан гүзәл сәнгатьләр белән мавыгуын теоретик яктан аңлау-төшенү өчен алшартлар туган.

«Гүзәл сәнгать» төшенчәсе Франциядә XVIII гасырда барлыкка килә. Гамәли, ягъни практик файда китерүче сәнгатьләрдән аермалы буларак, гүзәл сәнгатьләр бөтенләй башка максатларга хезмәт иткәннәр — алар тамашачыга яки тыңлаучыга ләззәт китергәннәр. Бу сыйфат *эстетик* сыйфат дип аталган, ягъни гүзәллек, матур буларак бәяләнгән.

Җәмгыятьнең рухи сферасына караган дүрт элементның икесе — *фән һәм мәгариф* — алгарыш (прогресс) кичерәләр, монда кичә яхшы булган нәрсә бүген тагын да яхшырагы белән алышына. Ә башка ике элемент — *сәнгать һәм дин* прогресстан читтә торалар. Беренчеләре гел вакыт эчендә баралар һәм мәңгелеккә таба, ягъни идеалга гына ашкыналар. Икенчеләре инде мәңгелектә торалар, тамашачыларга, дини кешеләргә мәңгелек гүзәллекнең һәм мәңгелек мәрхәмәтнең нәрсә икәнен хәбәр итәләр. Дин кануннары мең еллардан соң да мәңгелек хакыйкать булып калачак. Микеланджело картиналары һәм скульптуралары мең еллар узгач та мәңге гүзәл булачак. Әмма И. Ньютон һәм А. Эйнштейн теорияләре мең елдан соң хак булмаска да мөмкиннәр. Техник уйлап табулар да мәңге камил булып калмаячак. Аларны киләчәктә тагын да камилләштерәчәкләр. Агач чут төймәләре урынына механик калькулятор

килде, ә аны электрон калькулятор алыштырды. Сәнгать — Гүзәллеккә, дин — Мәрхәмәткә, ә техника — Файдага хезмәт итә.

Гүзәллек һәм Мәрхәмәт берлеге гүзәл сәнгатьне, ә Гүзәллек һәм Файда берлеге — гамәли сәнгатьне тудыра. Кабаре, цирк, спорт, архитектура, дизайнда Гүзәллек һәм Файда бергә кушыла.

Һөнәр яки сәнгать төре гамәли дип аталсын өчен әсәрнең башта файданы күздә тотып иҗат ителүе, шуннан соң гына гүзәллекне чагылдыруы кирәк. Чиркәү яки мәчет бинасы башта гамәли яки практик максатлар өчен корыла, ә аннан соң гына эстетик максатларга хезмәт итә. Шуңа күрә архитектураны гамәли сәнгатьләргә кертү дөресрәк булыр.

Төшенчәләр: *сәнгать, нәфис мәдәният, фольклор, «ирекле сәнгать».*

Сораулар һәм биремнәр

1. Киң һәм тар мәгънәдә сәнгать нәрсә ул? Сезнең өегездә сәнгать буенча альбомнар булса, алар сәнгатьнең кайсы (киң яки тар) мәгънәсенә туры килер?

*2. Ни өчен сәнгатьне нәфис мәдәният белән тулысынча тәңгәлләштерергә түгел, ә якынайтырга гына кирәк. Аларның охшаш һәм аермалы билгеләре нәрсәдән гыйбарәт?

3. Сынлы сәнгать һәм әдәби иҗат нәрсә белән аерыла? Иҗади мөстәкыйльлек нәрсә ул?

4. Аңлатыгыз, нәфис мәдәният нәрсә ул, аңа нәрсәләр керә? Әдәбият, музыка, театр кая керәләр?

5. Нәфис мәдәниятнең төп субъектларын тасвирлагыз.

*6. Гүзәллек, Мәрхәмәт һәм Хакыйкать мәдәнияттә нинди роль уйныйлар?

7. Гүзәл сәнгатькә рәсем сәнгатен, скульптураны һәм архитектураны кертеп буламы? Гүзәл сәнгатькә үзегез мисал китерегез.

? **Проблема.** Гүзәллекнең гомуми критерийлары бармы? Шул мәсьәлә турында уйлагыз.

Практикум. Аңлатыгыз, ни өчен сәнгатькә бары тик элитар сынлы мәдәният әсәрләре генә кертелә?

§ 22 (§ 46). Мәгариф

Мәгариф җәмгыятьнең мөһим институты булып тора. Ул Мәгариф министрлыгын, урыннардагы шәһәр һәм региональ мәгариф департаментларын, мәктәпләрне, лицейларны, гимназияләрне, колледжларны, вузларны (университетларны, академияләрне), миллионнарча укучыларны һәм студентларны, укытучыларны һәм аларга хезмәт күрсәтүдә эшләүче белгечләрне берләштерә. Мәгарифнең төп бурычы ата-бабалар тарафыннан тупланган белемнәрне алдагы буыннарга тапшырудан гыйбарәт. Язу барлыкка килгәнче яшәгән җәмгыятьләрдә бу вазифа телдән башкарылган. Белемне иң гади юл белән тапшыру борынгы ыруглык җәмгыятендә үк барлыкка килгән һәм бүгенге көнгә кадәр сакланып калган (мәсәлән, Көньяк Африка бушменнарында). Картлар яшүсмерләргә хайваннарның гадәтләрен, тәҗрибәле аучының нинди хәйләләр куллануын, урманда юнәлешне ничек табарга икәнлеген, кайсы үсемлекләрне ашарга яравы, табигатьтәге сәер күренешләр, традицияләр һәм гореф-гадәтләр турында сөйлиләр һәм аларны күрсәтәләр. Әлбәттә, моны да мәгариф дип санарга мөмкин, төгәлрәк әйткәндә, бу аның беренчел формасы була.

Мәгариф, өлгереп җиткән социаль институт буларак, Борынгы Мисырда б. э. к. III меңьеллыкта барлыкка килә. Нәкъ шул вакытта *чиновникларның профессиональ мәктәпләре* ачыла. Башкача әйткәндә, укытучы һәм укучы статусы формалаша, яңа белемнәрне язып бару өчен махсус кулланмалар — хәзерге дәфтәр тиңнәре, белемнәрне тапшыру чаралары — дәреслекләр, махсус бүлмә (сыйныф бүлмәсе), дәресләр режимы, белемнәрне бәяләү системасы һәм тулаем мәгарифнең аерылгысыз атрибутлары барлыкка килә.

Б. э. ның II гасырында *Рим мәгариф системасы* формалаша, ул Европа мәгариф системасының беренчел үрнәге була. Бу система *өч баскычтан* тора. Башлангыч мәктәптә укырга, язарга, санарга өйрәтәләр. Икенче баскычта укытучы-грамматиклар грек телен һәм *ирекле җиде сәнгатьне* укыталар. Боларга грамматика диалектика, риторика, музыка, арифметика, геометрия һәм астрономия, шулай ук архитектура һәм медицина керә. Иң югары баскычта — риторлар мәктәбендә — риторика һәм философияне өйрәнәләр. Риториканы үзләштерү сәяси карьера өчен төп шарт булып тора.

IX гасырда *монастырьлар* балаларны бик кечкенәдән ук рухи һәм руханилык өлкәсе өчен әзерли башлыйлар. Укытучылар укучыларда киләчәктә чиркәү хезмәтенә урнашуга мөмкинлек бирәчәк сәләтләрне үстерергә тырышалар. Укучылар, кагыйдә буларак, мәктәпкә биш ел йөриләр, иң беренче чиратта уку һәм язу күнекмәләре алалар. Алар башта стиль (каләмне хәтерләткән очлы башлы таякчык — *Ред.*) белән балавыз тактага язарга өйрәнәләр, аннан соң каурый каләм белән пергаментка язалар. Китаплар аз булу сәбәпле (монахлар һәр экземплярны кулдан әзерлиләр), чиркәү хорларында җырлаучылар аз булганга, музыка дәресләренә дә күп вакыт бирелә. Укучылар антик әдәбият һәм латинча дини язмалар белән танышалар; шуңа күрә мәктәпләрдә латин телен өйрәнүгә зур игътибар юнәлтелә. Европада монастырь мәктәпләрендә дәресләр шул телдә алып барыла.

Башлангыч белем бирү баскычыннан соң *тривиум* килә, аңа грамматика, риторика һәм диалектика (әңгәмә алып бару осталыгы) керә. Тривиумнан соң *квадривиум* килә: арифметика, геометрия, музыка һәм астрономия. *Монастырь мәктәпләре* мөһим мәдәни роль башкара: алар җәмгыятьнең төрле катлауларыннан сәләтле балаларны эзләп табалар һәм тәрбиялиләр.

Русьта беренче мәктәпләр моннан мең елдан артык элек Киевта барлыкка киләләр. Уку 7 яшьтән башлана һәм ике ел дәвам итә. Укытучы кулъязма китаплардан берьюлы 8–10 балага белем бирә. Балалар йөзгә кадәр саный, исәпли беләләр. Археологлар VI–VII гасырларга караган уенчык-исәпләү жетоннары таптылар. Уку программаларында җырга күп урын бирелә. Өй эшләре булмый. Русьта кәгазь бары тик XIV гасырда гына барлыкка килә, шуңа күрә мәктәпләрнең тәэмин ителеше мактанырлык булмый.

Петр I гомуми белем бирүче дәүләт цифир мәктәпләре оештыра. Аларда арифметика, язу, уку дәресләре бирелә. Сыйныфта төрле яшьтәге балалар укый. Закон балаларны линейка белән кыйнарга, сыек чыбык белән суктырырга, почмакка бастырырга рөхсәт итә. Дворян балалары кадет (французчадан cadet — «кече») корпусларында (шляхта, диңгез, артиллерия корпусларында), хосусый пансионнарда, затлы нәсел кызлары институтларында белем алалар. Дворян кызлары 6 яшьтән 18 яшькәчә Смольный институтында укыйлар һәм тәрбияләнәләр,

Русьта беренче мәктәп

бу Россиядә хатын-кызлар өчен гомуми белем бирүче беренче уку йорты була. Аларга әдәбият, тарих, рус теле һәм чит телләр, физика, математика һ.б. укыталар. Биергә, кул эшләренә, күркәм гадәтләргә өйрәтәләр. Бу уку йортында режим катгый була һәм тайпылышсыз үтәлә: иртәнге сәгать 6 да йокыдан торалар, 6—8 дәрес укыйлар. Шәһәрдәге түбән катлау балалары өчен халык мәктәпләре һәм училищелары ачыла.

XIX гасырда мәктәпләрнең *гимназия* төре киң тарала. Уку өчен түләргә кирәк була. Гимназияләргә бары тик дворяннар һәм чиновниклар балалары гына керәләр. Дәресләр 60 минут дәвам итә. Әгәр укучыларның берәрсе үзен начар тотса, аны сыек чыбык белән суктыралар, карцерга утырталар, ашарга бирмиләр, мәктәптән куалар. Гимназия белән директор җитәкчелек итә, ә аңа инспектор булыша. Директорга барлык укытучылар буйсына. Алар тигез хокуклы булмый. Мәсәлән, җыр һәм гимнастика укытучылары бернинди ташламалардан файдаланмый. Хәзерге сыйныф җитәкчеләре урынына сыйныф остазлары һәм күзәтчеләре эшли, алар укучыларны тәрбияләү белән шөгыльләнәләр. Гимназияне тәмамлагач, укучылар өлгергәнлек аттестаты алалар.

Гимназияләр белән беррәттән *реаль училищелар* да киң таралыш ала, аларда төп игътибар табигать фәннәрен (биология, физика, химия) укытуга юнәлтелә. Бу уку йортларында сәнәгать, авыл хуҗалыгы, сәүдә өчен кадрлар әзерләнә.

XVII–XIX гасырларда өйдә укыту тарала. Балаларын укыту өчен ата-аналар билгеле бер түләү хакына укытучыларны өйләренә чакыра башлый. Нәкъ шул вакытларда күпсанлы ялган «педагоглар» күренә башлый. Рөхсәтсез дәрес бирүчеләрне штрафка тарталар. Өйдә укыган кызлар һәм егетләр, белем турында рәсми документ алу өчен, мәктәптә имтихан тапшыралар.

Мәктәптә алган белемне *гомуми белем* дип тә атыйлар. Ул сезгә табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге төп күренешләрне аңларлык, иҗтимагый һәм хезмәт эшчәнлегендә катнашырлык фәнни белем нигезләрен алырга мөмкинлек бирә. Гомуми белем *профессиональ (махсус)* белем алуда нигез булып тора. Гомуми белем алуның төп юллары гомуми белем мәктәпләрендә, урта профессиональ уку йортларында укудан гыйбарәт. Гомуми белем бирү баскычлары — башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта белем.

*Урта белем бирүнең нигезе — мәктәп (*латинча Schola, грекчадан schole*)*. Ул укыту-тәрбия системасының башлангыч тибына карый. Мәктәп дәүләт яки хосусый затлар һәм җәмгыятьләр хисабына яши. Тапшырылган белемнең характеры буенча барлык мәктәпләр дә гомуми һәм профессиональ (махсус) белем мәктәпләренә; белем баскычлары буенча — башлангыч, тулы булмаган, урта, югары мәктәпләргә; дингә мөнәсәбәт буеча дөньяви һәм дини (конфессиональ) мәктәпләргә бүленәләр.

Гомуми белемне дәүләтнеке һәм хосусый булган ике типтагы мәктәпләрдә алырга мөмкин. Хосусый мәктәпләр түләүле булалар һәм ата-аналар хисабына эшлиләр. Тегеләре дә, болары да гадәти мәктәп яки махсус гимназия һәм лицей рәвешендә булалар.

Белемне кадет корпусларында да алырга мөмкин (алар Россиядә 30), хәзер анда кызларны да кабул итәләр.

Американы куып җитеп узып киттек

Әгәр сез балаларыгызны мәктәпкә озатканда, бу мәктәпнең Америкада яки Англиядә булмавына үкенәсез икән, бер дә борчылмагыз. Дөньяның 40 илендә белем сыйфатын бәяләү буенча

үткәрелгән 1ЕА халыкара тикшерүләр күрсәткәнчә, безнең мәктәп балалары математика һәм табигать фәннәрен Америка һәм күпчелек Европа илләрендә яшәүче балаларга караганда яхшырак беләләр.

Тикшерүчеләр моны Россиянең иң күп китап укучы ил булуы белән аңлаталар. 50% гаиләнең өендә 100 китаптан да ким булмаган китапханә бар. Өстәвенә, Россиядәге ата-аналар дөньяда иң белемле ата-аналардан санала. Безнең мәктәп укучыларының 34%ы ата-аналарның берсе генә булса да югары белемле гаиләдә яшиләр. Мондый хәл бары тик Канадада, Израильдә, Литвада һәм Америкада гына күзәтелә, ә бу илләр халкының бер өлешен «элекке руслар» тәшкил итә.

Россия укытучылары башка илдәгеләргә караганда дәрескә әзерләнү һәм эшләр тикшерү, укучылар һәм ата-аналар белән сөйләшү, профессиональ әдәбият уку өчен күбрәк вакыт сарыф итә. Алар бу эшләргә атнага 18,5 сәгать вакытларын бирәләр. Япониядә исә бу күрсәткеч 5 сәгать кенә тәшкил итә. Шуңа да карамастан, нәкъ менә азиялеләрнең иң белемле халык булуы ачыкланды. Беренче урында Сингапур тора, аннан соң Көньяк Корея һәм Япония килә.

Европада иң яхшы 6 ил арасына Бельгия һәм Чехия Республикасы керә. Белемнәр буенча икенче баскычта 14 ил тора. Алар арасында Словакия Республикасы, Швейцария, Болгария, Россия, Франция, Таиланд, Израиль һәм Швеция бар. Өченче урында — Америка.

Шунысы кызык, Азия балалары үзләренә ошаганны да, ошамаганны да бик тырышып өйрәнәләр һәм яхшы билгеләр өчен мактау көтмиләр. Көнбатыш илләрендә исә балаларның уңышы предметның ошавы яки ошамавы белән турыдан-туры бәйләнгән.

Чыганак: АиФ.— 1997.— №40.

Хәзерге мәктәп тормышы билгеле бер кагыйдәләргә буйсына. Мәктәп устав буенча яши. Анда укучыларның һәм укытучыларның хокуклары һәм бурычлары язылган, идарә структурасы, укучылар белемен тикшерү системасы билгеләнгән. Дәүләтебез тарихында беренче устав 1786 елда кабул ителгән. Мәктәп белән директор идарә итә, аның урынбасарлары була. Укытучылар аерым предметлар буенча дәресләр алып баралар. Бу дәресләр төрле булырга мөмкин, чөнки хәзерге укытучының балаларны укыту һәм тәрбияләү методикасын ирекле сайлау хокукы бар. Укытучының үз-үзен тотышы хезмәт хокукы нормалары белән көйләнә.

Ун ел тоташ эшләүдән соң, укытучы бер еллык ялга китә ала. Дәресләрдә төрле дәреслекләр, әсбаплар кулланырга,

балалар белемен тикшерү буенча үз алымнарыңны уйлап табарга мөмкин. Билгеләр безнең илдә 1944 елда кертелгән биш баллы шкала буенча куелырга тиеш. Ата-аналарның укытучының профессиональ эшчәнлегенә тыкшынырга хаклары юк. Әмма алар мәктәп Уставы, һәм балалары алган билгеләр белән танышалар, белем бирү оешмасының идарә эшләрендә катнаша алалар.

Укытучының бурычлары хокук (закон) белән беркетелгән. Закон аннан бала шәхесен хөрмәт итүен, мәктәптә дисциплина саклавын таләп итә. Балаларга карата техник һәм физик басым куллану тыела. Укытучы дәрестә килеп чыгарга мөмкин булган бәхетсезлек очракларын булдырмый калу чараларын күрергә тиеш. Аның дәрескә алкоголь, наркотик, токсиннар кулланган хәлдә килергә хакы юк. Әгәр укытучы билгеләнгән кагыйдәләрне бозса, юридик җаваплылык алдына баса. Мәсәлән, балага карата рәхимсез чара кулланган өчен, ул җинаять җаваплылыгына тартыла. Мәктәп Уставын бозган очракта эштән куылырга мөмкин.

Укытучы хосусый практика белән шөгыльләнә ала. Мәсәлән, дәресләрдән соң балаларга француз теле өйрәтергә мөмкин. Бу эшмәкәрлек дип исәпләнә, шуңа күрә аның өчен укытучы акча ала, икенче төрле әйтсәк, аңа табыш килә.

Мәктәп эшенең гомуми мәсьәләләре *педагогик советта* хәл ителә. Бу барлык укытучыларның, шулай ук башка хезмәткәрләрнең (тәрбиячеләрнең, китапханәчеләрнең, методистларның) җыелышы. Күп кенә мәктәпләрдә *методик советлар*, балаларның фән җәмгыятьләре, кызыксынулары буенча оешкан һәртөрле төркемнәр эшли. Шулай ук мәктәпкә финанс ярдәме күрсәтүче хәйриячеләр (попечительләр) советы да бар.

Укучы — гомуми белем алучы баланың юридик статусы ул. 1–11 (12) сыйныфлар кысасында түләүсез белем алырга мөмкин. Балалар яшәгән урыннарындагы мәктәптә белем алырга хокуклы. Мәктәптә укучылар билгеле бер кагыйдәләргә буйсынырга (мәсәлән, дәресләргә йөрергә, килми калмаска, соңармаска, укытучы таләпләрен үтәргә) тиешләр. Кагыйдәләр мәктәп документларында теркәлгән. Алар гимназист уставы яки укучылар өчен кагыйдәләрдә, Имтиханнар турындагы нигезләмәдә яктыртыла. Һәр мәктәп үтәлүе мәҗбүри булган үз кагыйдәләрен эшли. Мәсәлән, кайбер мәктәпләрдә елына ике тапкыр зачет сессияләре кертелә, башкаларында исә чыга-

рылыш сыйныфлары өчен мәҗбүри булган гомуми имтиханнар гына уза.

Укучы бер мәктәптән икенчесенә күчә ала. Дәресләрдә иркле төстә үз фикерен әйтергә хокуклы. Әгәр дә ул күпчелек һәм педагог фикереннән үзгә булса? Сезнең мондый хокукларыгыз бар һәм бу очракта үзегезне тыныч һәм нык тотыгыз.

Укучы түләү нигезендә өстәмә белем дә ала. Ул һәр кеше өчен мәҗбүри түгел. Закон нигезендә мәктәп түләүле хезмәт тә күрсәтә. Кемдер музыка, кемдер чит телләр, ә кемдер бию белән шөгыльләнә. Уку планына керүче өстәмә дәресләргә укучылар бушлай йөри. Әгәр дә сез яхшы укыйсыз һәм үз белемнәрегез ныклыгына ышанасыз икән, башка балалар өчен репетитор була аласыз.

Сезнең һәрберегезнең яраткан һәм яратмаган уку предметларыгыз, укытучыларыгыз бар. Бу — кешеләр арасында була торган гадәти хәл. Хокук (закон) бу өлкәгә кысылмый. Ул укучыларны гел яхшы билгеләр генә алырга мәҗбүр итми. Ул бары тик хәзерге мәктәптә укып чыккан бала үзләштерергә тиешле белем минимумын гына күрсәтә.

Әгәр 14 яшькә җиткән укучы тупас рәвештә мәктәп уставын боза икән, аны мәктәптән куарга мөмкиннәр. Мондый карарны мәктәп идарәсе органы балигъ булмаганнар эшләре буенча Комиссия ризалыгы белән чыгара.

Хокук укучыларның мәктәптәге эшчәнлегенең катгый үрнәген күрсәтми, ә белем алу формасын (гаиләдә, экстернат ысулы), укытучыларны, белем бирү оешмасын сайлау мөмкинлеге бирә. Гаиләдә белем алучы бала мәктәптә теркәлгән булырга тиеш. Ата-аналар һәм белем бирү оешмасы арасында килешү төзелә, аның нигезендә укытучылар гаиләгә дәрес программаларын күрсәтәләр, консультацияләр бирәләр, белемнәрне тикшерәләр.

Мәктәпне тәмамлап, имтиханнарны тапшыргач, укучы өлгергәнлек аттестаты ала, ә аеруча яхшы укыган балаларга алтын һәм көмеш медальләр бирелә.

Төшенчәләр: *мәгариф системасы, мәктәп, гимназия, укучы.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәктәп үсешенең төп тарихи этапларын һәм типларын сыйфатлагыз.

2. Укучының төп хокукларын һәм бурычларын атагыз. Мәктәптә

сезнең тарафтан башкарылган һәм хокук нормалары белән көйләнмәгән гадәти гамәлләрегезгә мисаллар китерегез.

*3. Сезнең мәктәп Уставында теркәлгән имтиханнар бирү тәртибе турындагы кагыйдәләргә анализ ясагыз. Укучы имтиханнарда нинди проблемалар алдында калырга мөмкин? Аларны ничек хәл итеп була?

*4. Сыйныфта конфликт туды. Укытучы бер кыз балага чиреккә икеле билгесе куйды. Ул кыз, әнисе бик авыр хәлдә яту сәбәпле, ай буе дәресләргә әзерлексез килде. Аның сыйныфташлары укытучыдан кызның аңлатмаларын тыңлавын сорадылар, әмма ул алар үтенечен кире какты. Балалар бөтен сыйныфлары белән бу укытучы дәресләренә йөрүдән туктадылар. Бу ситуацияне хәл итегез. Ул хокук (закон) белән җайга салынырга мөмкинме?

5. Укучы даими төстә укытучылар белән бик тупас сөйләшә, дәресләрдә кычкырып көлә, бөтен сыйныф алдында мәзәкләр сөйли, дәрес биремнәрен үтәми. Укытучыларның таләпләренә: «Мин закон бозмыйм бит. Мәктәпкә йөрим, имтиханнар тапшырам», — дип җавап бирә. Бу җавабында ул хаклымы? Әлеге хәл нинди нормалар белән җайга салына?

*6. XXI гасыр мәктәбе проектын төзеп карагыз. Аның хакында мәктәптә сөйләгез.

Проблема. Сыйфатлырак белем бирү өчен хәзерге мәктәптә нәрсәләрне үзгәртергә кирәк?

Практикум. Америка педагоглары хәзерге мәктәптә укучыларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу кирәк дип исәплиләр. Мәсәлән, укытучы кайбер укучылар кыска җиңле күлмәктән йөрергә, ә икенчеләренә свитер кияргә рөхсәт итә, бу индивидуаль температура режимын сайлауны аңлата. Хәтта укучыларга идәндә утырып яки ятып торырга, берара стенага сөялеп утырырга рөхсәт итәргә мөмкин. Балаларны хәтта бер-берсеннән аерым утыртырга да ярый, бу аларның төркем белән яки мөстәкыйль эшләү ихтыяҗын канәгатьләндерергә ярдәм итәчәк. Сез мондый укыту тәртибен ничек бәяләр идегез?

§ 23 (§ 47). Фән

Фән — интеллектуаль эшчәнлекнең иң катлаулы өлкәсе. Тарихи яктан ул дингә, сәнгатькә һәм мәгарифкә караганда соңрак барлыкка килә. Гәрчә фәнни белемнең беренче яралгылары б.э.к. V гасырда Борынгы Мисырда һәм Борынгы

Греция җәмгыятьләрендә үк күренә башлый, ә аның чып-чынлап чәчәк ату чоры бары тик Яңа заманда XVI–XVII гасырларда гына күзәтелә, һәм ул фәнни-техник прогресс, индустриаль революция белән бәйләнгән була.

***Фәннең төп вазифасы** чынбарлык турында объектив белемнәр эшләүдән һәм аларны теоретик яктан системага салудан гыйбарәт.*

***Фәнни эшчәнлекнең максаты** — яңа белемгә ирешү.* Мәгарифнең максаты — яңа белемне кешеләрнең яңа буынына, ягъни яшьләргә җиткерү. Боларның берсе булмаса, икенчесе дә булмаячак.

Күпчелек Европа илләрендә ике процессны — яңа белем алуны һәм таратуны — үзмичә алып барырга тырышалар. Шуңа күрә университетлар фәнни һәм педагогик ике функцияне, ягъни вазифаны башкаралар. Университет профессоры — бер үк вакытта тикшеренүче дә, галим һәм практик-педагог та. СССРда һәм Россиядә башка төрле традиция урнашкан. Монда фән белән берәүләр, ә белем бирү белән икенчеләр шөгыльләнә. Фәнни эшчәнлекнең төп үзәге — Фәннәр академиясе, аның составында 300 ләп фәнни-тикшерену институты бар. Россиядәге университет профессоры профессиональ рәвештә фән белән шөгыльләнергә бурычлы түгел. Ул — иң элек укытучы.

РОССИЯ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ (РФА) 1991 елда СССР Фәннәр академиясе базасында төзелә. Аның тарихы 1724 елдан Петербург Фәннәр академиясеннән үк килә. 1994 елда анда 440 хакыйкый әгъза, 600 мөхбир әгъза, 120 чит ил әгъзалары исәпләнә. Фән тармаклары һәм юнәлешләре буенча 18 бүлекне берләштерә: математика; гомуми физика һәм астрономия; атом-төш физикасы; энергетиканың физика-техник проблемалары; информатика, исәпләү техникасы һәм автоматлаштыру; машиналар турындагы белемнәр, механика һәм идарә процесслары проблемалары; гомуми техник химия; физико-химия һәм неорганик материаллар технологиясе; биохимия, биофизика һәм физиологик актив кушылмалар химиясе; геология, геофизика, геохимия һәм таулар турындагы фән; океонология, атмосфера физикасы һәм география; тарих; философия һәм хокук; икътисад; дөнья икътисады һәм халыкара мөнәсәбәтләр; әдәбият һәм тел; региональ бүлекләр (Себер, Урал, Ерак Көнчыгыш) һәм фәнни үзәкләр. Барлыгы 300 фәнни оешма, 200 дән артык фәнни совет.

Фәнни тикшеренү флоты. Фәнни кадрлар әзерли. Фәнни әдәбият нәшер итә. Фәнни хезмәтләр өчен медальләр һәм премияләр тапшыра. Халыкара фәнни элемтәләр җәелдерә.

Чыганак: Кирилл һәм Мефодийның Зур энциклопедиясе.

Фәннәр академиясе белән беррәттән безнең илдә тармак академияләре дә бар: Медицина фәннәре академиясе, Авыл хуҗалыгы академиясе, Педагогика фәннәре академиясе. Тармак ФТИлары — министрлыкларга һәм ведомстволарга буйсынучы һәм алар тарафыннан финансланучы фәнни-тикшеренү институтлары алар. Әгәр академик институтлар төп фәннәрне үстерсәләр, тармак ФТИлары гамәли фән белән шөгыльләнәләр, ягъни төп фән белемнәрен билгеле бер техник бурычлар башкаруга көйлиләр.

Фәнни процесс нигезендә мәгълүмат тапшыру ята. Ул объектив, дөрес, системалы булырга тиеш. Җәмгыять фәнне хакыйкатькә ирешүче соңгы нокта итеп карый. Шул ук вакытта мифтан, экияттән, романнан беркем дә дөреслек һәм хаклык эзләми. Фән хакыйкатьне эзләү һәм раслау максатында тудырыла. XVII гасырдан башлап, фәнни мәгълүматның күләме һәр 10–15 ел эчендә икеләтә арта.

Дәреслекләрдә һәм фәнни монографияләрдәге мәгълүматлар дөрес һәм объектив булырга тиеш, чөнки алар алдагы буыннарга тапшырыла. Мәгълүмат дөреслеген бозган кешеләр өчен махсус санкцияләр кулланыла һәм бу мәгълүматның дөреслеге контрольдә тотыла, аерым алганда, ялган мәгълүмат җиткергән өчен мәкалә авторын судка тартырга мөмкиннәр, ә журнал һәм газета редакциясендә исә мәкаләдә кулланылган төп документлар саклана. Мәкаләдә файдаланылган әдәбият исемлеге һәр укучыга галим язган һәр фактны тикшереп карау мөмкинлеге бирә.

Энциклопедияләр, сүзлекләр, географик атласлар, төрле күрсәткечләр, альманахлар, норматив һәм юридик документлар, статистик күрсәткечләр һәм таблицалар, схемалар, рәсемнәр, иллюстрацияләр һ.б. объектив эш торышы турында фактик мәгълүмат җиткерәләр, күбрәк булган саен аларның әһәмияте үсә бара.

Барлык фәннәр шартлы рәвештә табигать, җәмгыять, гуманитар һәм техник фәннәргә бүленәләр. *Социология, пси-*

хология, социаль психология, икътисад, политология, шулай ук *антропология* һәм *этнография* ***социаль фәннәргә*** керәләр. Аларның уртак яклары күп, бу фәннәр үзара тыгыз бәйләнгәннәр, үзенә күрә фәнни союз барлыкка китерәләр. *Философия, тарих, сәнгать белеме, әдәбият белеме* кебек әлеге фәнни союзга охшаш башка дисциплиналар аның белән янәшә торалар. Аларны ***гуманитар белемгә*** кертәләр. Һәм бу дөрес тә. Социаль фәннәр *микъдари* (математик-статистик) алымнар белән, ә гуманитар фәннәр, бик сирәк очракларны исәпкә алмаганда, *сыйфат* (тасвирлау-бәяләү) алымнары белән эш итәләр. Гуманитар дисциплиналарны кешеләрнең *үз-үзләрен тоту турындагы фәннәргә*, ягъни аларның төркемнәрдә, институтларда, базарда яки сәяси вакыйга-хәлләрдә үз-үзләрен тотуларын өйрәнүче фәннәргә кертеп булмый, ә социаль фәннәрне исә андыйлар исәбенә кертергә мөмкин. Шуңа күрә аларны *бихевиориаль фәннәр* (behaviour — үз-үзеңне тоту) дип атыйлар.

Социаль һәм гуманитар дисциплиналардан тыш ***табигать турындагы*** һәм ***техник*** фәннәр дә бар. *Физика, химия* һәм *биология* табигать турындагы фундаменталь фәннәргә керәләр, алар матди дөнья төзелешен ачалар. *Радиоэлектроника, биотехнология* һәм *полимерлар химиясе* техник дисциплиналарны, яки практик белемнәрне тәшкил итәләр. Алар фундаменталь белемгә нигезләнәләр һәм практик максатларга хезмәт итәләр.

Мәктәп белеме — зур фәнгә илтүче иң тәүге баскычлар ул. Ул сезгә табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге төп күренешләрне аңлау өчен кирәкле иң гади фәнни белемнәрне үзләштерергә ярдәм итә. Башкача әйткәндә, ул сезне фәнни белем нигезләре белән таныштыра. Югары белем исә аларны тагы да киңәйтергә ярдәм итә. Аспирантура һәм докторантурада уку сезгә *яңа белемнәрне үстерү* белән шөгыльләнергә булышачак. Ә бу академик фәндә иң төп әйбер санала.

Югары белем алуның нигезе — *вузлар.* Алар, урта белем базасында хуҗалыкның, фәннең һәм мәдәниятнең төрле тармаклары өчен белгечләр әзерлиләр, укытучыларның квалификацияләрен күтәрүне тормышка ашыралар. Вузларга университетлар, институтлар, югары училищелар, уку-укыту академияләре, консерваторияләр керә. Уку вакыты — 4–7 ел.

Университет (латинчадан universitas — кушылма, бергәлек) — югары уку йорты һәм фәнни оешма, анда фундамен-

таль һәм күпсанлы гамәли (практик) фәннәр буенча һәм халык хуҗалыгының, мәдәниятнең төрле тармакларында эшләүче белгечләр әзерләнә.

Беренче университетлар XI– XII гасырларда Италиядә, Испаниядә, Франциядә, Англиядә барлыкка киләләр. Студентлар һәм профессорлар шәһәрләрдән бәйсез булу, үзидарә хокукы алу өчен университетларга берләшәләр. Университет «якташлык җәмгыятьләре»нә — теге яки бу ил студентлары берләшмәсенә һәм теге яки бу белемнәрне бирүче факультетларга бүленә. Университетларның махсуслашуы да күзәтелә: риторика һәм дини хокукны өйрәнү буенча Болонья университеты иң эре үзәк санала. Парижда, теология үзәге булып танылган Сорбонна университетында латин телендә укыталар. Урта гасырларда университетларда студентлар теология, хокук, медицина һәм философияне өйрәнәләр.

Академик университет (1726–1766, Санкт-Петербург) һәм Мәскәү университеты (1755) Россиядә иң беренче университетлар була; 1916 елда аларның саны 11 гә җитә. 1994 елда Россия Федерациясендә 40 тан артык дәүләт университеты, техник, медицина, педагогик, аграр һ.б. профильдәге 80 дәүләт университеты, 40 тан артык дәүләтнеке булмаган университет исәпләнә.

М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты (МДУ) хаклы рәвештә илнең иң яхшы университеты булып исәпләнә. Ул дөнья фәне үзәкләренең берсе һәм иң эре уку йорты. Университет 1755 елда М.В. Ломоносов һәм граф И.И. Шувалов инициативасы буенча төзелә. Анда философия, юридик һәм медицина факультетлары эшли. Бүген физика, математика, химия, биология, геология, филология, тарих, философия, психология, юриспруденция һәм башка фәннәр, белгечлекләр буенча кадрлар әзерли. Университетта 200 дән артык кафедра һәм 430 фәнни-тикшерену лабораториясе, 4 ФТИ (механика, атом-төш физикасы, П.К. Штернберг исемендәге астрономия, Д.Н. Анучкин исемендәге антропология фәнни-тикшерену институтлары), Исәпләү үзәге, 4 обсерватория, 12 фән-укыту станциясе, 3 музей, Ботаника бакчасы, фәнни китапханә, нәшрият (1927 елда ачылган) бар. 1992 елда университет Россиянең үзидарә статусына ия булган югары белем бирүче дәүләт уку йортына әверелде. Монда РФнең төрле

почмакларыннан һәм чит илләрдән килгән студентлар белем ала.

Югары белем системасында әһәмияте буенча икенче урында *академия* тора. «Академия» сүзе Афина тирәсендәге бер урын атамасыннан килеп чыккан, анда Платон академиясенә нигез салынган (якынча б. э. к. 387 ел).

ПЛАТОН АКАДЕМИЯСЕ

Бу б. э. к. 387 елда Афинада Платон тарафыннан ачылган борынгы грек фәлсәфә мәктәбе була, ул б. э.ның I гасырына кадәр яши. Платон академиясе төзелгәнче яшь афиналылар югары белемне софистларда алалар (грекчадан тәрҗемә иткәндә, «софист» «оста», «акыл иясе», «ялган акыл иясе» мәгънәсен белдерә). Софистлар, бер шәһәрдән икенчесенә күчеп йөреп, ораторлык осталыгын камилләштерү һәм философия буенча үз киңәшләрен һәм тәкъдимнәрен бирүче сәяхәтче лекторлар булалар. Алар Афина тирәсендә урнашкан өч иң эре җәмәгатьчелек гимназияләренең (gymnasiums) берсендә генә булса да аудитория табачакларына шикләнмиләр. Платон үз сәяхәтләреннән Афинага әйләнеп кайткач (якынча б.э.к. 387 ел), академия дип аталган бер гимназиядән ерак түгел йортта урнаша. Гимназия шәһәр стеналарыннан төньяк-көнбатышка таба бер миль ераклыкта урнашкан була. Платон даими тыңлаучылары булган философия мәктәбе төзи, алар академиядә яки Платон йортында очрашалар. Башка философлар да аның үрнәгендә үз укучылары белән билгеле бер урында очраша башлыйлар, алар анда лекцияләр укыйлар, әңгәмәләр үткәрәләр. Платонның укучысы Аристотель Афинаның көнчыгышында урнашкан Лицейда (Lyceum) үз мәктәбен булдыра.

Платон академиясе традициясе Афинада урта платонизм (I гасыр уртасы — II гасыр) һәм неоплатонизм (IV гасыр — VI гасыр уртасы) мәктәпләрендә кабат яңара. Яңарыш дәверендә Платон академиясе Флоренциядә төзелә (1459-1521), аның белән М.Фичино җитәкчелек итә.

«Академия» терминын еш кына урта гасырларда Шәрекътә таралган фәнни түгәрәкләргә карата да кулланалар. XV–XVI гасырларда күпсанлы Европа фәнни җәмгыятьләре дә «академия» дип аталган. XVII гасырда беренче фәннәр академияләре формалаша.

XVI–XVII гасырлар чигендә Флоренциядә, Венециядә, Феррарда, Неапольдә бер-бер артлы «академияләр», яки «кameratlar» — иҗат түгәрәкләре барлыкка килә, алар гүзәллек дөньясын сөючеләрне, шагыйрьләрне һәм музыкантларны берләштерәләр. Анда яңа мадригаллар башкарыла, шагыйрьләр әле генә язган шигырьләрен укыйлар, анда музыка уйныйлар, милли сәнгатьнең киләчәге турында фикер алышалар. Бу академияләр яңа музыка языла торган иҗат лабораторияләре була. Нәкъ шул рәвешле 1600 елда Флоренциядә опера туа. Аның заманча булуы һәм яңалык алып килүе гаять югары бәяләнә.

Бүген Англиядә һәм АКШта хосусый урта мәктәпләрне һәм махсус уку йортларын академия дип атыйлар. Мәсәлән, хәрби-диңгез академияләре шулар рәтеннән. Киңрәк мәгънәдә (кайбер илләрдә) академияләр фәнни-тикшеренү бергәлекләре була. Алар фәнни белемнәрне, мәдәниятне үстерәләр, үзенчәлекле сәнгать һәм фәннәр үсешенә булышлык итәләр.

Фәнни-тикшеренү бергәлекләре арасында кардинал Ришелье тарафыннан 1635 елда оештырылган Француз Академиясе — әдәбиятчылар ассоциациясе — иң танылганнардан санала.

Төшенчәләр: *фән, университет, академия.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Социаль институт буларак фән нәрсә ул? Аның җәмгыятьтәге роле нинди?
2. Фәнни мәгълүматка нинди сыйфатлар хас?
3. Фәннәр академиясенең һәм олы фәннең структурасы нинди? Сезнең әти-әниләрегез яки танышларыгыз фән белән бәйләнгәнме? Җәмгыять тормышының бу мөһим өлкәсе турында алар нәрсә сөйләргә мөмкин?
4. Фәннәр ничек классификацияләнә? Җәмгыять белемен сез кая кертер идегез?
5. Югары белем бирү нинди элементлардан төзелә? Хәзерге дөньяда нинди профессияләр югары белем белән бәйләнгән?
6. Европадагы университет һәм Россия университеты нәрсә ул?

*7. Безнең көннәрдә университет дәрәҗәсе никадәр югары?

Проблема. Мәгълүмат ташкынының елдан-ел артуын сез көндәлек тормышыгызда тоясызмы? Мисаллар китерегез. Бу хәл җәмгыятьне һәм аның гражданнарын нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?

Практикум. Бу цифрлар турында уйланыгыз. Сез аларда нинди тенденция яки закончалык таптыгыз?

1. СССРда ачышларның 34% ы 50 нче елларга туры килә.
2. СССРда ачышларның 46% ы 60 нчы елларга туры килә.
3. СССРда ачышларның 18% ы 70 нче елларга туры килә.
4. СССРда ачышларның 2% ы 80 нче елларга туры килә.

Йомгаклау сораулары

1. Нәрсә ул сәясәт һәм аның җәмгыять тормышында роле нинди?

2. Сәяси хакимиятнең табигате нидән гыйбарәт?

3. Хакимиятләр бүленеше нәрсә ул?

4. Дәүләт ничек формалаша һәм аның функцияләре нидән гыйбарәт?

5. Сезгә идарә итүнең нинди формалары мәгълүм?

6. Милли-дәүләт төзелеше нәрсә ул?

7. Нинди сәяси режимнар була?

8. «Граждан» һәм «гражданлык» төшенчәләре үзара ничек бәйләнгән?

9. Гражданнар сәяси тормышта ни рәвешле катнашалар?

10. Нәрсә ул сайлаулар һәм референдум?

11. Сез нинди партияләр белән таныштыгыз һәм алар эшчәнлекләрен ничек алып баралар?

12. Бер һәм күп партиялелек нәрсә ул?

13. Хәзерге Россиядәге нинди сәяси реформалар турында сөйли аласыз?

14. Сезгә хокукның нинди тармаклары мәгълүм?

15. Хокук һәм закон үзара ничек бәйләнгән?

16. Ни өчен Конституция — дәүләтнең төп законы?

17. Россия Федерациясенең конституцион строй нигезләре нинди?

18. Закон чыгаручы, башкарма һәм суд хакимиятләренең вазифалары (функцияләре) нинди?

19. Президентлык институты нәрсә ул?

20. Җирле үзидарә ничек эшли?

21. Кеше хокуклары нәрсәдә чагылыш таба?

22. «Кеше хокукларының гомуми функция»сендә нәрсәләр теркәлгән?

23. Халыкара гуманитар хокук нәрсә ул?

24. Балалар һәм өлкәннәр хокукы ничек яклана?

25. Гражданлык җәмгыяте һәм хокукый дәүләт арасында нинди охшашлык бар?

26. Җинаять нәрсә ул?

27. Җинаять җаваплылыгы нәрсәдән гыйбарәт?

28. Административ гаеп эш нәрсә ул?

29. Хокук саклау органнары ничек эшли?

30. Җәмгыять нәрсә ул һәм нинди сфералардан тора?

31. Җәмгыятьнең төп билгеләре нинди?

32. Җәмгыять табигатькә ничек йогынты ясый, һәм табигатькә антропоген басым нәрсәләрдә чагыла?

33. Фәндә җәмгыятьнең нинди типларга бүленеше кабул ителгән? Индустриальлеккә кадәрге, индустриаль һәм постиндустриаль җәмгыять нәрсә ул?

34. Социаль һәм фәнни-техник прогресс нәрсәләрдә чагыла?

35. Кешенең глобаль проблемаларын сез ничек характерлыйсыз?

36. Дөнья бергәлеге нәрсә ул?

37. Кеше ничек шәхес булып әверелә?

38. Социальләшү һәм тәрбия нәрсә ул?

39. Кешенең нинди ихтыяҗлары булуын билгелегез?

40. Кешенең дөньяны һәм үзен танып-белүе ничек бара?

41. Кешенең рухи тормышы нидән гыйбарәт?

42. Ирек һәм җаваплылык үзара ничек бәйләнә?

43. Кеше төркемдә үзен ничек тота?

44. Аралашу процессында шәхесара мөнәсәбәтләр нәрсә ул?

45. Җәмгыятьтә конфликтлар ничек барлыкка килә һәм алар ничек хәл ителә?

Йомгак

Без кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең мавыктыргыч дөньясына сәяхәтебезне төгәлләдек. Ул мөнәсәбәтләрне җәмгыять белеме өйрәнә. Ә җәмгыять белемен без җәмгыятьнең нәрсә булуын тасвирлаудан, аның кеше белән үзара йогынтысы, социаль, икътисади һәм сәяси структурасы нинди булуын өйрәнүдән башлап җибәрдек. Без шәхеснең нәрсә булуын, аның рухи дөньясы ничек формалашуын, кешене әйләндереп алган тирәлекнең (гаилә һәм кечкенә төркем) нинди булуын белдек, милли мөнәсәбәтләр һәм социаль конфликтлар, мәдәният һәм дин белән таныштык. Үз юлыбызда без кыргый кабиләләр, онытылган халыклар, борынгы цивилизацияләр белән очраштык. Алардан тыш әле безне югары дәрәҗәдәге компьютерлы җәмгыятьләр, дөнья бергәлеге, глобаль проблемалар, рухи өлкә, мәдәният һәм дин үсеше, икътисад, хокук һәм сәясәт каршы алды.

Без җәмгыять белеменең төп предметы дип әйтергә мөмкин булган гражданлык җәмгыятен анализладык. «Гражданлык җәмгыяте» төшенчәсе башкаларга караганда демократиянең асылын тагы да ныграк чагылдыра. Чөнки бу ирекле, мөстәкыйль шәхесләр җәмгыяте, алар иң киң колачлы сәяси гражданлык хокукларына ия, актив төстә дәүләт белән идарә итүдә катнашалар һәм үз фикерләрен ирекле рәвештә әйтә алалар. Кешенең эчке дөньясы аның ихтыяҗларыннан, ниятләреннән һәм максатларыннан гыйбарәт, алар аның эшчәнлеген һәм үз-үзен тотышын билгелиләр. Кешенең җәмгыятькә керү процессы, аңа яраклашуы фәндә «социальләшү» дигән исем алды. Ул кеше тормышының барлык этаплары — балачагы, үсмерлек еллары, өлкәнлек һәм картлык чорлары аша уза. Без кешенең турыдан-туры социаль тирәлеге — шәхесара мөнәсәбәтләр, якыннар һәм танышлар белән аралашуы, җәмгыятьтә үз-үзен тоту культурасы, массакүләм мәгълүмат чараларының кешегә йогынтысы белән таныштык, социальләштерү

агентлары дип аталганнарның (ата-аналар, туганнар, дуслар, мәктәп, университет, армия, җитештерү — эш урыны, диннең) нинди роль башкаруларын белдек.

Китапта җәмгыять катлаулы дөнья системасы буларак күрсәтелә, монда аның төп сфераларының үзара бәйләнеше, кешенең глобаль проблемалары, социальләшү һәм тәрбия процессында кешенең биологик һәм мәдәни эволюциясе, җәмгыятьнең социаль һәм икътисади структурасы, сәяси системасы, гражданлык һәм кеше хокуклары, мәдәният һәм аның чагылышлары ачыла.

Сез җәмгыять белеменең икътисад, сәясәт, хокук, мәдәният, дин, философия, җәмгыятьнең социаль сферасына караган күптөрле белем өлкәләре буенча бик күп мәсьәләләрне колачлавын төшендегез. Ул философия, психология, социаль психология, икътисад, социология, антропология, политология, дәүләт һәм хокук кебек янәшә торган дисциплиналар бергәлеге белән таныштыра. Теге яки бу фән кебек үк, җәмгыять белеменең дә предметы һәм конкрет тикшеренү алымнары бар.

Кайчандыр үзем дә 8 нче һәм 9 нчы сыйныфларда укыдым. Шуннан бирле 30 елдан артык вакыт узды, әмма безнең тарих укытучысының үз укучыларында җәмгыять белеменә карата нинди кызыксыну уята алуын әле дә хәтерлим. Гаҗәеп педагог буларак, ул бездә социаль белемнәргә карата 5 нче сыйныфтан ук мәхәббәт тәрбияләде. Нәкъ шул вакытта, атнасына ике тапкыр, аның дәресләрендә без 15 минутлык сәяси мәгълүмат алышулар оештырдык. Сәясәттән башлап без акрынлап социаль һәм фәлсәфи мәсьәләләргә күчә идек. Шунысы гаҗәп, сыйныфташларымның сәяси мәгълүмат алышуларда кабынган кызыксынуы соңрак тарих, әдәбият һәм табигать фәннәре белән кызыксынуга күчте. Мәктәп балаларында дөньяны танып-белүгә карата ныклы кызыксыну формалашты. Тора-бара күп кенә сыйныфташларым вузларга керү өчен уңышлы имтихан тапшырдылар.

Безнең заманда кызыклы китаплар аз иде. Бүгенге көн белән чагыштырганда гаять аз. Җәмгыять белеме дәреслеге шулкадәр аңлаешсыз һәм коры тел белән язылган иде ки, без аны бары тик чираттагы карикатураны төшерер өчен генә ачкаладык. Әмма сыйныф җитәкчесе безгә мәктәп дәреслеге кысаларыннан тыш яшәүче колач җитмәслек дөньяны ачты. Без китапханәдә бөек кешеләр биографияләрен эзләдек, дөнья

барлыкка килү серләрен, тарихи хроникалар, дөнья мәдәнияте истәлекләрен өйрәндек. Мин бүген шуны аңладым: минем белем нигезем нәкъ шул чакта — ерак үсмерлек елларымда, иҗтимагый фәннәрне өйрәнгәндә салынган.

Сез киләчәктә икътисадчылар, психологлар, юристлар, тәрҗемәчеләр, тарихчылар, инженерлар, социологлар булырсызмы, әллә мәдәният белгечләренә әверелерсезме, барыбер җәмгыять белеме нигезләрен белү бик кирәк. Һәм белем кыясына күтәрелүне никадәр иртәрәк башласагыз, шулкадәр яхшырак. Мәгълүмат колачы һәр ел саен киңәя бара, танылып белүдә алгы рәтләргә чыгу өчен, сезгә киләчәктә ул мәгълүмат чытырманлыкларын үтеп чыгарга туры килер. Фәнни белем һаман да киңәюгә сәләтле. Мәктәптә җәмгыять белеме нигезләрен өйрәнгән кешеләр әйләнә-тирә дөньяга башка күз белән карый башлыйлар, аның законнарын аңлыйлар, үз карьераларын һәм шәхси тормышларын уңышлырак коралар — тәҗрибә шуны раслады.

Газеталарны һәм журналларны күбрәк укыгыз, телевидение буенча кызыклы тапшыруларны карагыз — бернинди дә файдалы мәгълүматны ычкындырмагыз. Ул, кызганычка каршы, искерү генә түгел, ә онытылу сыйфатына ия. Нәрсәдер хәтердә сакланып калсын өчен, аны бик күп тапкырлар кабатларга туры килә. Һәм моның барысы өчен вакыт, ә иң мөһиме — түземлек һәм тәртипле булу таләп ителә. Үзегезне аңлашылмаган һәм сезнең өчен кызыгы булмаган нәрсәләрне җентекләп өйрәнергә мәҗбүр итегез. Кагыйдә буларак, башта иң күңелсез һәм авыр тоелган эш иң кызыклысы булып чыга. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, 70–80% очракта нәкъ шул хәл күзәтелә. Кешегә үз хезмәтен куеп табылганнар гына ошый башлый. Үземнән беләм: аңлашылмаслык итеп бирелгән һәм ышандырмый торган материалдан гыйбарәт булган дәреслекләр еш кына теге яки бу фәнгә карата кызыксынуны бетерәләр. Кеше мие һәр нәрсәдә закончылык һәм мантыйк (логика) табарга тырыша. Аңлашылмаган нәрсәләрнең 50% ы мантыйкка сыймый, расланмаган мәгълүмат ул.

Бары тик математика һәм физика гына раслана һәм ышандыра дип уйлап дөрес булмас иде. Икътисад, хокук, политология, социология, философия, антропология, психология кебек җәмгыять турындагы фәннәрнең дә үз логикасы һәм ышан-

дыру күче бар. Аларны таба белергә һәм укучыга җиткерергә генә кирәк.

Иҗтимагый фән махсус ысуллар — сораштыру, интервью, күзәтү, статистик анализ, эксперимент — ярдәмендә табылган катгый белемнәрдән гыйбарәт. Шул юллар белән алынган мәгълүматка галимнәр математик статистика алымнары нигезендә классификация ясыйлар һәм эшкәртәләр. Нәтиҗәдә логик яктан каршылыксыз һәм тәҗрибә белән расланган җәмгыять һәм кешеләрнең үз-үзләрен тотышы турындагы белемнәр системасы барлыкка килә. Җәмгыять турындагы фәннәр — логик яктан төзек һәм ышанычлы, дөрес белем системасы ул. Алар социаль процесслар агымында закончалыклар һәм тенденцияләр чыгарырга, киләчәк вакыйгаларны алдан күрергә, вакыйгалар барышын үзгәртергә мөмкинлек бирәләр.

Бу дәреслек авторы үтәп булмаслык максатлар куймады. Аның бурычы сезне иҗтимагый фәннәргә алып керүдән, җәмгыять проблемалары буенча белем минимумы бирүдән, традицион һәм иң яңа мәгълүматларны җәмгыять турындагы төп фәннәр профиле буенча хикәяләп бирүдән, хәзерге заман җәмгыять белеме проблемалары буенча үз фикерегезне булдыруга этәрүдән гыйбарәт. Танып-белү эшчәнлегегезне активлаштыру сезнең шәхес буларак үзбилгеләнүегезгә ярдәм итәчәк.

Әмма җәмгыять турындагы фәннәр дөньясына сәяхәтебез моның белән генә тәмамланмый. Ул 10 нчы һәм 11 нче сыйныфларда да дәвам итәчәк. Дөрес, тагын да җентеклерәк һәм җитдирәк сөйләшү булачак. Бүген сез фәнгә кереп китү өчен кирәкле терминнар һәм төшенчәләр минимумы белән таныштыгыз. Әмма әле сез объектив чынбарлыкның тирән каршылыкларын ачучы проблемаларга кагылмадыгыз (яки бик аз күләмдә генә кагылдыгыз), икътисад, социология, хокук, культурология, психология, философиянең соңгы казанышлары белән танышмадыгыз. Димәк, алда әле сезне иң кызыклы нәрсәләр белән очрашу көтә.

Абсолют ярлылык — индивидның үз табышы хисабына азыкка, торакка, киемгә, җылыга булган иң төп ихтыяҗларын да канәгатьләндерә алмавы яки бары биологик җан асрауны тәэмин итәрлек кенә минималь ихтыяҗларын канәгатьләндерә алу хәле.

Абстракт — (латинчадан abstractio — читләшү) — тормыштан аерылган, читләшкән, теоретик.

Авторитар (латинчадан auctoritas — хакимият) — шәхси хакимияткә, шәхси диктатурага нигезләнгән.

Авторитет (латинчадан auctoritas — хакимият, йогынты) — белемнәргә, әхлакый абруйга, тәҗрибәгә нигезләнгән йогынты.

Аграр (латинчадан agrarius) — җиргә кагылышлы; җир биләүгә, җирдән файдалануга кагылышлы; мәсәлән, аграр мәсьәлә.

Адаптация — физик һәм социаль тирәлеккә яраклашу.

«Ак якалар» — автоматлаштырылган җитештерү өлкәсендә, фәнни һәм гамәли камилләштерүдә, шулай ук мәгълүмат сферасында эшләүче хезмәткәрләр.

Акцепт (латинчадан acceptus — кабул ителгән) — тәкъдимдә (офертада) күрсәтелгән шартлар нигезендә шартнамә төзү белән килешү (гражданлык хокукында).

Акциз (французчадан accise) — читләтелгән (кыек) салым төре; сатып алучыдан кайбер төр товарлар алганда үзләштерелә, бу товарның бәясенә карата процентлар белән билгеләнә.

Акча — алмашу мөнәсәбәтләрен тормышка ашыру чарасы, гомуми эквивалент.

Альтруизм (французчадан altruisme, латинчадан alter — башка) — башкалар иминлеге турында ихлас күңелдән кайгырту; эгоизмның капма-каршысы.

Амораль — әхлаксыз.

Андеграунд — формаль булмаган сәнгать.

Андерсыйныф — җәмгыятьтә кешелек һәм сыйнфый йөзен югалткан элементлардан (исерекләр, наркоманнар һ. б.) торучы катлау.

Анимизм (латинчадан anima, animus — җан, рух) — рухлар һәм җан булуына ышану.

Аномия (французчадан anomia — законның, оештыруның булмавы) — иҗтимагый аң халәте. Кыйммәтләр системасының таркалуы һәм җәмгыять кризисы, игълан ителгән максатлар һәм аларны чынга ашыру мөмкинлеге булмау аркасында туган каршылык белән характерлана.

Антропоген йогынтылар (грекчадан anthropos — кеше, genes — тудыручы) — кеше эшчәнлегенең табигатькә төрле йогынтысы формалары. Мәсәлән, аны пычрату.

Артефакт (латинчадан artefactum — ясалма) — кеше тарафыннан ясалган, әзерләнгән предмет.

Аскетизм (грекчадан asketes — күнекмәләр ясаучы) — философия мәктәпләренә (мәсәлән, киниклар һәм циниклар мәктәпләренә) һәм аеруча төрле диннәргә (монахлык һ.б.) хас тойгы-теләкләрен чикләү яки бастыру, үз тәләгең белән физик авырту кичерү, ялгыз калу.

Ассимиляция — бер халыкның (кайчакта берничә халыкның) башка халык эчендә эреп югалуы, этник яктан йотылуы.

Атеизм (грекчадан atheos — алласыз) — Алланың барлыгын инкарь итү һәм шуның белән бәйле рәвештә динне танымау.

Атрибутлар (латинчадан attribuo — өстим, бирәм) — зарур, әһәмиятле сыйфат.

Ачык җәмгыять — бер катлаудан икенче катлауга күчү рәсми рәвештә чикләнмәгән җәмгыять.

Базар (инглизчә market) — сатып алучыларны (сораучыларны) һәм сатучыларны (тәкъдим итүчеләрне) бергә очраштыручы теләсә кайсы институт яки механизм.

Байлык — кеше ия булган барлык нәрсәләрнең акчалата суммасы.

Башкаручы (җитештерүче яки әзерләүче) — эшмәкәр статусына ия булган оешма яки граждан.

Бәя — товар яки хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен түләнә яки алына торган акча (яки башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр) күләме.

Бизнес — эшмәкәрлек төре.

Буш вакыт — кеше үзе теләгәнчә файдалана торган вакыт.

Бүләкләү — хезмәт өчен мораль яки матди яктан билгеләп үтү, бүләк тапшыру.

Бюджет — билгеле бер вакыт аралыгы өчен керемнәр һәм чыгымнар суммасын күрсәтүче финанс планы.

Вакыт исәбеннән түләү — күпме продукция җитештерүдән бәйсез рәвештә, эшләгән сәгатьләр саны буенча түләү.

Вакыт бюджеты — аерым хезмәткәрнең һәм аның гаиләсенең, шулай ук билгеле бер халык төркеменең вакытны нинди файдалану төре буенча тотуын билгеләүче күрсәткечләр системасы.

Вәгъдә куешу — аерым затларның гражданлык хокукларын һәм йөкләмәләрен (бурычларын) урнаштыруга, үзгәртүгә яки юкка чыгаруга юнәлдерелгән эш-гамәлләре.

Вәхи — илаһи затның (Алланың) турыдан-туры ихтыярын, теләген белдерү яки, кеше гамәлләренең һәм танып белүнең абсолют критерие буларак, Алладан иңүче гыйлем.

Вестернизация — (инглизчәдән western — көнбатышныкы) Көнбатыш мәдәнияте кыйммәтләренең Көнбатышныкы булмаган җәмгыятьләргә дә таратылуы.

Виза — башка илгә керү хокукын бирүче документ.

Виталь — (латинчадан vitalis — тормышчан) — тормышчан.

Гадәтләр — билгеле бер ситуацияләрдә үз-үзеңне тотуның инде урнашкан схемасы (стереотип).

Гади хокук — дәүләт тарафыннан рөхсәт ителгән язылмаган кагыйдәләр җыелмасы.

Гаепсезлек презумпциясе принцибы — бу кагыйдә буенча бары тик суд кына кешене җинаятьче дип таный ала һәм аңа җәза чарасын билгели.

Гаилә — өйләнешүгә яки кан кардәшлегенә корылган, уртак көнкүреш, үзара ярдәмләшү, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән кечкенә төркем.

Гаилә бюджеты — аерым бер гаиләнең билгеле бер вакыт берәмлегендәге (ай, ел) барлык чыгымнары һәм керемнәре.

Гаиләнең тормыш циклы — гаилә тормышындагы әһәмиятле, этаплы вакыйгалар эзлеклелеге. Ул өйләнешкән көннән башланып китә һәм аерылышу белән тәгалләнә.

Генотип (грекчадан genos — токым, чыгым, typos — салынган

эз, форма, үрнәк) — организмның генетик (нәселдән килүче) конституциясе, аның барлык геннары, тотрыклы билгеләре җыелмасы, аларның буыннан-буынга тапшырылуы нәтиҗәсендә, халык яки этнос үзенең биологик формасын саклап кала.

Глобальләшү (франц. global — гомуми, латинчадан globus — шар) — милләтләрнең һәм халыкларның тарихи якынаю процессы. Бу процесс, эзлекле рәвештә традицияләр чикләрен юкка чыгарып, кешелекне бердәм сәяси системага әверелдерә.

Гомуми мәдәният — җәмгыятьнең күпчелек әгъзалары таянган барлык кыйммәтләр, ышанулар, традиция һәм гореф-гадәтләр.

Гореф-гадәт — үз-үзеңне тотуның, гамәлләренең традицион ныгып урнашкан тәртибе.

Гражданлык — кеше һәм дәүләтнең сәяси-хокукый бәйләнеше, бу бәйләнеш аларның үзара хокукларында һәм бурычларында чагылыш табыла.

Гражданлык җәмгыяте — сәяси булмаган мөнәсәбәтләр җыелмасы; киң сәяси һәм гражданлык хокукларына ия булган, дәүләт белән идарә итүдә актив катнашучы ирекле, суверен шәхесләр җәмгыятен гәүдәләндерүче идеал.

Гражданнарның буйсынмавы — күмәк каршылык күрсәтү формасы, хакимияткә буйсынмауда чагыла.

Гыйбадәт кылу — тылсымлы йолалар, изгеләргә, иконаларга, сыннарга табыну, пост яки ураза тоту кебек махсус йолалар җыелмасы. Алар диндар кешеләрнең дини хисләре даимилеген һәм активлыгын саклап тору өчен кирәк.

Дәгъва (иск) — суд арбитражына яки третейский судка бирелгән дәгъва гаризасы. Ул бозылган һәм алынган хокукны яки закон тарафыннан сакланган мәнфәгатьне яклау өчен мөрәҗәгать итүдән гыйбарәт.

Дәүләт — билгеле бер хакимият режимыннан (монархия, республика), идарә органнарыннан һәм структурасыннан (хөкүмәт, парламент) гыйбарәт булган аерым бер илнең сәяси оешмасы.

Дәүләт бурычы — түләнмәгән заемнар һәм алар буенча бирелмәгән процентлар.

Дәүләт бюджеты — дәүләтнең билгеле бер вакытта (елга) керемнәре һәм чыгымнары исемлеге.

Дәүләт символикасы — гимн, герб һәм флаг. 2000 елның декабрендә РФ Дәүләт Думасы Александров музыкасына нигезләнгән һәм яңа шигъри юллардан гыйбарәт гимнны, өч төсле (ак, зәңгәр, кызыл) флагны һәм кызыл җирлеккә ике башлы бөркет төшерелгән гербны раслады.

Девиация (соңгы чор латин теленнән deviatio — тайпылу) — кешенең үз-үзен тотышында гомуми кабул ителгән нормалардан читләшүе.

Делинквентлык (лат. delinquens —гаеп эш кылучы) — социологиядә һәм юриспруденциядә җәзага тартылучы гамәлләрне билгеләү.

Депрофессионализация — элекке профессияне яки квалификацияне югалту.

Депривация (латинчадан privatus — хосусый) (*иск.*) — тормыш өчен зарур булган шартлардан мәхрүм калу яки аларның җитәрлек булмавы.

Дефицит (латинчадан deficit —җитми) — алдан ниятләнгән, планлаштырылган яки зарур шартлар белән чагыштырганда чаралар һәм чималларның җитешмәве.

Диада — ике кешенең үзара йогынтысы.

Диаспора (грекчадан — чәчелү) — халыкның шактый зур өлешенең үз туган иленнән читтә яшәве.

Дин (латинчадан religio — диндарлык, изге нәрсә, культ предметы) — җәмгыятьнең иң мөһим институтларыннан берсе; иҗтимагый аң сферасы (идеология, фәнни белемнәр, гади фикерләр белән беррәттән), табигатьтән өстен көчкә ышану аның аермалы билгесе булып тора; мораль принциплар бердәмлегe, алар шушы дини ышануда торучы кешеләрнең үз-үзләрен тотышын һәм яшәү рәвешен җайга сала; культка әверелгән дини карашлар һәм церемониаль гамәлләр практикасы, алар Күк һәм Җирнең аерылгысыз бәйләнешен яңадан торгыза; диндәш кешеләр бердәмлекләре, үзенчәлекле җәмгыять төре.

Дога, гыйбадәт — үтенечне сүзләр белән әйтеп, Ходайга мөрәҗәгать итү.

Дотация (урта гасырлардагы латин теленнән dotatio — бүләк) — предприятиеләр, фирмалар күргән зыянны каплау өчен дәүләт бюджетыннан ассигнованиеләр бүлү, хәрби сәнәгатькә, инфраструктура тармакларына финанс ярдәме күрсәтү.

Дөньяның икътисад системасы — икътисади бәйләнешләр белән берләшкән барлык территорияләр һәм илләр.

«Дүртенче хакимият» — җәмәгатьчелек фикеренә бик зур йогынты ясаучы, хәзерге Россиядәге тормышның күп кенә тискәре якларын гадел яктыртучы массакүләм мәгълүмат чараларын (газеталар, журналлар, телевидение) шулай атыйлар.

Җаваплылык — гаепле кешенең кылганнары өчен җавап тотуы.

Җәмгыять — билгеле бер илнең социаль оешмасы, аның нигезен социаль структура тәшкил итә.

Җәмгыятьнең поляризациясе — алган керемнәреннән бәйле рәвештә ике социаль полюсны тәшкил итүче ярлыларның һәм байларның тирән аерымлануы.

Җитештерү — төрле икътисади продуктлар әзерләү процессы.

Җитештерүчән хезмәт — товарга әвереләчәк матди продуктлар һәм предметлар җитештерүче хезмәт.

Җитештерми торган хезмәт — товарлар җитештермәүче, әмма хезмәт күрсәтүче хезмәт.

Зәвык — нәрсәгә булса да хирыслык яки тартылу, күп очракта бу матурлыкны аңлау яки матурлыкны тану хисе.

Идарә итү — карарлар кабул итү процессы, җитештерүне оештыру, кешеләр эшчәнлеген контрольдә тоту.

Идарә формалары — хакимиятне оештыру төрләре; алар хакимиятнең формаль чыганагы белән характерлана. Монархиядә формаль чыганак — бер зат (король, патша, фиргавен һ.б.). Республикада, закон буенча, хакимият чыганагы — халыкның күпчелеге.

Идентификация (соңгы чор латин теленнән identifico — тәңгәлләштерәм) — тәңгәллекне тану; социологиядә кешенең үзен башка кеше, төркем яки үрнәк белән эмоциональ һәм башка яктан тәңгәлләштерүе процессы.

Иерархия (грекчадан hieros — хакимият) — бербөтен өлешләренең яки элементларының югарыдан түбәнгә таба урнашу тәртибе.

Иерархия принцибы — А.Маслоу теориясе буенча, һәр яңа баскычның ихтыяҗлары элекке баскыч ихтыяҗлары канәгатьләндерелгәч кенә калкып чыга, актуальләшә.

Изге дәрәҗәгә күтәрелү йоласы (ординация, руханилык) — тылсымлы йолалар башкарырга, диндарларны өйрәтергә

һәм «пастырь» кебек үз артыннан ияртергә, тылсымлы йолалар кылырга мөмкинлек бирүче рухи дәрәҗәгә күтәрү (руханилыкка багышлау).

Ике карьералы гаилә — ир һәм хатын икесе дә эшли торган гаилә.

Икътисад — үзара җитештерү, куллану, хезмәт күрсәтүләр һәм товарлар алмашын билгеләү мөнәсәбәтләренә керүче зур төркем кешеләрнең аңлы оештырылган эшчәнлеге.

Ил — дөньяның яки территориянең билгеле бер чик сызыкларына ия булган һәм дәүләт суверенитетыннан файдаланучы бер өлеше.

Имидж — кешенең үз статусына тиң итеп үзен ничек тотарга тиешлеге һәм аның әлеге статустагы хокуклары һәм бурычлары үзара ничек бәйләнүе турында җәмәгатьчелектә туган күзаллаулар.

Имин тормыш дәрәҗәсе — кешегә яхшы тормыш дәрәҗәсен сакларга, кимсенмәскә, үзенең бөтен нигезле ихтыяҗларын канәгатьләндереп, лаеклы тормыш рәвеше алып барырга мөмкинлек бирүче матди байлык күләме.

Импичмент (инг. impeachment) — югары вазифалы затларның җинаятьләрен судта карау һәм аларны җаваплылыкка тартуның үзенчәлекле тәртибе.

Инвестицияләр (немецча investition, латинчадан investio — киендерәм) — ил эчендә яки аннан читтә икътисад тармакларына озак вакытка капитал салулар.

Индивидуальлек — кешенең психологик үзенчәлекләре, алар аның башка кешеләрдән үзгә булуын, аермаларын билгели.

Индивидуаль (индивид) (латинчадан individuum — бүленмәс; шәхес, зат) — аерым кеше.

Индустрия (латинчадан industria — тырышлык) — шул ук сәнәгать.

Индустрияләштерү — сәнәгать технологиясендә фәнни белемнәрдән файдалану, энергиянең яңа чыганакларын табу; алар элек кешеләр һәм җигүле хайваннар башкарган эшне машиналар белән алыштырырга мөмкинлек бирә.

Инноватика, инновация — яңа әйбер, ачыш; яңа технологияләр һәм идеяләр уйлап табу һәм кертү.

Инноватор — нинди дә булса ихтыяҗны канәгатьләндерерлек һәм табыш китерерлек эш уйлап тапкан кеше.

Институт: социаль институт (латинчадан institutum — урнаштыру, оештыру) — җәмгыятьнең яраклаштыру җайланмасы. Ул җәмгыятьнең мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен төзелә һәм социаль нормалар белән көйләнә.

Интернет — глобаль компьютер челтәре. Сез анда үзегезне кызыксындырган бик күп сорауларга җаваплар таба, үз сайтыгызны (битегезне) ача һәм шул рәвешчә Россиядә һәм чит илләрдә яшәүче яшьтәшләрегез белән таныша аласыз.

Инфраструктура: социаль инфраструктура (латинчадан infra — түбән, structura — төзелеш, урнашу) — социаль сфера (мәктәпләр, сырхауханәләр, театрлар, стадионнар һ.б.) эшләве өчен кирәк булган корылмалар, биналар, системалар, хезмәт күрсәтүләр.

«Ирекле сәнгатьләр» — урта гасырларда грамматика, риторика, логика (мантыйк), арифметика, геометрия, музыка һәм астрономияне колачлаган университет фәннәре курсы.

Ирекле эшсезлек — тәкъдим ителгән хезмәт хакыннан канәгатьсезлек аркасында килеп чыккан вакытлы эшсезлек.

Ихтыяҗ — тере затның яшәү шартларыннан бәйлелеген гәүдәләндерүче халәте.

Ихтыяҗның канәгатьләндерелүе — организмның тигезләнеш, туенганлык хәленә кире кайтуы.

Ия булу — хуҗа булу, ягъни милекнең чын хуҗасы булу.

Йола — гореф-гадәт яки ритуал белән билгеләнгән гамәлләр җыелмасы.

Йөкләмә (бурыч) — теге яки бу кешегә йөкләнгән һәм һичшиксез үтәлергә тиешле эш-гамәлләр яки бурычлар.

Кавем — күпсанлы ыруглардан һәм кланнардан торучы югары формадагы берләшмә.

Казаныш мотивациясе — камилләшүгә, хезмәт баскычы буенча үсүгә, иҗади күтәрелүгә булган бик көчле омтылыш.

Казна талау — дәүләт милкен талау.

Канун (грекчадан kanon — норма, кагыйдә) — башкарылуы мәҗбүри булган кагыйдәләр, нигезләмәләр җыелмасы: 1) сынлы сәнгатьтә — кайсыдыр бер чор яки сәнгать юнәлешендә (мәсәлән, барокко, рококо, реализм) хакимлек итүче стилистик һәм икона язу системасы; 2) чиркәү кануны — догматика, культ, чиркәү оешмасындагы кагый-

дәләр, аларны чиркәү законы дәрәҗәсенә күтәрү; 3) Библия кануны — барлык Библия китаплары; аларны чиркәү Алла ярдәмендә язылган дин таный, бу китаплар гыйбадәт кылганда Изге Язма буларак файдаланыла.

Капитал (латинчадан capitalis — төп) — кеше тарафыннан тудырылган чыганаклар; алар табыш китерү өчен товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өлкәләрендә файдаланыла.

Капитализм — хосусый милеккә һәм ирекле (дәүләт катнашыннан башка) базар мөнәсәбәтләренә корылган җәмгыять.

Каста — социаль төркем; кеше тумышы белән генә анда әгъза булып тора.

Катлау яки сословие — гореф-гадәтләр яки юридик закон белән беркетелгән һәм нәселдән нәселгә тапшырылучы хокукларга һәм бурычларга ия булган социаль төркем.

Керем салымы — физик һәм юридик затларның кеременнән алына торган туры салымнарның төп төре. Физик затларның хезмәт хакыннан, өстәмә түләүләрдән һәм премияләрдән, күчемсез милек кеременнән, юридик затларның табышыннан алына.

Кешесез җитештерү өлкәсе — роботлаштырылган цехлар һәм предприятиеләр; анда бар эшне дә роботлар башкара.

Клан (галлча clann, токым) — фараз ителгән ата-баба исемен йөртүче кан-кардәшләр төркеме (кланда уртак җир милке, канлы үч, үзара ярдәмләшү һ.б. саклана); хәзерге заман (күбесенчә чит ил) әдәбиятында клан — нәсел-ыру терминына тәңгәл китереп аңлатыла.

Коллык — кешеләрне кабалага төшерүнең икътисади, социаль, юридик формасы, тулысынча хокуксызлык һәм тигезсезлек белән тиң халәт (кол — хуҗа әйбере).

Конкуренция (соңгы дәвер латин телендәге concurrentia, concurrere сүзеннән — бәрелешү) — аерым бер иҗтимагый өлкәдә бердәй максатларга, иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен кешеләрнең, төркемнәрнең яки оешмаларның ачыктан-ачык көндәшлеге.

Конституция (латинчадан constitutio — төзелеш, корылыш) — дәүләтнең төп законы, ул җәмгыять һәм дәүләт төзелешен, хакимиятнең вәкиллекле органнарын төзү тәртибен һәм принципларын, сайлау системасын, гражданнарның төп хокукларын һәм бурычларын билгели.

Контркультура — төп кыйммәтләр белән конфликтка керүче, аларга капма-каршы торучы субкультура.

Конфликт (латинчадан conflictus — бәрелешү) — ике кешенең яки социаль төркемнәрнең бәхәсе, бәрелешүе. Бу бәхәс ике як тарафыннан да мөһим дип табылган, кадерле булган нәрсәгә хуҗа булу өчен килеп чыга.

Конфронтация (французча confrontation) — төркемнәрнең, сыйныфларның, кешеләрнең һәм шулай ук аларның мәнфәгатьләренең, фикерләренең бәрелеше, үзара көрәше.

Коррупция (латинча corruptio — сатып алу) — вазифалы затның шәхси баю максатларында үз хезмәт урыныннан турыдан-туры файдалануы.

Көч — үз ихтыярын башка кешеләр теләгеннән тыш аларга тагу максатында физик йогынтыдан файдалану.

Кулланучы — товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алучы һәм аларны көнкүрештә шәхси ихтыяҗлары өчен файдаланучы кеше.

Культ (латинчадан cultus — хөрмәтләү, баш ию) — диннең төп элементларының берсе; дини табынуга күренеп торган рәвеш бирү яки аны башкаручыларга илаһи «көч» иңдерү (тылсымлы йолалар) максатына корылган хәрәкәтләр (тән хәрәкәтләре, билгеле бер текстларны һ.б. уку яки җырлау).

Культура (мәдәният; латинчадан — эшкәртү, белем, үсеш, хөрмәт итү) — барлык традицияләр, гореф-гадәтләр, социаль нормалар, кагыйдәләр. Алар хәзерге буын вәкилләренең үз-үзләрен тотышын җайга салалар һәм алдагы буынга тапшырылалар.

Культура (мәдәният) **ареалы** — географик район, аның эчендәге төрле культураларның төп сыйфатлары уртаклыклары күзәтелә.

Культура (мәдәният) **комплексы** — башлангыч элемент базасында барлыкка килгән һәм функциональ яктан аның белән бәйләнгән барлык мәдәният сыйфатлары яки элементлары.

Культура (мәдәният) **универсалийлары** — географик урыныннан, тарихи заманыннан һәм җәмгыятьнең социаль төзелешеннән бәйсез рәвештә, бөтен культураларга да хас нормалар, кыйммәтләр, кагыйдәләр, традицияләр һәм сыйфатлар.

Культура (мәдәният) **плюрализмы** — бер дәүләт эчендә төрле халыкларның янәшә тыныч яшәве.

Культуралаштыру (мәдәниләштерү) — тәрбияләү, мәдәният белән таныштыру аша мәдәният нормаларына өйрәтү.

Күп буынлы гаилә — балалардан, әти-әниләрдән, әби-бабайлардан торган гаилә.

Күп партиялелек — партия системасы, мондый очракта илдә икедән артык легаль сәяси партия эшли.

Кыек (читләтелгән) **салым** — гражданнардан һәм хуҗалык оешмаларыннан алар билгеле бер эшне тормышка ашырганда гына дәүләт файдасына алына торган җыем (мәсәлән, кайбер төр товарларны сатып алганда).

Кыска сроклы казна векселе — кыйммәтле дәүләт кәгазе, ул бер еллык вакытка чыгарыла һәм, гадәттә, үз номиналь кыйммәте белән чагыштырганда ташламалы бәядән сатыла, ә дәүләт аны соңыннан шул номиналь бәядән кире сатып ала.

Легаль (латинчадан legalis — законлы) — закон тарафыннан рөхсәт ителгән, танылган.

Легитим — законлы.

Лидер (инглизчәдән leader — әйдәп баручы, җитәкче) — теге яки бу төркемнең, партиянең, хәрәкәтнең, фракциянең иң абруйлы әгъзасы.

Льгота яки ташлама — ниндидер өстенлекләр бирелү, билгеләнгән кагыйдәләрдән, бурычлардан өлешчә азат ителү яки аларны үтәү шартларының җиңеләйтелүе. Мәсәлән, салым ташламалары.

Мавыгу — кыска вакытлы эмоциональ омтылыш.

Манера яки үз-үзеңне тоту рәвеше — кешенең үз-үзен тотуының гадәтләргә нигезләнгән тышкы формалары.

Маргинал (французчадан marginal — икенче, кырыйда) — бер мәдәниятне, илне, сословиене, сыйныфны, төркемне калдырып киткән һәм башка тормыш рәвешенә һәм кыйммәтләренә керә алмаган кеше.

Маркетинг (инг. marketing, market сүзеннән — базар) — предприятиеләрнең җитештерү-сату эшчәнлеге белән заманча идарә итү системасы, ул базарны комплекслы анализлауга нигезләнә.

Матриархат (латинчадан mater — ана һәм грекча arché баш-лангыч, хакимият; сүзгә-сүз тәрҗ. — ана хакимияте) —

иҗтимагый төзелешнең бер формасы (борынгы ыруглык җәмгыятенең беренче чоры), гаиләдә, варислыкта хатын-кызның өстен булуы белән характерлана.

Мәгълүмати җәмгыять — төп җитештерүче көч булып белем һәм мәгълүмат торган постиндустриаль җәмгыять.

Мәҗбүри эшсезлек — хезмәткәр теләгеннән тыш килеп чыккан сәбәпләр аркасында туган эшсезлек.

Менеджер (инглизчә, берлек санда manager — идарәче) — идарә итү белгече.

Милек мөнәсәбәтләре — нинди дә булса милек яки әйбергә кагылышлы хокукый мөнәсәбәтләр.

Милләт — территориаль кысалар белән чикләнмәгән автоном төркем, аның әгъзалары уртак кыйммәтләргә һәм институтларга таяна.

Милли азчылык — үз этносының төп өлешеннән яки шул милләт исемендәге дәүләттән читкә килеп эләккән этносның аерым бер өлеше.

Миграция (латинча migratio, migro сүзеннән — күчәм, килеп урнашам) — күпсанлы кешеләрнең бер урыннан икенче урынга, мәсәлән, бер илдән икенче илгә күчүе, килеп урнашуы.

Миф (грекчадан mythos — риваять) билгеле бер халыкларда, билгеле бер вакытта аларның тарих таңында урын алган кайбер вакыйгаларның символик чагылышы буларак сөйләнгән хикәят.

Мифология — кешенең — коллективка, коллективның — табигатьтән өстен дөньяга, әлеге дөньяның галәмгә кушылуының киң колачлы кагыйдәләр (тәүге — ата-бабалар башлап җибәргән гореф-гадәтләрдән алып) системасы.

Мода (французча mode, латинчадан modus — үлчәм, чара, кагыйдә) — тормыш яки мәдәниятнең теге яки бу өлкәсендә билгеле бер зәвыкның кыска вакытлы хакимлеге, кием формалары һәм үрнәкләре алышыну; тиз узучы мәшһүрлек.

Монополия (грекчадан monos — бер, бердәнбер һәм poleo — сатам, сату-алу итәм) — дәүләтнең теге яки бу эшчәнлек сферасындагы аерым, үзенеке генә булган (монополь) хокук (мәсәлән, тышкы сәүдә, оешма, предприятие, фирма монополиясе).

Монотон (грекчадан monos — бер, tonos — киеренкелек) бердәй агышлы, кабатланучан, искелек.

Мораль (латинчадан moralis — әхлакый) — барлык әхлакый нормалар; алар, гади гореф-гадәттән һәм традициядән аермалы буларак, мәрхәмәтлелек һәм явызлык, тигезлек, гаделлек идеаллары рәвешендә нигезләнәләр; әхлак яки мораль таләпләрнең үтәлеше бары тик рухи йогынты формалары белән генә көйләнә (иҗтимагый бәяләү, уңай дип табу яки тәнкыйть итү); аңа мәңгелек рухи идеаллар керә, шулай ук ул тарих алып килгән нормаларны һәм принципларны да колачлый; махсус философия фәне — этика тарафыннан өйрәнелә.

Мотив (французча motif, латинчадан moveo — хәрәкәтләндерәм) — үз-үзеңне тотышның аңлатып була торган сәбәбе, уйланылган эш-гамәле.

Муллык-иминлек — кешеләрнең көндәлек тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек, аларга файда китерерлек барлык нәрсәләр.

Натуралаштыру — кешене, аның үтенече буенча, теге яки бу илнең гражданы яки подданые итеп алу (мәсәлән, озак еллар дәвамында шул илдә яшәгәндә).

Нәфис мәдәният — сүз, музыка, театр, сынлы сәнгать һ.б. кебек нәфис иҗат эшчәнлегенең бөтен төрләрен берләштерә, аңа бу эшчәнлекнең барышы һәм нәтиҗәсе керә, төгәлрәк әйткәндә, ул иҗат итүдән, саклаудан, таратудан, аңлау-кабул итүдән, бәяләүдән, әдәби әсәрне өйрәнүдән, шулай ук иҗатчыларга белем бирүдән, тәнкыйтьчеләрне, сәнгать белгечләрен, тамашачыларны тәрбияләүдән гыйбарәт.

Неолит революциясе (неолит — яңа таш дәвере) — аучылык һәм азык җыючылыктан игенчелеккә күчү.

Норма (латинчадан norma— җитәкче башлангыч, кагыйдә, үрнәк) — төркемдә яки җәмгыятьтә рәсми яки рәсми булмаган рәвештә кабул ителгән барлык кагыйдәләр (социологиядә).

Нуклеар гаилә (латинчадан nukleus — төш) — ата-аналардан һәм балалардан, ягъни киләчәк буынны тудыра алырга һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләргә сәләтле булган социаль һәм биологик төштән, үзәктән торучы гаилә.

Община — үзара кан кардәшлеге җепләре белән, үзара никахлар, хезмәт кооперациясе, үзара ярдәмләшү, территорияне бергәләп саклау белән бәйләнгән берничә йөз кеше союзы, берлеге.

Олигополия (грекчадан oligos — аз санлы һәм poleo — сатам, сәүдә итәм) базарда килеп туган хәл, мондый очракта берничә эре конкурент фирма тармактагы продукция җитештерүне һәм аның төп өлешен сатуны монополияләштерәләр.

Оферта (латинчадан offero — тәкъдим итәм) гражданлык-хокукый характердагы килешү (договор) төзү тәкъдиме.

Өйләнешү (никахлашу) — ир һәм хатынның хокукларын, бурычларын, шулай ук икесенең бергә балаларына һәм гомумән җәмгыятькә карата хокукларын һәм бурычларын билгеләүче рәсми күрсәтмәләр җыелмасы.

Өйләнешү (никахлашу) **контракты** — уртак милеккә хуҗа булу, аның белән эш итүнең, бер-береңне матди яктан тәэмин итүнең теләсә кайсы шартларын искәртүче юридик документ.

Өстәмә керем, табыш — товар җитештерүгә һәм аны таратуга киткән чыгымнардан тыш товарны сатканнан соң калган керем.

Парламент (инглизчә parliament, французчадан parler — сөйләү) — хакимиятнең закон чыгаручы вәкаләтле югары органы, ул тулысынча яки өлешчә сайлау башлангычларында корыла.

Патриархаль гаилә — берничә буыннан гыйбарәт зур гаилә, аның башында ир кеше тора.

Поп-культура — массакүләм мәдәниятнең сленг атамасы.

Постиндустриаль җәмгыять — фән һәм яңа интеллектуаль технологияләр җитештерүче көч буларак чыгыш ясаган җәмгыять. Күпчелек халык хезмәт күрсәтү өлкәсендә (сәүдә, финансларда, транспортта, сәламәтлек саклауда, буш вакытта, фәндә, мәгарифтә, хөкүмәттә) эшли.

Предприятие — законлы тәртиптә төзелгән мөстәкыйль хуҗалык субъекты.

Престиж (французча prestige, иң элек — сөйкемлелек) — авторитет, йогынты; җәмәгатьчелек фикерендә урнашкан статусны хөрмәт итү.

Причащение (Евхаристия) (грекчадан eucharistia — катнашу, кушылу) — христианнарда диндар кешенең Христос тәне һәм канын гәүдәләндерүче ипи (просфора) һәм шәрабтан литургия вакытында авыз итүе һәм шулай итеп Христоска кушылуы.

Прогресс (алгарыш) — җәмгыять үсеше, алгарышы. Бу вакытта уңай үзгәрешләр тискәреләреннән алга китә.

Прогрессив салым — керемнең үсә баруына бәйле рәвештә салым ставкаларын арттыру принцибына корылган салым.

Профориентация — профессиональ, һөнәри юнәлеш алу, һөнәр сайлау.

Процент — читләр акчасын яки капиталын файдаланган өчен түләү.

Раса дискриминациясе — милләте яки расасына бәйләп, кешеләрнең этник төркемнәре хокукларын даими чикләү, киметү.

Рациональ (латинчадан rationalis — акылга сыешлы, ratio — акыл) — акылга, логик дәлилләргә, максатчанлыкка нигезләнгән.

Регресс — җәмгыять үсеше, мондый очракта тискәре үзгәрешләр уңайларыннан өстен чыга.

Рекрутинг (немецча rekrut — ялланып яки бурычын үтәп, хәрби хезмәткә алынган зат) — кадрлар, персонал туплау системасы.

Респондент — социолог тарафыннан сораштырылучы кеше.

Республика (латинча respublika, сүзгә-сүз тәрҗемәсе — иҗтимагый эш) — дәүләт башлыгы (мәсәлән, президент) халык яки сайлау коллегиясе тарафыннан сайлана; закон чыгару хакимияте сайланган вәкиллекле орган (парламент) кулында була.

Референдум (латинчадан referendum — хәбәр ителергә тиешле нәрсә) законнар кабул итү формасы яки дәүләт тормышының аеруча мөһим мәсьәләләрен бөтен халык тавыш бирүе юлы белән хәл итү.

Рецидивист (латинчадан recidivus — әйләнеп кайтучы) — инде хөкем ителгән һәм кабат җинаять кылган кеше.

Ритуал (латинчадан retualis — йоланыкы) — йоланың бер төре, катлаулы символик хәрәкәтләр формасы, билгеле

бер социаль һәм культура кыйммәтләрен чагылдыручы эш-гамәлләр системасы.

Роль — үз-үзеңне тоту моделе, статусның бер өлеше.

Рольләр җыелмасы — бер статус белән тәңгәл килә торган барлык рольләр (рольләр комплексы).

Рэкет — табышны көч кулланып тартып алуның криминаль формасы (шантаж, куркыту, физик газаплаулар).

Сайлау хокукы — дәүләт башлыгын, вәкиллекле органнарны сайлаулар тәртибен билгеләүче барлык хокукый нормалар.

Салымнар — физик һәм юридик затлардан дәүләт һәм җирле бюджетларга дәүләтнең үзәк һәм җирле хакимият органнары тарафыннан алына торган мәҗбүри түләүләр.

Сальдо (итал. saldo — исәп-хисап, калдык) — хисапчылар яки бухгалтерлар хисабында дебет һәм кредит буенча йомгаклау язмалары арасындагы аерма.

Санкция (латинчадан sanctio — иң кискен карар) — уңай һәм тискәре йогынты чарасы.

Сәнгать — 1) тулаем әдәби иҗат: әдәбият, скульптура, рәсем сәнгате, графика, декоратив-гамәли сәнгать, музыка, бию, театр, кино һәм кеше эшчәнлегенең дөньяны танып-белү барышында әдәби образ формалары рәвешендә берләштерелгән башка төрләре; 2) бары тик сынлы сәнгать; 3) теләсә кайсы эшчәнлек өлкәсендәге осталыкның, маһирлыкның югары дәрәҗәсе.

Сәяси партия — социаль төркемнәр мәнфәгатьләрен чагылдыра, аларның иң актив вәкилләрен берләштерә торган сәяси берләшмә.

Сәяси программа — җәмгыятьнең булачак төзелеш тәртибен сыйфатлап бирүче, хакимияттә торучы хөкүмәткә тәнкыйть белдерүче, халык йөзгә-йөз бәрелгән көнүзәк социаль һәм икътисади проблемаларны хәл итү чараларын һәм ысулларын чагылдыручы нигезләмәләр тупланмасы.

Сәяси режим — дәүләт хакимиятен тормышка ашыру алымнары системасы, рәсми конституцион һәм хокук формаларының чынбарлыктагы сәяси тормыш белән туры килүе, хөкүмәтнең үз эшчәнлегенең хокукый нигезләренә мөнәсәбәте, шәхеснең демографик хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру дәрәҗәсе.

Сәяси философия — җәмгыятьнең идеаль төзелешен күздә тоткан карашларның тәртипле системасы, ул үзенең тамырлары белән дөньяның теге яки бу сәяси системасына (демократиягә, социализмга, либерализмга, консерватизмга, фашизмга) барып тоташа.

Сепаратизм (латинчадан separatus — аерым) — бүленүгә, аерымлануга омтылыш.

Символ (грекчадан symbolon — тамга, аеру билгесе) — матди җисемне алыштыручы идеаль билге.

Сленг (инглизчә slang) — инглиз телле илләрдә шул ук жаргон; әдәби тел нормалары белән туры килми торган сөйләм теле варианты.

Сорау — сатып алучыларның, кулланучыларның билгеле бер товарны акчалата мөмкинлекләре белән ныгытылган сатып алу теләге, нияте.

Социализм — җәмәгать милкенә һәм икътисадны планлы көйләүгә нигезләнгән җәмгыять.

Социаль — иҗтимагый, халык массаларының үзара йогынтысы белән тудырылган.

Социаль дәүләт — социаль җәһәттә якланмаган катлауларга (ялгыз аналарга, аз керемлеләргә, балаларга, инвалидларга һ.б.) актив матди ярдәм күрсәтүгә юнәлеш тоткан дәүләт.

Социаль институтлар — уртак эшчәнлекне оештыруның тарихи яктан урнашкан нык формалары. Алар нормалар, традицияләр, гореф-гадәтләр белән җайга салына, бу эшчәнлек җәмгыятьнең төп ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән.

Социаль катлауларга бүленү — халык арасында социаль катлаулар барлыкка килү процессы (һәм аның нәтиҗәсе).

Социаль программалар — матди хәлләре буенча абсолют ярлылык бусагасында яки аннан да артта торучы, ягъни яшәү минимумы дәрәҗәсендә яки аннан да түбәнрәк торган аз керемле кешеләрне, картларны, эшсезләрне, инвалидларны һ.б. яклау өчен дәүләт бюджетыннан финанслау чаралары.

Социаль төркем — кешеләрнең социаль яктан мөһим критерийлар буенча (җенес, яшь, милек, раса, профессия, яшәү урыны, керем, хакимият, белем һ.б.) аерылып торучы теләсә кайсы төркеме.

Социальләшү — бөтен яшәү рәвешендә мәдәният нормаларына төшенү һәм социаль рольләрне үзләштерү.

Социальләштерү агентлары — мәдәният нормаларына өйрәтү һәм социаль рольләрне үзләштерү өчен җаваплы кешеләр һәм оешмалар.

Статус — индивидның төркемдәге яки җәмгыятьтәге социаль позициясе (урыны).

Стратификация (латинчадан stratum — катлам һәм ...фикация, ягъни төзелеш, корылыш) — социаль төркемнәрнең керем, белем дәрәҗәләре, хакимиятләре колачы, һөнәри абруйлары тигезсезлеге билгесе буенча югарыдан түбәнгә таба урнашуы.

Структура — нык береккән һәм үзара бәйләнгән барлык элементлар җыелмасы.

Субкультура — гомуми мәдәниятнең бер өлеше, зур социаль төркемгә хас кыйммәтләр, традицияләр һәм гореф-гадәтләр системасы.

Суверенлык — бөтен җәмгыятьне тулаем гәүдәләндерү хокукына ия булуда, норматив актлар, шул исәптән җәмгыятьнең барлык әгъзалары тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган законнар чыгаруда, суд эшчәнлеге алып баруда чагылыш таба.

Сыйныф (русча класс, грекчадан class — үз дәрәҗәсендә һәм профессиясендә калган, үз урынын, хәлен белгән кешеләр) — кешеләрнең зур социаль төркеме. Алар җитештерү чараларына, коралларына ия булалар (яки булмыйлар), иҗтимагый хезмәт бүленеше системасында аерым урын билиләр һәм табыш алуның үзләренә генә хас ысулы белән сыйфатланалар.

Сын, пот, балбал (русча идол, грекчадан eidolon, сүзгә-сүз тәрҗ. — образ, күчермә) — а) кеше яки хайван формасында ясалган матди предмет; б) дини табыну объекты булып хезмәт итүче илаһи зат сыны; в) үзен хөрмәт итүчеләрнең аңа бик нык бирелгәнлегенә ирешкән мәшһүр кеше (музыкант, спортчы, җырчы һ.б.)

Сынлы сәнгать — пластик сәнгатьләрнең бер бүлеге, ул рәсем сәнгате, скульптураны һәм графиканы колачлый.

Табыш, керем — хезмәт хакы, пенсия, рента, пособие, алимент, гонарар рәвешендә алынган күпмедер акча суммасы.

Тармак — бер үк төрле продукт җитештерүче, тиңдәш технология яки бердәй чимал файдаланучы фирмалар төркеме.

Тәкъдим — натураль мөмкинлек белән ныгытылган теләк, җитештерүченең (сатучының) үз товарларын сатуда тәкъдим итү нияте.

Тәкъдим күләме — сатучыларның билгеле бер урында һәм билгеле бер вакытта сатуга тәкъдим иткән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме.

Тәүбә (исповедь) — христиан диндарларының үз гөнаһларын священникка сөйләве һәм аның Христос исеме белән гафу итүенә («гөнаһларны ярлыкау») ирешү.

Теләктәшлек — нинди дә булса карашларны яки гамәлләрне яклау, эшлекле уртаклашу.

Тигезсез никах — парларның ниндидер бер әһәмиятле билге (җәмгыятьтә тоткан урыны, яше, кереме) буенча аермасы.

Теология (грекчадан theos —Алла һәм logos — фән) — кешегә үзе турындагы белемне вәхидә хәбәр итүче бердәнбер Алла концепциясен алга сөргән дини тәгълимат.

Технология (грекчадан techne — сәнгать, осталык, эшли алу һәм ...логия) — продукция җитештерү процессында чимал, материал яки ярымфабрикатны эшкәртү, әзерләү, аның халәтен, сыйфатларын үзгәртү ысуллары җыелмасы.

Тинэйджер — 13 яшьтән алып 19 яшькә кадәрге яшүсмер (егет яки кыз).

Титуллар — аларга ия кешеләрнең хезмәттәге, катлау һәм нәсел-ырудагы хокукый статусларын кыскача билгеләүче сүзләр. Бу сүзләр закон белән күрсәтелгән.

Титул этнос — атамасы дәүләт атамасы белән бер булган этник төркем.

Товар — алмашу (сату өчен җитештерелгән хезмәт продукты).

Тормыш планы — алда торган тормышның идеаллаштырылган картинасы, аның үзеген социаль карьера траекториясе һәм мөмкин булган казанышлар суммасы тәшкил итә.

Тоталитаризм (урта гасырлар латин теленнән totalis — барлык, бөтен, тулысынча) — дәүләтнең бер формасы (тоталитар дәүләт), ул җәмгыять тормышының барлык өлкәләре өстеннән тулысынча (тоталь) контроль белән, оппозиция һәм башкача фикер йөртүчеләргә карата репрессияләр белән характерлана.

Тотемизм — борынгы ыруглык җәмгыятенең инанулары һәм йолалары комплексыннан гыйбарәт, алар кешеләр төркемнәре һәм хайваннар арасындагы туганлык турындагы күзаллаулар белән бәйләнгән.

Традиция — элекке буыннардан мирас итеп алынган бар нәрсә.

Трансмилли — милләтара.

Триада — өч кешенең актив үзара йогынтысы.

Тулы булмаган гаилә — ата-аналарның берсе үлү яки аерылышу аркасында барлыкка килә.

Туры салым — һәр гражданнан яки хуҗалык оешмасыннан, аларның керемнәре күләменә карап, дәүләт файдасына алынган җыем.

Тылсымлы йолалар (грекча mysterion, латинча sacramentum) — кеше тормышына илаһилыкны алып керергә тиеш булган махсус ритуаль гамәлләр. Православие чиркәве 7 төрле тылсымлы йоланы таный: чукындыру, хуш исле май сөртү (миропомазание), причащение (евхаристия), тәүбәгә килү (исповедь), чиркәүдә өйләнешү (венчание), изге зәйтүн мае ышку (соборование яки елеосвящение), руханилыкка багышлау (священство).

Университет (латинчадан universitas — кушылма, бердәмлек) югары уку һәм фән йорты, анда фундаменталь һәм күпсанлы гамәли (практик) фәннәр буенча һәм халык хуҗалыгының, мәдәниятнең төрле тармакларында эшләүче белгечләр әзерләнә.

Урбанизация — кешеләрнең шәһәрләргә күчеп килүе, шәһәр тормышы кыйммәтләренең барлык катлаулар арасында таралуы.

Үзъялланмыш — бер үк кешедә гәүдәләнеш тапкан яллы хезмәткәр дә, хуҗа да.

Үрнәк гадәтләр (нравы) — җәмгыятьтә аеруча сакланучы, бик нык хөрмәт ителүче күмәк эш-гамәлләр үрнәкләре.

Фактор (латинчадан factor — ясаучы , җитештерүче) — нинди дә булса процессның, күренешнең сәбәбе, хәрәкәтләндерүче көче. Ул аның характерын һәм аерым сыйфатларын да билгели.

Фераль кешеләр — кешеләрдән аерым, изоляциядә үскән һәм хайваннар арасында тәрбияләнгән кешеләр.

Фетишизм (французча fetiche, португалчадан feitico — амулет; тылсым) — җансыз предметларга дини табыну, алар

табигатьтән өстен сихри көчкә ия дип ышану.

Фирма (итальянчадан firma — имза) — 1) предприятиеләрнең җитештерү берләшмәләре төре; 2) сәүдә яки сәнәгать предприятиеләре атамасы (фирма атамасы).

Формаль яки рәсми — теркәлгән кагыйдә һәм законнарга нигезләнгән.

Фрустрация (латинчадан frustratio — уңышсызлык) — хәвефлелек, чарасызлык хисе, төшенкелек.

Функция яки вазифа — билгеле бер эш, башкарыла торган роль.

Хакимият — закон һәм традицияләр нигезендә йогынты ясау, ягъни башка кешеләргә карата закон яки гореф-гадәтләр кысасында физик булмаган йогынты ясау.

Халык мәдәнияте — профессиональ әзерлеге булмаган аноним иҗатчылар тарафыннан тудырылган мәдәният.

Халыкның социаль составы — барлык зур социаль төркемнәр.

Халыкча — кешеләрнең тел, территориаль, икътисади һәм мәдәният ягыннан гомумилеге. Кабиләләр һәм милләтләр арасында урнаша.

Хәерчеләр — физик ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүгә сәләтле булган, биологик җан асрауны гына тәэмин итә алырлык, хәер җыеп көн күрүче кешеләр.

Хәерчелек — чиктән тыш ярлылык.

Хезмәт — кеше вакытының, энергиясенең һәм сәләтләренең хезмәт күрсәтүләр һәм товарлар җитештерү һәм аларны урнаштыру өчен файдаланылуы.

Хезмәт күрсәтү — акча алу өчен башкарыла торган файдалы эшчәнлек.

Хезмәт табышы — эшче тарафыннан алынган индивидуаль табыш яки керем; хезмәт хакы ставкасын эшләнгән вакыт күләменә тапкырлап исәпләнә.

Хезмәт хакы — хезмәткә (хезмәттән файдаланган өчен) куелган бәя, ул вакыт берәмлеге белән (атна, ай) исәпләнә.

Хезмәт хокукы — эш процессында хезмәткәр һәм эш бирүче арасында туган мөнәсәбәтләрне җайга салучы нормалар җыелмасы.

Хезмәткә урнашу — эш эзләү һәм яллану.

Хокук (закон) — һичшиксез үтәлергә тиешле кагыйдәләр системасы; алар дәүләт тарафыннан рөхсәт ителә (санкция-

ләнә) һәм билгеле бер нормаларда гәүдәләнеш таба.

Хокук нормасы — кешеләрнең килеп туган теге яки бу хәлдә үз-үзләрен тоту кагыйдәсе, ул һичшиксез үтәлергә тиеш.

Хокукый дәүләт — җәмгыятьтә хокук өстенлеге, кешеләр иреге, хокукый тигезлек.

Хокукый сәләтлелек — хокукларга һәм бурычларга ия булу сәләте.

Хокукый статус — кешенең хокук һәм йөкләмәләре (бурычлары) бергәлеге.

Хосусый милек — гражданның яки юридик затның тәгаен билгеле бер милеккә (җиргә, башка күчемле һәм күчемсез милеккә) карата закон тарафыннан якланган хокукы.

Церемония — символик мәгънәгә ия булган һәм нинди дә булса вакыйгаларны һәм даталарны бәйрәм итүгә багышланган эш-гамәлләр эзлеклелеге.

Цивилизация — 1) «варварлыкка» алмашка килгән тарихи дәвер; 3) мәдәни-географик төзелмә, мәсәлән, Көнчыгыш, Көнбатыш, Кытай цивилизацияләре; 4) бөтен планетаны колачлаган глобаль цивилизация.

Цикллы эшсезлек — барлык тармакларда, сфераларда, регионнарда эш көченә булган сорауның гомуми түбәнәюе белән бәйләнгән, вакытлыча эшсез калу.

Чагыштырма ярлылык — билгеле бер җәмгыятьтә кабул ителгән тормыш стандартын яки тормыш дәрәҗәсен саклап тора алмау.

Чек (инг. check, chegue) — кыйммәтле кәгазь, анда чек бирученең (гадәттә, агымдагы хисап хуҗасының) кулында чек булган кешегә банктан шул чекта күрсәтелгән сумманы бирү турында бернәрсә белән дә бәйләнмәгән язма боерыгы.

Чимал — хезмәт йогынтысына дучар ителгән һәм эшкәртелергә тиешле материаллар (мәсәлән, чыгарылган руда).

Чиркәү (грекчадан kuriake (oikia), сүзгә-сүз тәрҗемә — Алла йорты) — 1) христиан динендә диндарларның («тугрыларның») мистик бергәлекләрен билгеләүче үзенчәлекле төшенчә, чиркәүдә башкарылган тылсымлы йолаларда (беренче чиратта, евхаристиядә) бергәләп катнашу аша кешенең Алла белән кушылуы тормышка ашырыла; 2) христианнар храмы; 3) уртак дини тәгълимат һәм культка нигезләнгән теге яки бу дин тарафдарлары оешмасы.

Чоппер — чуерташтан ясалган, бер ягы эшкәртелгән авыр корал.

Чукындыру — христианлык тормышының бер өлешен тәшкил итүче инициация, ягъни тылсымлы йоланы башкару, ул тумыштагы гөнаһтан арындыра, имеш.

Чыганак яки ресурслар (французчадан ressource — ярдәмчел чара) — акча, кыйммәтләр, запаслар, мөмкинлекләр, чаралар, керемнәр чыганагы (мәсәлән, табигать байлыклары, икътисади ресурслар).

Чыганаклар яки ресурслар сирәклеге — аерым төр чимал төрләренең чикләнгәнлеге, алар күләменең җитештерү ихтыяҗларын канәгатьләндерергә җитмәве.

Шартнамә, килешү — кешеләр, оешмалар, дәүләтләр арасындагы килешү.

Шәхеснең хокукый мәдәнияте — хокукны белү һәм аңлау, шулай ук аңа тиң эш-гамәлләр.

Шәхси статус — кешенең кече яки беренчел төркемдә аның индивидуаль сыйфатларына карамыйча тоткан урыны.

Шенген килешүе — әлеге документка кул куйган Бельгия, Австрия, Бөекбритания, Германия, Италия, Нидерланд, Франция кебек илләрдә таможня контролен һәм виза режимын бетерү турындагы килешү.

Шоу-бизнес — күңел ачулар индустриясе.

Шөгыль — хезмәт хакы яки табыш китерүче эшчәнлек төре яки башкарыла торган эш.

Эгоизм (французча egoisme, латинчадан ego — мин) — үзеңне ярату; тулысынча үз файдаң, табышың турындагы уй белән билгеләнүче гамәлләреңне, үз мәнфәгатьләреңне башкаларныкыннан өстен кую.

Элитар мәдәният — җәмгыятьнең өстен катлавы яки аның кушуы буенча профессиональ иҗатчылар тарафыннан тудырылган мәдәният.

Эмиссия (латинчадан emissio — чыгару) — банк һәм казначылык билетларын, кәгазь акчаларны һәм кыйммәтле кәгазьләрне әйләнешкә кертү.

Эскапизм (латинчадан escape — чабарга, котылырга) — шәхеснең кризислар, чарасызлык, читкә кагылу ситуацияләрендә чынбарлыктан иллюзияләр, фантазияләр дөньясына китәргә омтылуы.

Этикет — аерым социаль даирәләрдә кабул ителгән һәм бербөтенне тәшкил итүче үз-үзеңне тоту кагыйдәләре системасы.

Этник кушылу — күп буыннар дәвамында милләтара өйләнешүләр аша төрле этник төркемнәрнең стихияле кушылуы.

Этнос (грекчадан ethnos — кавем, халык) — кавем, халыкча яки милләт барлыкка китерүче күпсанлы кан-кардәш кешеләр төркемнәренең гомуми атамасы.

Этноцентризм — үз мәдәниятенең өстен булуына ышаныч, башка мәдәният стандартларын дөрес булмаган, түбән, эстетик түгел дип кире кагу тенденциясе яки шуңа омтылу.

Эш — билгеле бер түләү өчен башкарылган теләсә кайсы эшчәнлек төре.

Эш башыннан түләү — җитештерелгән продукция күләменә карап түләү.

Эш-гамәлгә сәләтлелек — кешенең үз хокукларын чикләүләрсез мөстәкыйль тормышка ашыру һәм үз бурычларын үти алу сәләте.

Эшмәкәр — табыш алуга өметләнеп үз эшен ачкан һәм аның белән идарә итүче зат, үзенең акчасы яки бурычка (кредитка) алган акча хисабына үз эшен башлап җибәргән кеше.

Эшмәкәрлек — товарлар җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен үзенең акчасы яки бурычка алган акча хисабына хуҗалык оешмалары (фирмалары) төзү һәм шуның нигезендә табыш алу.

Эшсез — хезмәт хакы булмаган, эшсезлек өчен ярдәм (пособие) дип аталган махсус ярдәм чарасы хисабына яшәүче кеше.

Эшсезлек — эшкә сәләтле яшьтәге кешеләрнең иҗтимагый җитештерүдә катнашмавы.

Эшсезлек дәрәҗәсе — эшсезләр санының хуҗалыкта эшләүчеләрнең гомуми санына карата нисбәте.

Ябык җәмгыять — түбән катлаулардан югары катлауларга күчү тулысынча тыелган яки бик нык чикләнгән җәмгыять.

Яллы хезмәт — хезмәткәрнең үзе хуҗа булып тормаган предприятиедә яллау шартнамәсе буенча хезмәте.

«Яңа руслар» — РФдә базар мөнәсәбәтләре елларында формалашкан эре, урта һәм вак буржуазия.

Ярлылык — иң аз акчага, белемгә, хакимияткә һәм абруйга ия булган кешеләрнең икътисади һәм социаль хәле.

Ярлылык бусагасы — минималь керем сыйфатында рәсми рәвештә билгеләнгән акча суммасы, аның ярдәмендә индивид яки гаилә туклану өчен кирәкле азык-төлек ала. Аны шулай ук «ярлылык дәрәҗәсе» дип тә атыйлар. Россиядә тагын «яшәү минимумы» дигән өстәмә исем дә бирелгән.

Яшәү минимумы — фәнни күзлектән караганда, кешегә минималь ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирерлек товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җыелмасы (сатып алынган әйберләрнең бәяләрендә гәүдәләнеш таба).

Яшәү рәвеше — кешеләрнең тормыш алып баруының, үзүзләрен тотышының гадәткә әверелгән рәвеше.

Яшелчәчелек — әзер продуктлар (кыргый үсемлекләр) табудан системалаштырылган һәм интенсив рәвештә культуралаштырылган кыяклы ашлыклар үстерүгә күчүдән гыйбарәт үсемлекчелек тармагы.

Әдәбият

Авксентьев В. А. Этническая конфликтология: В 2-х ч.— Ставрополь, 1996.

Алексеев В. П. Становление человечества.— М., 1984.

Андреев И. Л. Происхождение человека и общества.— М., 1988.

Андреева Г. М. Социальная психология.— М., 1994.

Арутюнов С. А. Народы и культуры: Развитие и взаимодействие.— М., 1989.

Байбурин А. К., Топорков А. Л. У истоков этикета: Этнографические очерки.— Л., 1990.

Берн Э. Игры, в которые играют люди. Люди, которые играют в игры.— М., 1988.

Бергер П. Л. Приглашение в социологию: Гуманистическая перспектива / Пер. с англ.— М., 1996.

Бодалев А. А. Личность и общение: Избранные психологические труды. 2-е изд., перераб.— М., 1995.

Большая энциклопедия Кирилла и Мефодия / Отв. ред. Т.Г.Музрукова.— М., 1997 (электронная версия).

Бородкин Ф. М., Коряк Н. М. Внимание: конфликт!— Новосибирск, 1989.

Бродель Ф. Материальная цивилизация, экономика и капитализм, XV–XVIII вв.— М., 1986.

Введение в одиществознание. Актуальные проблемы: Пособие.— М., 1991.

Введение в обществознание: Учеб. пособие для 8–9 классов общеобразовательных учреждений / Под ред. Л.Н.Боголюбова. 2-е изд.— М., 1997.

Гофман А. Б. Мода и люди: Новая теория моды, модного поведения.— М., 1994.

Гуревич А. Я. Проблемы средневековой народной культуры.— М., 1981.

Здравомыслов А. Г. Социология конфликта.— М., 1995.

Империя фарисеев: Социология и психология диктатуры.— Саратов, 1994.

Клибанов А. И. Духовная культура средневековой Руси.— М., 1994.

Клименко А. В., Румынина В. В. Обществознание в вопросах и ответах: Учеб. пособие для старшекл. и поступающих в вузы.— М., 1998.

Кон И. С. Открытие «Я».— М., 1995.

Кравченко А. И. Введение в социологию.— М., 1995.

Леонтьев А. Н. Проблемы развития психики.— М., 1972.

Липсиц И. В. Экономика без тайн.— М., 1993.

Лихачев Д. С. Прошлое — будущему: Статьи и очерки.— Л., 1985.

Народные знания. Фольклор. Народное искусство. Свод этнографических понятий и терминов. Вып. 4.— М., 1991.

Обозов Н. Н. Межличностные отношения.— Л., 1979.

Поршнев Б. Ф. Социальная психология и история.— М., 1979.

Прикладная экономика.— М., 1993.

Пугачев В. П., Соловьев А. И. Введение в политологию.— М., 1995.

Радугин А. А. Введение в религиоведение: Теория, история и современные религии.— М., 1997.

Россия в окружающем мире: 1998 (Аналитический ежегодник).— М., 1998.

Руднев В. А. Дерево жизни: Об истоках народных и религиозных обрядов.— М. — Л., 1989.

Русская нация: Историческое прошлое и проблема возрождения.— М., 1995.

Самуэльсон П. Экономика.— М., 1964.

Семья на пороге третьего тысячелетия.— М., 1995.

Соколов Э. В. Культурология: Очерки теорий культуры. Пособие для старшеклассников.— М., 1994.

Сорокин П. Человек, цивилизация, общество.— М., 1992.

Социальные реформы в России: История, соврем. состояние и перспективы.— СПб., 1995.

Социальные конфликты. Экспертиза прогнозирование, технологии разрешения.— М., 1995.

Февр Л. Бои за историю.— М., 1991.

Шибутани Т. Социальная психология / Пер. с англ.— М., 1961.

Щепаньски Я. Элементарные понятия социологии / Пер. с польск.— М., 1969.

Энциклопедия «Хроника человечества».— М.: GSC, 1997.

ИЗДАТЕЛЬСТВО «РУССКОЕ СЛОВО»
ПРЕДЛАГАЕТ УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИЕ КОМПЛЕКТЫ ПО ОБЩЕСТВОЗНАНИЮ,
А ТАКЖЕ ИЗДАНИЯ ПО ВОСПИТАНИЮ ДЕТЕЙ

5 класс

•*Кравченко А.И. Обществознание. Учебник для 5 класса.

**Кравченко А.И., Хромова И.С. Обществознание. Программа курса для 5–7 классов общеобразовательных учреждений.

**Черных Р.М., Кутырова О.В. Тематическое планирование курса обществознания (с региональным компонентом). 5–7 классы основной школы.

6 класс

*Кравченко А.И., Певцова Е.А. Обществознание. Учебник для 6 класса.

**Хромова И.С. Обществознание. Рабочая тетрадь для 6 класса.

7 класс

**Кравченко А.И., Певцова Е.А. Обществознание. Учебник для 7 класса.

8 класс

•*Кравченко А.И. Обществознание. Учебник для 8 класса. Ч.1.

**Кравченко А.И. Задачник по обществознанию. 8–9 классы. Учебное пособие.

**Кравченко А.И. Обществознание. Программа курсов для 8–9 и 10–11 классов общеобразовательных учреждений.

**Кравченко А.И. Тесты по обществоведению. 8–9 классы.

**Черных Р.М. Тематическое планирование курса обществознания (с региональным компонентом). 8, 9, 10 и 11 классы.

**Певцова Е.А. Обществознание. 8–9 классы.Книга для учителя.

9 класс

•*Кравченко А.И. Обществознание. Учебник для 9 класса. Ч.2.

**Певцова Е.А. Право: Основы правовой культуры. 9 класс.

10 класс

•*Кравченко А.И. Обществознание. Учебник для 10 класса. Ч. 1.

**Кравченко А.И. Задачник по обществознанию.10–11 классы.

**Кравченко А.И. Тесты по обществознанию.10–11 классы.

**Певцова Е.А. Обществознание.10–11 классы. Книга для учителя.

Певцова Е.А. Право. Основы правовой культуры. Учебник для 10–11 классов общеобразовательных учреждений.

** Волкова Е.В. Этика. Учебное пособие для 10–11 классов.

11 класс

•*Кравченко А.И., Певцова Е.А. Обществознание. Учебник для 11 класса. Ч. 2.

Кравченко А.И., Резникова Т.П. Обществознание. Справочное пособие для абитуриентов.

• Входит в Федеральный перечень Министерства образования Российской Федерации.

* Допущено Министерством образования Российской Федерации

** Входит в Перечень-каталог учебно-методических изданий Министерства образования Российской Федерации на 2003/2004 учебный год

Кравченко А.И., Певцова Е.А.

К78 Җәмгыять белеме: 9 сыйныф өчен уку ярдәмлеге. /Русчадан М. А. Хәйруллин тәрҗ.— Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2005.— 223 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-94113-205-0

Дәреслек 8 сыйныф дәреслегенең дәвамы булып тора. Биредә хокук, политология һәм культурология нигезләре яктыртыла.

Дәреслектә җәмгыятьнең әлеге сфералары буенча РФ Мәгариф министрлыгы раслаган мәҗбүри минимум күләмендәге материал тулысынча тупланган.

Китап хәзерге заман укучылары өчен җиңел һәм аңлаешлы телдә язылган.

ISBN 5-94113-205-0

ISBN 5-94113-205-0
9785941132058

Учебное издание

Кравченко Альберт Иванович
Певцова Елена Александровна

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

Учебник для 9 класса

4-е издание

(перевод с русского на татарский язык)

Редакторы *И. Х. Халиуллин*
Корректоры *Ә. Ф. Әхмәдуллина*
Компьютерда биткә салучы *Г. С. Нуретдинова*

Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты.
420015, Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014, Казан, Кремль, а/я 54.
Тел. (факс): (8432) 38-63-06

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.09.2005. Форматы 60×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 14,0.
Тиражы 12 000 д., Заказ А-833

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

«Русское слово»
«Хәтер»